300

Л. Җәләй

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ТАРИХИ ФОНЕТИКАСЫ БУЕНЧА МАТЕРИАЛЛАР

ТАТКНИГОИЗДАТ • 1954

СССР ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ КАЗАН ФИЛИАЛЫ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ
ТАРИХ ИНСТИТУТЫ

Л. ҖӘЛӘЙ

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ТАРИХИ ФОНЕТИКАСЫ БУЕНЧА МАТЕРИАЛЛАР

К. САБИРОВ
редакциясендә

ТАТКНИГОИЗДАТ
УКЫТУ-ПЕДАГОГИК ӘДӘБИЯТ РЕДАКЦИЯСЕ
КАЗАН 1954

# ЭЧТӘЛЕК

Автордан . . . . . . . . . . . . . . . . 3
I. Татар теле фонетикасы тарихына кереш урынында 5
II. Татар теле формалашу процессында күзәтелгән кайбер фонетик үзгәрешләр . . . . . . . . . . . . 16
III. Сузыклар өлкәсендәге үзгәрешләр . . . . . . . . . 25
1. А авазының ике төрле әйтелеш мәсьәләсе: 1) ачык а, 2) иренләшмә а . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
2. О—ө һәм у—ү авазлары формалашу мәсьәләсе . . 32
3. Сузыклар гармониясе яки иренләшү охшашлыгы . . 39
IV. Тартыклар өлкәсендәге үзгәрешләр . . . . . . 51
1. Тартыклар гармониясе һәм андагы үзгәрешләр . . . 51
2. Тартыклар арасындагы тәңгәллек һәм аларның берберенә күчүләре . . . . . . . . . . . . 57
3. К—г авазларының ясалу урыннары, әйтелешләрендәге үзгәреш һәм аларның бүтән авазлар белән алмашынулары . . . . . . . . . . . . 78
4. Ң авазының килеп чыгышы һәм тарихи үзгәреше 85
5. Зат алмашлыкларыннан үзгәреп килеп чыккан кушымчалар . . . . . . . . . . . . . . . . 88
6. Авазлар төшеп калу күренеше . . . . . . . . . 96
7. Сүзләрнең мәгънәләрен үзгәртмичә генә төшеп калган авазлар һәм иҗекләр . . . . . . . . . . . . . 103

Л. ЗАЛЯЙ

МАТЕРИАЛЫ ПО ИСТОРИЧЕСКОЙ ФОНЕТИКЕ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

(на татарском языке)

Редакторлары *М. Хәсәен һәм С. К. Хакимов*

Техник редакторы *Ф. Г. Нурутдинов*

Корректоры *Л. Шайнурова*

Производствога бирелде 10|VIII-53 ел. Басарга кул куелды 23|III-54 ел. ПФ 01144. Кәгазь форматы 84х108¹|₃₂. Учет.-изд. 5,46 табак. Басма табак 6,75 (5,53) Табакта 33.712 знак. Заказ № А -166. Тираж 6.000. Бәясе 1 сум 45 тиен.

Татарстан АССР Министрлар Советы каршындагы полиграфия промышленносте, издательстволар һәм китап сәүдәсе эшләре Управлениесенең Камил Якуб исемендәге китап фабрикасында басылды. Казан, Бауман урамы, 19. 1954 ел.

## АВТОРДАН

И. В. Сталинның „Марксизм һәм тел гыйлеме мәсьәләләре“ һәм „СССРда социализмның экономик проблемалары“ дигән гениаль хезмәтләре совет фәненең үсешенә яңа юнәлеш, марксистик программа бирделәр.

Һәркайсыбызга мәгълүм булганча, И. В. Сталинның шушы хезмәтләре белән коралланып, совет тел белеме, маррчылар сөйрәп килгән барлык чүп-чарлардан арынып, соңгы өч ел эчендә бик зур казанышларга иреште, тел фәненең иң төп проблемалары марксистик методология нигезендә чишелде, ачыкландылар. Бу казанышлар, үз чиратында, мәктәп грамматикалары — норматив грамматикалар тармагында яшәп килгән кимчелекләрне бетерергә, гомумән, тел буенча дәреслекләрнең сыйфатын яхшыртырга мөмкинлек ачтылар. 1953 елның 18 — 23 маенда СССР Фәннәр Академиясенең Тел белеме институты уздырган зур киңәшмәдә теркәүле (описательная) грамматикалар нинди принципларга нигезләнеп төзелергә тиешлек турында тирән эчтәлекле аерым бер доклад куелды. Бу докладта саналган һәм тәкъдим ителгән принциплардан берсе норматив грамматикаларга кергән тел материалларының тарихилык белән сугарылган булырга тиешлегеннән тора. Мәктәп грамматикаларын мондый принципка кору И. В. Сталин күрсәтмәләрен тел фәнендә тормышка ашыруның реаль күрсәткече булачак.

Норматив грамматикаларда телнең тарихи яклары нindiрәк күләм белән кертелерләр, монысы икенче мәсьәлә. Уйлыйбыз, бу турыда белгечләр үзләренең анык фикерләрен әйтерләр. Без исә әлегә шуны гына

әйтә алабыз, бу очеркка теркәлгән материаллар норматив грамматикаларны төзүчеләргә дә, укытучыларга да азмы-күпме ярдәм итәрләр.

Очеркыбызны „Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар“ дип атадык. Чөнки моңа әле киң мәгънәсендә тарихи фонетика булу өчен кирәкле фактларның байтагы кермәгән. Шуның белән бергә, бу материаллар тулысынча дип әйтерлек күләмдә тарихи-чагыштырма метод күзлегеннән карап яктыртылмаган да.

Кыскасы, бу очерк татар теленең тарихи фонетикасын әшкәртү юлында бер кереш кенә булып тора. Укучылар шуны исәпкә алырлар һәм, авторга ярдәм итү йөзеннән, үзләренең фикерләрен әйтерләр, дип ышанабыз.

*Л. Җәләй.*

# I. ТАТАР ТЕЛЕ ФОНЕТИКАСЫ ТАРИХЫНА КЕРЕШ УРЫНЫНДА

„... тел, — дип өйрәтә И. В. Сталин, — аралашу коралы булу белән бергә, көрәш коралы һәм җәмгыятьне үстерү коралы“[1].

Безнең илдә яшәүче барлык халыкларның телләре, аралашу чарасы булу белән беррәттән, коммунизм җәмгыяте төзү, җир йөзендә тынычлык урнаштыру, бөтен кешелекне капитализм тырнагыннан коткару өчен көрәш коралы булып та хезмәт итә.

Марксистик методологиягә нигезләнгән совет тел белеменең төп бурычы, тел культурасын иң югары дәрәҗәгә күтәрү юлы белән, күп милләтле илебезне һәрьяклап үстерүгә һәм коммунизм җәмгыяте төзүгә чын күңелдән бирелеп хезмәт итүдән гыйбарәт.

„Тел — кешеләргә бер-берсе белән аралашырга, фикерләр алышырга һәм үзара аңлашуга ирешергә ярдәм итә торган чара, корал. Фикерләү белән турыдан-туры бәйләнештә булганлыктан, тел сүзләрдә һәм җөмләләрдәге сүзләр бәйләнешендә фикерләү эшенең нәтиҗәләрен, кешенең танып-белү эшенең уңышларын терки һәм беркетә һәм, шулай итеп, кешелек җәмгыятендә фикер алышу мөмкинлеген тудыра“[2], — дип өйрәтә И. В. Сталин.

Бу күрсәтмәдә фәнни аныклык белән телнең иҗтимагый, тарихи урыны билгеләнә.

Укытучыларның бурычы — укучыларыбызның танып-белү сәләтләрен коммунистик рухта тәрбияләү. Димәк, тел, әнә шушы бөек бурычны үтәп чыгу өчен, иң зур чараларның берсе булып тора. Ләкин моңа ирешү, ягъни тел белемен, тел фәнен әнә шундый

---

[1] И. В. Сталин, Марксизм һәм тел гыйлеме мәсьәләләре, Татгосиздат, 1951 ел, 20 бит.

[2] Шунда ук, 19—20 битләр.

тарихи бурычларны үти алу дәрәҗәсенә күтәрү өчен, барыннан да элек, без аны марксизм методологиясе нигезендә тулы үзләштергән булырга тиешбез. Телне тәрбия чарасы итеп үзләштерү өчен, аның барлык законнарын тирәнтен белү кирәк.

„Тел — җәмгыять яшәгән бөтен вакыт буена эш итүче иҗтимагый күренешләр исәбенә керә. Ул — җәмгыять белән бергә туа һәм җәмгыять белән бергә үсә. Ул — җәмгыять үлү белән бергә үлә. Җәмгыятьтән тыш тел юк. Шуңа күрә телне һәм аның үсеш законнарын җәмгыять тарихы белән, өйрәнелә торган телнең иясе, иҗатчысы һәм гәүдәләндерүчесе булган халыкның тарихы белән аерылгысыз бәйләнештә өйрәнгәндә генә аңларга мөмкин“[1],—дип өйрәтә И. В. Сталин.

Бу күрсәтмәдә, һәркемгә аңлаешлы итеп, телдәге законлылыкны тулысынча үзләштерә алу аның тарихын белү җирлегендә генә булырга мөмкин икәнлеге әйтелә.

Академик Н. Я. Марр грамматиканы, „Форма гына ул“, „Мәктәп схоластикасы гына ул“, — дип, бөтенләй инкарь итте һәм, шуның аркасында, идеализмга барып чыкты.

И. В. Сталин хезмәтләрендә Н. Я. Маррның ялгыш карашы фаш ителеп, грамматиканың тел төзелешендәге роле, хезмәте бөтенләй яңача, чын-чыннан материалистик диалектика законнары нигезендә ачып бирелде.

„Телнең сүзлек составында иң әһәмиятлесе — төп сүзлек фонды; барлык тамыр сүзләр дә шул фондка керәләр һәм аның ядросы булалар. Бу фонд телнең сүзлек составына караганда шактый таррак була, ләкин ул бик озак, гасырлар буе яши һәм телгә яңа сүзләр тудыру өчен база бирә. Сүзлек составы телнең нинди хәлдә булуын чагылдыра: сүзлек составы никадәр бай һәм күпьяклы булса, тел шулкадәр бай һәм шулкадәр алга киткән була.

Ләкин сүзлек составы, үзен генә алганда, тел түгел әле, — тел булудан бигрәк ул тел өчен төзү материалы“[2], — дип өйрәтә И. В. Сталин.

---

[1] И. В. Сталин, Марксизм һәм тел гыйлеме мәсьәләләре, Татгосиздат, 1951 ел, 19 бит.
[2] Шунда ук, 20 бит.

Монда телнең сүзлек составына тирән һәм фәнни ачык аңлатма бирелә. Төп сүзлек фондының һәм сүзлек составының аңлашу, аралашу чарасы була алуы өчен, аның грамматика карамагына керүе шарт. И. В. Сталин бу моментны түбәндәгечә билгели:

„Ләкин телнең сүзлек составы, тел грамматикасы карамагына кергәч, бик зур әһәмият казана. Грамматика сүзләрне төрләндерү кагыйдәләрен, җөмләләрдә сүзләрнең бәйләнү кагыйдәләрен билгели һәм, шул рәвешчә, телгә төзек, мәгънәле характер бирә. Грамматика (морфология, синтаксис) ул — сүзләрне төрләндерү һәм җөмләдә сүзләрне тезү турындагы кагыйдәләр җыелмасы. Димәк, нәкъ менә грамматика аркасында тел кеше фикерләрен материаль тел тышчасына төрергә мөмкинлек ала“[1], — дип өйрәтә И. В. Сталин.

Бу күрсәтмә грамматиканың телдә тоткан роле һәм сүзлек составы белән грамматик категорияләр арасындагы диалектик бәйләнешне бөтен тирәнлеге белән ачып бирә. Димәк, грамматик категорияләр „телгә төзек, мәгънәле характер бирә“ (И. В. Сталин) торган чаралар булалар.

„Шулай итеп, телнең грамматик төзелеше һәм аның төп сүзлек фонды телнең нигезен, аның спецификасының асылын тәшкил итәләр“[2], — дип, И. В. Сталин безгә марксистик формула бирде.

Тел өстендә күзәтүнең, аның тарихын һәм хәзерге торышын өйрәнүнең нигез ташы, төп материалы булып, телнең грамматик төзелеше һәм төп сүзлек фонды ятарга тиеш. Бу грамматика белән сүзлек составы арасындагы үзара мөнәсәбәтнең диалектик нигезен беренче планга куя. Һичшиксез, марксистик методология тел укыту практикасын да, телне теоретик өйрәнү эшен дә җиңеләйтә, туры юлга сала.

Татар теле тарихын өйрәнүнең төп объекты, материалы — аның сүзлек фонды, сүзлек составындагы үзгәреш, үсеш һәм грамматик төзелешендә булып үткән камилләшү, шомару күренешләреннән тора.

Бер телнең тарихын өйрәнү аның үсеш һәм акрынлап үзгәрә баруын, иске сыйфаттан яңа сыйфатка күчүен, ягъни андагы искергән сүзләрнең төшеп калуын, алар

---

[1] И. В. Сталин, Марксизм һәм тел гыйлеме мәсьәләләре, Татгосиздат, 1951 ел, 20—21 битләр.

[2] Шунда ук, 22 бит.

урынына икенчеләренең урнашуларын, шулай ук борыннан ук яшәп килгән сүзләрнең яңа мәгънәгә күчүләрен белергә ярдәм итә. Мәсәлән, хәзерге татар телендә *ярыш* сүзе кешеләрнең намус белән, социалистик аң белән хезмәт итүләрен, үз өсләренә төшкән бурычны коммунистларча үтәүләрен аңлата. Борында исә бу сүз кешеләрнең бер-берләрен яру, кыйнауларын аңлаткан, тискәре төшенчәдә йөргән.

Телнең грамматик, фонетик төзелешендә дә күп кенә үзгәрү, яңарулар булган. Боларны тикшерү, исәпкә алу шушы телне иҗат иткән халыкның формалашу тарихын, аның аң культурасының үсеш тарихын күзаллауга ярдәм итә. Телнең тарихын белү аның бүгенге төзелешен аңлау, төшенүне җиңеләйтә.

Телне, аның структурасын нинди дә булса бер эпоха продукты итеп кенә карарга ярамый. Телнең структурасы, аның грамматик төзелеше һәм төп сүзлек фонды — күп эпохалар продукты.

„Хәзерге заман теленең элементлары бик борынгы заманнарда ук, коллык эпохасына кадәр ук салынган дип уйларга кирәк. Бу тел катлаулы булмаган, аның сүзлек фонды да бик ярлы булган, ләкин аның үзенең грамматик төзелеше булган, дөрес, примитив төзелеш, ләкин, шулай да, грамматик төзелеше булган“[1], — дип өйрәтә И. В. Сталин.

Билгеле, татар теленең дә башлангыч яралгысы, И. В. Сталин өйрәткәнчә, коллык эпохасына чаклы ук, ягъни башлангыч җәмгыятьтә үк барлыкка килгән. Тагын да ачыграк итеп әйткәндә, хәзерге татар теленең яралгысы татар дигән халык үзе һәм аның гомумхалык теле формалашканчы ук туган була. Ул яралгы тел гомумтөрки теленең борынгы материалы итеп санала. Хәзерге гомумтатар теленең формалаша башлау тарихы Идел-Кама болгарлары дәүләтендәге төрки кабиләләргә барып тоташа, бу, якынча, IX—X йөзләргә туры килә. Реаль тарихның мөгаен шулай булганлыгын тел фактлары раслыйлар. Моңа ышанычлырак дәлил булып, болгар кабер ташбилге язмалары хезмәт итәләр. Берничә мисал алыйк:

---

[1] И. В. Сталин, Марксизм һәм тел гыйлеме мәсьәләләре, Татгосиздат, 1951 ел, 23 бит.

„Мөхәммәт ул[1] Хәсән блүкү... Тарих җиат җөр“;

„Хәсән ул Гали ул Әхмәт хаҗи зиарәте торур. Тарих җиат җөр“ (1299).

„Айбикә бинте Мөхәммәт зиарәте торур. Тарихка йите йөз йикерме өчтә ирде“ (1302).

„Йәкетләр күрке, күнелләр үзәге, галимнәрне агырлаган, ятим, тол, үксезләрне асраган Муса угылы алтынчы Шаһидулла... һиммәт кыйлсун. Шәһре рабигаль әүүәленең уртасында тарихка vıv“[2] (1306).

Менә шушы беренче карашка шактый примитив күренерлек текстлар гына да бик характерлы мәгълүмат бирәләр. Ул текстларның сүзлек составы һәм грамматик төзелешләрендә хәзерге гомумтатар теленә һәм аның грамматик төзелешенә зур гына якынлык бар, детальрәк анализ ясаганда, түбәндәге фактлар ачыла. Боларның сүзлек составындагы, мәсәлән, *җөр, блүкү, йәкет, күрке, күңел, үзәк, ятим, тол, үксез, асрау, ул, угыл, алтынчы, зиарәт, торыр, йите, йөз, йикерме, өч, ирде* (иде) кебек сүзләр хәзерге телнең сүзлек составында актив кулланышларын дәвам иттерәләр. Монда теркәлгәннәрдән хәзерге көнне кулланылмый торган *агырлау* сүзе борынгы әдәбиятта *олылау, хөрмәтләү* мәгънәсендә йөргән.

*Җөр* — йөз дигән сүз. Хәзерге телдә без бу сүзне *чор* формасында билгеле бер вакыт аралыгы (русча эпоха) мәгънәсендә йөртәбез. Мәсәлән, безнең *чор* — коммунизм төзү *чоры* (наша эпоха — эпоха строительства коммунизма).

*Блүкү* — төбендә, *билгесе* дигән сүз. „Хәсән *блүкү*“ — шул кешенең каберенә билге дигән мәгънәне аңлата. Бу сүзнең тамыры — *бел*. Хәзерге татар теленең сүзлек фондында һәм сүзлек составында *бел* тамырыннан ясалган сүзләрнең саны дистәләргә җитә. Хәтта совет чорында гына да без *бел* тамырыннан *белгеч, белдерү, белешмә, белем* (мәсәлән, тел белеме), *билгеләмә* (определение), *билгесезлек* (килеше) кебек берничә сүз — термин ясадык.

*Блүкү* — (билге, билгесе) сүзенең грамматик төзелеше *бел* — тамырыннан һәм *кү* (*гү-ке-ге*) аффиксын-

---

[1] Искәрмә. Кайбер кабер ташларында *ул ы* сүзе *ул* (اول) формасында да язылган. *Автор.*

[2] vıv борынгы татар әдәбиятында кулланылган цифр, 717 була.

нан тора. Билгеле булганча, *бел* тамырыннан берничә сүз ясалган кебек, *ку—кү* (*гу—гү*) аффиксы да,*кы—ке, гы—ге* формаларына әверелеп, нисбәт, тартым төшенчәсен аңлату чарасы булып хезмәт итә. Мәсәлән, *язгы, кышкы, авылдагы, басудагы, синдәге, миндәге* кебек формалардагы кушымчалар әнә шушы *ку—гу, күгү* дән үзгәргәннәр.

„Алтынчы Шаһидулла" дигән сүз тезмәсендәге *чы* кушымчасы (һөнәр, профессия төшенчәсен биргән) хәзерге татар телендә иң актив ясагычлардан берсе булып тора. Мәсәлән, *укытучы, колхозчы, язучы, тәрбияче, хәбәрче, очучы, тракторчы* һ. б.

Югарыда теркәлгән текстларның грамматик формаларын тикшергәндә, „Мөхәммәт *ул*" (Мөхәммәт улы дигән сүз) һәм „*Муса угылы*" тезмәләренә игътибар бирергә тиешбез. Эш моннан гыйбарәт: күргәнебезчә, бу текстларның барысы да бер үк чорда язылганнар. Шулай булуга карамастан, берсендә „*Мөхәммәт ул*", икенчесендә „*Муса угылы*" формасында бирелгән, ягъни „*ул*" (сын) сүзе фонетик яктан да, грамматик яктан да „*угылы*" дан аерыла. „*Угыл*" (угылы) формасы „*ул*" га караганда чагыштырмача борынгырак, чөнки, „*г*" авазы төшеп, „*угыл*" дан „*ул*" га калган. Бу исә, үз чиратында, „*ул*" ның гомумхалык сөйләм теленнән алынган булып та, „*угыл*"ның китап, язу теле традициясе буенча сакланганлыгын күрсәтә. Икенчедән, „*ул*" (Мөхәммәт ул) сүзенең тартым кушымчасы алмый гына аерылмыш позициясендә килеп, „*угылы*" (Муса угылы) формасының тартым алган булуы да бик әһәмиятле тарихи бер мәсьәлә турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә.

Билгеле ки, хәзерге гомумтатар телендә һәм әдәбиятта „Муса улы", „Хәсән улы" формасы, ягъни тартымлы бәйләнеш формасы төп норма булып тора. Икенче төрле әйткәндә, әнә шул борынгы язмалардагы „Муса угылы" (улы) формасы дәвам итә. Шуның белән беррәттән, татар теленең аерым диалект һәм сөйләшләрендә „Хәсән ул" формасы да (тартымсыз бәйләнештә) яши.

Мәсәлән, „*учак утын*" (учак утыны), „*тау түбә*" (тау түбәсе), „*ызбарт*" (өй арты)... дип сөйләү Молотов-Свердлов сөйләшендә, „*үзебез эш*", „*үзебез авыл*" дип әйтү урта диалектның Норлат-Кайбыч урын-

чылыгында һәм, *„Нократ авыл“* (Нократ авылы), *„йәралма бакча“* (бәрәңге бакчасы), *„Олча баш“* (урам башы), *„кытай чәй“*, *„җан папа“* (җан күбәләге)... дип сөйләү урта диалектның Нократ-Кистем сөйләшендә система булып тора.

Димәк, тартымлы бәйләнешнең (аергыч-аерылмыш бәйләнешенен) ике төрле, ягъни кушымчалы һәм кушымчасыз формаларда тәгъбир ителүе татар теле тарихында болгар чорыннан ук килә торган күренеш икәнлеге ачыла. Монысы бер яктан. Икенче яктан исә, бу моментның ачылуы хәзерге көнне тартымлы бәйләнеш юлы белән (синтаксик юл белән) ясала торган кушма тамырлы сүз-терминнардан тартым кушымчасын төшереп калдыру формасы кайдан килгән һәм нинди законлылыкка нигезләнгән булуын күз алдына китерергә мөмкинлек бирә.

Билгеле, безнең терминологлар хәзерге көнне кушма тамырлы терминнарны күп очракта тартым кушымчасыз формалаштыру юлы белән баралар. Мәсәлән, *кульязма* (кул язуы, кул язмасы түгел), *көнчыгыш* (көн чыгышы түгел), *көнбатыш, төньяк, көньяк, үзаң* (үз аңы түгел) һ. б. шундый төзелешкә, структурага керәләр һәм, материаллардан күренгәнчә, бу форма татар теле тарихы өчен яңа түгел, бәлки әнә шул борынгы „Мөхәммәт үл“ (улы урынына) формасының активлаштырылган дәвамы гына. Чөнки *Казанбаш, Орнашбаш, көнчыгыш, төшлек як, билбау, табагач, кисәүагач, тукранбаш*... кебек кушма тамырлы сүз-терминнарның тартым кушымчасыз әйтелеше һәм язылышлары бик күптәннән бирле яшәп килә.

1950 елны басылып чыккан авыл хуҗалыгы терминнары сүзлегендә *көлматдә, утчәчәк, һавасыеш, каргаборын* (корал), *үрдәкборын* (корал), *казаяк* (үлән), *кураҗиләк* (җимеш) һ. б. кебек байтак кына терминнар бар. Боларның барысы да тартым кушымчасы төшереп калдырылган формага нигезләнгәннәр.

Шуны да әйтергә кирәк, бу форма термин һәм атамалар арасындагы мәгънә нечкәлекләрен аныкларга да ярдәм итә. Мәсәлән, *каргаборын* белән *карга борыны* бер-береннән бик ачык аерылалар. Болардан беренчесе карга борынына охшаган коралны, икенчесе — карганың үз борынын, ягъни томшыгын аңлата; *үрдәкборын* — корал, *үрдәк борыны* — монысы үрдәк-

неӊ үз борыны; *казаяк*—үлән, *каз аягы*—казныӊ үз аягы була. Без монда шактый характерлы законлылык күрәбез. Икенче яктан, шул ук формаларныӊ әдәби телдә йөртелүләре әлегә шактый каршылыклы да: мәсәлән, югарыда әйтелгән сүзлектә, *куражҗиләк* белән беррәттән, *каен җиләге* дип алынган. Система булу ягыннан караганда, монысын да *каенҗиләк* формасында алу кирәк иде дигән фикер туа.

Мондый каршылыклар кайдан килеп чыгалар соӊ? Моныӊ аӊлатмасы ачык: мондый хәлләр әдәби тел нормалары беркетелү, урнашу процессына гомумхалык телендәге төрле диалект, сөйләш, хәтта урынчылыкларныӊ да теге яки бу күләмдә катнашлары булудан килә.

Мәгълүм ки, *куражҗиләк* (формасы) Казан арты сөйләшенеӊ Дөбъяз-Әтнә урынчылыгына һәм Нократ-Кистем сөйләшенә хас. Калган диалект, сөйләшләрдә исә, гомумән, *курай җиләге* (кура җиләге), *каен җиләге, җир җиләге* дип әйтелә.

Димәк, сүзлеккә (әдәби телне документлаштыра торган чара) *кура җиләк* формасы Дөбъяз-Әтнә урынчылыгыннан алып кертелгән. *Каен җиләге* формасы исә гомумхалык сөйләм практикасына урнашканча алынган була.

Билгеле, бу урында без сүзлек төзүчеләр, термин ясаучылар белән сүз көрәштерергә җыенмыйбыз. Ләкин хәзерге терминология практикасында тартымсыз бәйләнеш формасыныӊ алга сөрелүен искә төшереп китәргә тиешбез. Мәсәлән, *көнчыгыш, көнбатыш, төньяк, көньяк, узаӊ*... кебек терминнар әнә шушы формага (куражиләк формасына) нигезләнгәннәр.

Мәгънә киӊлеге һәм форма үлчәме ягыннан килгәндә, һичшиксез, *көньяк, үзаӊ*... формасы баерак һәм рациональрәк. Чөнки *көньягы*—бу, тар мәгънәсендә, берәр нәрсәнеӊ көн ягы була, шулай ук *үз аӊы* да ниндидер бер субъектныӊ үзендәге аӊын гына белдерә; *үзаӊ* исә киӊрәк, чөнки монда абстракцияләү көчле, шул уӊайда *үзаӊ*—үзе бер субстант, мөстәкыйль бер фәлсәфи төшенчәгә әверелә.

Кыскасы, терминологлар бу форманы активлаштырып дөрес итәләр. Чөнки бу формада, И. В. Сталин күрсәткәнчә, телнеӊ, тел чараларыныӊ иске сыйфаттан яӊа сыйфатка күчү моменты бик ачык чагыла.

Безне, тел фактларын тарихи планда күзәтүчеләр буларак, түбәндәге берничә конкрет мәсьәлә кызыктыра. Беренчедән, хәзерге татар телендә тартымлы сүз тезмәсен аффикслы һәм аффикссыз формада әйтергә мөмкинлек булуы ачыла. Мәсәлән, *җир җиләге* дип тә, *җирҗиләк* дип тә әйтергә мөмкин. Икенчедән, менә шушы ике форманың болгар чоры язмаларында ук янәшә йөргәнлекләре раслана. Мәсәлән, „Мөхәммәт ул"( Мөхәммәт улы) — монда тартым кушымчасы „ы" юк, һәм „Муса угылы" (Муса улы) — монысында тартым кушымчасы „ы" бар.

Бу, әлбәттә, ниндидер очраклы күренеш кенә булмаган. Моның нигезендә ул чордагы кабиләләр теленә хас диалекталь аерма ята. Тарихи чынбарлыкның мөгаен шулай булганлыгын хәзерге татар теле жирле диалектларында сакланган тел фактлары раслыйлар.

Югарыда әйткәнебезчә, тартымлы сүз тезмәсен аффикссыз формада сөйләү урта диалектның Нократ-Кистем сөйләшенә, өлешчә Дөбъяз-Әтнә, Норлат-Кайбыч урынчылыкларына һәм Свердлов-Молотов сөйләшенә хас күренеш булып тора. Шул ук урта диалектның калган сөйләшләре һәм урынчылыкларында, көнбатыш һәм көнчыгыш диалектларда тартымлы тезмәне аффикслап әйтәләр. Мәсәлән, *кояш чыгышы*, кояш *иңеше*, *кояш баешы* (яклар); *җир җиләге, кура җиләге*; *алма агачы*, *имән агачы*... формасын куллану көнбатыш диалектта аерата көчле.

Күреп үткәнебезчә, әдәби телебездә дә менә шушы ике форманың янәшә йөрүе бар. Уебызча, бу фактлар үзләре генә дә тартымлы тезмәнең борын-борыннан ук татар телендә ике формасы сакланып килгәнлеге турында сөйлиләр.

Чагыштырма-тарихи методның семьядаш телләр тарихын өйрәнүдә файдасы зур булуын И. В. Сталин тел турындагы гениаль хезмәтләрендә басым ясап әйтте.

Әгәр дә без бу урында менә шушы тартымлы тезмәне киңрәк күзалларга телибез икән, ул чагында чагыштырма-тарихи күзәтү чарасына мөрәҗәгать итәргә тиеш булабыз, һәм бу метод, һичшиксез, мәсьәләне тулырак чишәргә ярдәм итәчәк.

Проф. Н. К. Дмитриев үзенең „Башкорт теленең грамматикаһы"ндагы (1950 ел, 241—246 битләр) „Исем-

дәрҙ̣ең аныклауһылар группаһы“ дигән бүлекчәсендә бу төр сүз тезмәсенә шактый киң туктала һәм аны, „1) *тимер юл*, 2) *кала баксаһы*, 3) *каланың баксаһы*“ (242 б.) формаларында алып, өч төркемгә бүлә дә болардан беренчесен иң борынгы тип итеп билгели, дөресе, билгеләргә мөмкин итеп саный. Үз сүзләре белән әйткәндә, аныңча, болай була:

„Был өс типтың иң боронгоһо, күрәһең, беренсе тип булырга тейеш. Был күренеш төрөк телдәренең үҫешендә морфологик күрһәткестәрҙ̣ең (аффикстәрҙ̣ең) яһалып өлгөрмәгән һәм һүҙ̣ҙ̣әрҙ̣ең араһындагы мөнәсәбәттәр (бәйләнештәр) фәкәт синтактик юлдар менән генә бирелгән эпоханы кәүҙ̣әләндерә. Төрөк системаһындагы кайһы бер телдәрҙ̣ә (кумык, сыуаш һ. б. телдәрҙ̣ә) был беренсе тип өҫтөнлөк итә, мәҫәлән: кумыкса къумыкъ тили тип түгел, а къумыкъ тил тип әйтергә кәрәк“[1].

Авторның бу уе шактый нигезле. Чөнки морфемалар чагыштырмача соңрак барлыкка килгәннәр. Сүзләрнең янәшәлек юлы белән, авторча, „синтактик юлдар менән“ үзара бәйләнешләре — борынгырак этап булып тора; „*комык тел*“ (комыкча), „кәзә һакал“ (башкортча), „билбау“ (татар һәм башкортча), „куражиләк“ (татарча) — болар „комык *теле*“, „*бил бавы*“, „*кура җиләге*“нә караганда элегрәк яшәгән формалар булып чыга.

Н. К. Дмитриев башкорт теле терминологиясендә шушы тип тартымлы бәйләнешнең соңгы вакытта активлашып баруын әйтә, мәсәлән, „урын килеш“ (243 бит, грамматик термин). Хәзерге татар әдәби теле терминологиясендә дә шул ук хәл сизелә. Мәсәлән, *баш килеш* (грам.), *көнбатыш диалект, көнчыгыш диалект* (тел белеме), *үзбаш* (мөстәкыйль мәгънәсендә), *күзал* (лау) — күзнең алдына китерү дигән сүз һ. б.

Чуваш теле җирле диалектларын өйрәнү буенча язылган фәнни документлар күрсәткәнчә, анда тартымлы бәйләнешнең аффикссыз формасы диалекталь

---

[1] Н. К. Дмитриев, „Башкорт теленең грамматикаһы“, 1950 ел, 242 бит.

Искәрмә: Башкортның тел арты авазлары булган калын *к—г* лары, типографиядә махсус хәрефләр булмаганлыктан, татарча *к—г* белән генә бирелде.

күренеш хәлендә генә калып, чувашның әдәби телендә аффикслы форманың актив урын биләве сизелә. „Сундыр районы чувашлары сөйләше“нә карата язылган кандидатлык диссертациясе афторефератында (1950 ел) Т. Я. Чуркин, әдәби телдә *күс сүле*, Сундыр сөйләшендә *кос сол* (слеза) (9 бит) дигән мисалны китерә. Һәм ул моны „авазлар төшеп калу“ күренеше итеп саный.

Димәк, чуваш телендә „*күз яше*“ һәм „*күз яшь*“ формалары бар булып чыга, татар телендә дә нәкъ шулай. Хәтергә төшерик, Г. Тукай да бит „Ак кирәк дип, пакь кирәк дип, күпме *күз яшь* түкмәдем“ дигән фразасында „*күз яшь*“ формасын куллана.

Җыеп әйткәндә, татар, башкорт һәм чуваш телләрендәге фактлар аффикссыз тартымлы сүз тезмәсенең шул ук аффикслы тезмәгә караганда борынгырак булуы турында уйларга мөмкинлек бирәләр. Шуның белән бергә, бу төр сүз тезмәсенең татар һәм чуваш телләрендә борынгы болгар чорыннан калган күренеш булуы да ышандыргыч төс ала. Ләкин мондый күзәтүләрне болгар чоры белән очлап калдыру гына да җитми, мөмкинлекләр сыйдырган күләмдә, киңрәк һәм еракканрак алып барларга тиешбез. Мәсәлән, шушы тартымлы сүз тезмәсенең һәр ике төре (тибы) Орхун язмаларында ук (732 елларда язылган) янәшә кулланыш алган булалар. Без ул текстта түбәндәге формаларны очратабыз: а) аффикссыз тартымлы тезмәләр: „*Табгач каган* (11)“, (Табгач каганы — ханы дигән сүз); „*Түрк будун*“ (6) (төрек халкы дигән мәгънәдә); „*Чугай йыш* (6)“ (чугай халкы дигән төшенчәне бирә); б) шул ук тезмәнең аффикс (тартым кушымчасы) белән формалаштырылганнары: „*Кеше оглы* (адәм баласы, кеше улы дигән мәгънәдә); „Түрк будуның *илен*, тор (ус)ен тута бирмеш (1)“. Соңгы фразаның „Түрк будун“ тезмәсендә тартым кушымчасы юк, „*будуның илен*“ тезмәсендә исә (ил-е-н) тартым кушымчасы бар; „*үзә түрк тәңресе* (10)“ — югарыда төрек күге дигән сүз)[1].

Шул рәвешчә, бер яктан, телнең борынгы чорга караган төзелешен, икенче яктан, аның бүгенге то-

---

[1] Мисаллар С. Е. Маловның „Памятники древнетюркской письменности“, 1951 ел, 27—29 битләр буенча алындылар. *Автор.*

рышын чагыштырып күзәткәндә, характерлы уртаклыклар, И. В. Сталин күрсәткәнчә, аерата телнең грамматик төзелешендәге тотрыклылык фактлары ачылалар.

Димәк, безнең бу уңайда кыскача гына күзәтүебез дә тартымлы сүз тезмәсенең бик борынгы заманнардан бирле үк аффикслы (кушымчалы) һәм аффикссыз формалары янәшә яшәп килгәнлеген күзаллауга мөмкинлек бирә ала.

Бу процессның теоретик аңлатмасын, безнең уебызча, нисби сыйфаттан „саф“ сыйфатка, әйбернең әйбергә мөнәсәбәтен билгеләүдән, әйбернең сыйфатын (качествосын) билгеләүгә күчү күренеше итеп нигезләү дөрес булачак.

Билгеле, без бу урында болгар эпитафик язмаларыннан китерелгән үрнәкләрнең грамматик һәм лексик якларына тулы анализ ясап тора алмыйбыз. Алай киңәю безне темабыздан читкә алып китәр иде. Без бу мәсьәләгә тик кереш уңаенда гына кагылдык. Ләкин шунысы ачык: мондый күзәтүләр, И. В. Сталин өйрәткәнчә, телнең күп эпохалар буена формалашкан бик катлаулы иҗтимагый күренеш икәнлеген тирәнтен төшенергә мөмкинлек бирәләр.

## II. ТАТАР ТЕЛЕ ФОРМАЛАШУ ПРОЦЕССЫНДА КҮЗӘТЕЛГӘН КАЙБЕР ФОНЕТИК ҮЗГӘРЕШЛӘР

Югарыда әйтелгәнчә, телдәге үзгәреш һәм алмашынуларны күзәткәндә, нигез итеп, сүзлек составы һәм грамматик төзелеш (морфология һәм синтаксис) алына. Грамматика төшенчәсе астына морфология, ягъни сүзләрнең төрләнеш һәм ясалыш типлары, нормалары турындагы өйрәтмә һәм синтаксис, ягъни сүз тезмәләре һәм җөмләләрнең формалары турындагы өйрәтмә керә. Фонетика исә — телнең аваз төзелеше турындагы өйрәтмә — грамматика составына керми. Ләкин сүзләр һәм сүз тезмәләре һәрвакыт телнең „табигый материясе“ булган авазлардан тыш булмаганлыктан, фонетикадан башка сүзләрнең төрләнеше яки ясалышы һәм җөмләдә сүзләрнең бәйләнеше турында фикер йөртеп булмый. Шуңа күрә грамматиканы өйрәнүдән алда һәрвакыт телнең авазлар төзелеше өйрәнелергә һәм үзләштерелергә тиеш.

Бер телнең фонетик төзелешендәге тарихи процессны

исәпкә алмау, гомумән, аның үзенә хас якларыннан күз йому булыр иде. Чөнки телнең фонетик төзелешен читләтү, төбендә, „сүзләр теле“ (аваз теле) белән тиешенчә хисаплашмау дигән сүз ул. Д. Белкин һәм С. Фурер иптәшләргә биргән җавабында И. В. Сталин бу мәсьәлә буенча ныклы кисәтү ясады.

„Аваз теле яки сүзләр теле, — ди И. В. Сталин, — һәрвакыт кешелек җәмгыятенең бердәнбер теле, кешеләрнең аралашуларында тулы бәяле чара булып хезмәт итәргә сәләтле бердәнбер тел булган“[1].

Тел тарихы өстендә күзәтүләр ясаганда, аның авазлар системасына без, һичшиксез, И. В. Сталин өйрәтмәсеннән килеп карыйбыз; ягъни без аваз телен бердәнбер тел итеп өйрәнәбез. Авазлар төзелешендәге үзгәрешләр һәм яңалыкларга без шушы тел үсешендәге үзгәрешләрнең органик бер өлеше итеп аңлатма бирәбез.

„Кешелек дөньясы тарихында аваз теле кешеләргә хайваннар дөньясыннан аерылып чыгарга, җәмгыятьләргә берләшергә, үзләренең фикерләүләрен үстерергә, иҗтимагый производство оештырырга, табигать көчләренә каршы уңышлы көрәш алып барырга һәм хәзерге вакытта бездә булган прогресска килеп җитәргә ярдәм иткән көчләрнең берсе“[2], — ди И. В. Сталин.

Аваз теленең тарихи әһәмияте бу билгеләмәдә бөтен тулылыгы белән ачып бирелә.

Татар теле дә үзенең үсеш процессында шактый катлаулы фонетик үзгәрешләр кичергән. Ләкин бу өлкә әлегә бик аз өйрәнелгән, хәтта бөтенләй үк өйрәнелмәгән, дип әйтерлек. Мондагы катлаулылык күп кенә тарихи сәбәпләр белән аңлатыла. Ул сәбәпләрнең иң зурысы һәм иң характерлысы татар теленең бер-берсеннән аермалары шактый сиземле диалектлардан укмашкан булуыннан тора. Моның шулай икәнлеген хәзерге татар теле җирле диалектларындагы фонетик төрлелекләр таныклыйлар. СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институты бастырып чыгарган „Сораулык“та (1949 ел) сузыклар буенча 20—30 вариант, тартыклар буенча исә 45—50 ләп вариант аваз тәңгәллеге күрсәтелә.

---

[1] И. В. Сталин, Марксизм һәм тел гыйлеме мәсьәләләре, 1951 ел, 42 бит.

[2] Шунда ук.

Шуның белән бергә, бу саннар әлегә төгәллектән ерак торалар. Чөнки реаль тулылыкка ирешү өчен, татар телендәге барлык диалект һәм сөйләшләрнең җентекләп өйрәнелгән булуы таләп ителә. Без әлегә аңа ирешмәдек. Бу тәңгәллекләрнең байтагы татар теле формалашу процессындагы шактый еракта калган күренешләрне ачарга һәм дөрес билгеләргә дәлил, таяныч була алалар. Мәсәлән, хәзерге татар телендәге *өй* дифтонгын алып карыйк. Белгәнебезчә, бу инде әдәби норма булып урнашкан: *өй, көй, көйлә, сөй, сөйлә* һ. б. Җирле диалектларда исә моның әле бүген дә *эв* (эv), *ү, и* вариантлары яшәп килә. Мәсәлән, *эвенә* кат'а (миш.); *сүгән яр* (миш.); *сүли, сүләй* (миш., Тау ягы, Минзәлә); *игә кайта* (Дөбъяз, Арча); *силисен* (Әтнә); *кили* (Казан, Яңа бистә) һ. б.

Менә шушы ук вариантларның барысын да диярлек без борынгы язма әдәбият текстларында очратабыз. Мәсәлән, анда *өй* дифтонгын берничә төрле язып киләләр: „Ялан сүз *сүзләмәс*" („Йосыф-Зөләйха"); „Атамыз аны бездин артык *сәвәр*" (шунда ук); „Андин Йосыф җавап *силәр*" (шунда ук); „*Ивенә* кәлде каdгу берлә"; „Мән сәнең берлә бер *ивдә* тормагаймын тиде („Нәһҗ-эл-фәрадис"); „*тәвә* бугазлар", „Мән гаять *сәвендем*", „йөз *тәвә, сәвнеч* бирәен" (шунда ук).

Бу өзекләрдәге *ив* (өй), *тәвә* (дөйә), *сәвнеч* (сөенеч) сүзләрендә *өй* дифтонгы *ив—эв* (اِوْ - اَوْ) формалы кушыклар белән бирелгән.

Шунысы характерлы: „Йосыф-Зөләйха" текстында *өй* дифтонгы өч-дүрт төрле язылган. Һәм мондый алым хәтта XIX йөзгәчә дәвам итә дип әйтергә була.

Мәсәлән, Мөхәммәтьяр (XVI йөз), система рәвешендә, *өй* урынына *ү* һәм *эв* авазлары куллана: „*сүзләю ул* сүзгә кердем мән фәкыйрь" (сөйләп); „Бар ирде бер гасыйның ялгыз кызы, *сәвер* ирде җаны илә бу кызы" (сөяр иде дигән сүз). „*Эвенең* иче хатуннар ирде тулуг" [1] (эве—өе дигән сүз).

Менә шундый язмалар ерак заманнардан бирле *өй* кушыгының төрле диалекталь вариантларда языла килүе турында сөйлиләр.

Дифтонглар формалашуга карата тюркологиядә,

---

[1] Мисаллар Мөхәммәтьярның „Төхфә и мәрдән"еннән алындылар.

башлыча, ике төрле фикер бар. Н. И. Ашмарин: „Кушык сузыклар (анынча, двугласные) сүз уртасында яки аның азагында торган тартыкларның үзгәрүләре (огласения — сузыклашулары) нәтиҗәсендә барлыкка килгән"[1], — ди һәм мисалга *таг — тау, агыз — ауыз* сүзләрен китерә.

Проф. Н. К. Дмитриев фикере дә, түбендә, шул ук карашка кайтып кала. Ул, мәсәлән, башкорт телендәге ау—әү дифтонгларын аг—әг дән, ай—әй дифтонгларын исә „сузык аваз + д" дән ясалганнар дип аңлата[2].

Академик В. В. Радлов „Кодекс-куманикус" телен тикшерү уңаенда, кушыклар (анынча, двугласные) „беренчел" түгел, бәлки соңыннан барлыкка килгән фонетик үзгәреш нәтиҗәсе булып торалар, дигән фикергә килә. „Куман телендә дә, бүтән төрки диалектлардагы кебек үк, кушык сузыклар (двугласные) электән үк килмәгәннәр, бәлки соңыннан, ике сузык яки бер сузык һәм бер тартыкның механик кушылуы нәтиҗәсендә туганнар"[3], — дип аңлата ул, һәм бу телдә формалашкан берничә төрле кушык саный. Алар, башлыча, түбәндәгеләр:

1) уа „тик бер генә тамыр", — ди ул. Мисалы: *куаныц* (куаныч дигән сүз).

2) ау, мисаллары: *таук* (тавык), *чулгау* (чолгау).

3) *ай—äй, ой, уй* дифтонглары. Мисаллары: *äйге* (изге дигән сүз); *тойдыргыл* (туйдыр), *öйгүнец* (үкенеч дигән сүз), *куйрук* (койрык).

В. В. Радловның бу мисаллары күп нәрсә турында сөйлиләр. Беренчедән, кушыклар формалашу гомумән төрки телләрдә, шулардан куман телендә дә шактый борында — XII—XIII йөзләргә чаклы ук башланган була[4], икенчедән, югарыда күргәнебезчә, ул дифтонгларның эволюциясе, хәзерге торышларына килеп җитүләре шактый озак дәвам иткән һәм иң әһәмиятлесе — алар төрле диалектларда берничә вариантта йөргәннәр,

---

[1] Проф. Н. И. Ашмарин, „Заметки по сравнительной грамматике тюркских языков", 1928 ел, 23—25 битләр.

[2] Проф. Н. К. Дмитриев „Башкорт теленең грамматикаһы", 1950 ел, 16—18 битләр.

[3] В. В. Радлов „О языке куманов", 1884 ел, 24 бит.

[4] Искәрмә: В. В. Радлов. Куман (кыпчак, половец) теле, гомумән, Идел-Кама буе татарлары, бигрәк тә мишәрләр теленә якын, дип әйтә. Шул ук китапның 39—41 битләрен кара.

өченчедән, В. В. Радлов китергән мисаллар дифтонглар тууга тартыклар катнашы булганлыкны бик ачык күрсәтәләр. Мәсәлән, *тук—туйдыргыл,* монда *ук→уй* (к→й) дифтонгы килеп чыккан.

Бер сузык һәм бер тартык аваз катнашмасыннан кушык сузык (дифтонг) барлыкка килү, түбендә, кайбер тартык авазларның тел уртасы авазы кыска *й* гә һәм ике ирен катнашы белән ясала торган кыска *уυу* га (v) күчүләре җирлегендә булган. Бу процессны түбәндәге мисаллар белән күрсәтергә мөмкин:

*аз* | *аd*[1] — *ай*: *аdак* | *азак→айак*; *казгы→кайгы; аdыр→айыр, аdырса→айырса; аd→ай*; *аdгур→айгыр, аdгу→айу.*

Менә шушы сүзләрдән икесе (азак, казгы) язма текстларда XVII йөзгә чаклы *аdак* || *азак*, *казгы* формаларында язылып киләләр. Аннан соң тик *айак, кайгы* формаларында гына язылуга күчәләр. Айыр || айырса сүзенең *аdыр* || *азыр, аdырса* || *азырса* формасында d—з белән язылулары XIV йөзләрдә генә очрый.

Й—з (d) авазлары арасында тәңгәллек булу һәм аларның бер-беренә күчүләре бу авазларның әле бүген дә татар теле җирле диалект һәм сөйләшләрдә янәшә йөрүләре белән раслана. Мәсәлән, *йыйылыш* || *зыйылыш* (җыелыш); *йиләк* || *зиләк* (җиләк); *йил* || *зил* (җил); *йук* || *зук* (юк)... кебек сүзләрдә й←→з авазларын тәңгәл йөртү әнә шул борынгылыкның калдыгы булып тора.

Әйткәнебезчә, *айак* сүзен *азак (аdак)* формасында язу XVII йөзләрдән соң дәвам итми, һәм моннан соң болар икесе ике мәгънәгә беркетелеп калалар: *айак*— бер орган (нога), *азак* — соң, оч (конец) дигән төшенчәгә йөри башлыйлар, мәсәлән, *азактан* — соңыннан (после) дигән сүз була.

Шул рәвешчә, бу мисаллардан сүзнең (тамырның) авазларын алмаштырып (й←→з) сүз ясау булганлыгын күрәбез. Үз→үй→өй: сүз→*сүйлә, сөйлә, уз→уй, куз→куй, кузмады→куймады. Сүзлә* формасыннан *сөйлә, сүлә, силә* формаларына күчү XIII йөзләрдән үк башлана, ләкин *сүзлә* дип язу әдәби текстларда XVII йөз

---

[1] d—бу билге белән борынгы тел-теш авазы « ذ » (сакау з) не күрсәтәбез. Шунын белән бергә, дифтонглар составындагы авазлар ачык күренеп торсын өчен, алар аерым хәрефләр белән күрсәтелде.

азакларына чаклы дәвам итә. Мәсәлән, „*Дуадакның өне юк, сүзләмәгә* теле юк“ (М. Колый, XVII йөз).

*Куйды, куйса* формаларын *кузды, кузса* дип язу XIII—XIV йөзләрдән соң очрамый.

*Из→ий: изә→ийә, изәсе—ийәсе.*

*аг→ау: аглак→аулак; агрук→ауру* (к), *агул→ауыл* (авыл)[1].

*ак* ‖ *аг→ау: бозак→бозау; таг→тау; йаг→йау; баг→бау* һ. б.

*аг→ай→әй: баг→бәй, бәйлә.*

*йыг→йый: йыгылу→йыйылу* (жыелу). Мисалы:

„Качан кем, бер мәшурәт кылмак кәрәк булса, ул әвгә *йыгылур* ирделәр“ („Нәһж -эл-фәрадис“, XIV йөз — жыела иделәр дигән сүз).

*гы→йы: сыгыр→сыйыр; тикеш* ‖ *тигеш→тийәш...*

*зы→йы: козык→койы* (к).

Мисаллардан күренә ки, д ‖ з, к ‖ г тартыклары, сузыклар белән тезмәгә керү аркылы, татар теленә *ай—әй, уй, өй, йы, ий* (йә) дифтонгларын биргәннәр.

Авазларның кушыклашулары (дифтонг һәм аффриката булып әверелүләре), гомумән, телнең фонетик төзелешенә хас эчке законлылыклар белән билгеләнә. Артикуляцион базаның ипләшүе һәм көчүе, ассимиляция, диссимиляция, басым, сөйләм ритмикасы һ. б. шундыйлар эчке законлылыкларны тәшкил итәләр.

Янәшә килгән ике сузыкның бер кушык (дифтонг) составына керүләрендә дә әнә шундый басым һәм ритмика кебек законлылыкларның йогынтысы аерата ачык чагыла. Мәсәлән, *килә иде, бара иде* кебек аерым язылышлы кушма фигыльләрне без *киләйде, барайде* дип әйтәбез. Сәбәбе ачык: беренчедән, болар, кушма сүз буларак, уртак бер басымга күчәләр,—*киләйде, барайде;* икенчедән, сөйләм ритмикасы, темп бу ике сүзнең бергә кушылуын таләп итә, һәм, шул жирлектә, ә и, а+и→әй, ай булып әйтелә, ягъни ижек ясый торган *и,* үзеннән алда торган *а, ә* авазларына кушылып кыскара, ижек ясау көчен югалта, һәм *әй, ай* дифтонгы барлыкка килә.

---

[1] С. Е. Малов агул сүзен „загон для скота“ дип анлата. „Памятники древнетюркской письменности“. 1951 ел, 355 бит.

Телдә тагын трифтонг дип атала торган кушыклар да бар. Монысы өч сузык кушылмасыннан тора, ягъни өч сузык бер иҗеккә җыела да, шулардан берсе иҗек ясау көчен саклап, калган икесе аңа кушылып кыскаралар. Татар телендә моның иң ачык үрнәге — *йау* сүзе. Элек бу сүз *йаг* формасында йөргән. Соңыннан, *г* авазы кыска „v" белән алмашынгач, *йау* булган, ягъни *йа* дифтонгына тагын бер кыска сузык өстәлгән дә, *йаг* — *йау* килеп чыккан. Бу үзе бер иҗектән тора һәм трифтонг булып әйтелә: *йау. Йайлак* (җәйләү) сүзендә дә *йай* — трифтонг.

Хәзерге татар телендә саннары белән дә, сыйфатлары ягыннан да чагыштырмача катлаулы төс алган дифтонглар әнә шул рәвешчә барлыкка килгәннәр һәм әдәби телгә норма булып урнашканнар.

Дифтонгларның төзелеш үзенчәлекләрен күзәтү теге яки бу сүзләрнең этимологик тарихларын табарга, ачарга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, хәзерге татар телендә *азау* (теш) дигән сүз бар. Моны кайбер сөйләшләрдә *азу* (теш) дип, кыскартып (*а* ны йотып та) әйтәләр, һәм, шуннан чыгып, бу сүзнең төп мәгънәсе *азу* (азгынлану) төшенчәсенә кайтса кирәк, дип уйлаучылар да юк түгел. Ләкин, асылда, алай булмас: *азау←азак* сүзеннән килә, ягъни *азакы, арткы, соңгы* теш дигән мәгънәне аңлата, моның *азау* формасына күчүе *ак→ау* га әйләнү уңаенда булган. Хәзерге татар телендә *тауык, йауыз* формасында әйтелә торган сүзләр дә борынгы *таг+ок* (→ык), *йаг+ыз* (→ир, кеше) сүзләренә барып тоташалар. Шул рәвешчә, *тауык* ның борынгы мәгънәсе таг (→тау)+*ык* (җәнлек), ягъни тау кошы; *йауыз* исә борынгы *йаг* (→*йау*, ягъни дошман) + ыз (←ир, кеше), ягъни *йау кешесе* (дошман кеше) дигән төшенчәгә кайтып кала.

Теге яки бу авазларның кушык хәлгә күчүләре (дифтонглашулары) сүзләрнең мәгънәләрен үзгәртүгә, ачыклауга хезмәт иткәнме, әллә саф фонетик күренеш кенә булып калганмы? Бу сорауның дөрес җавабы түбәндәгечә булырга тиеш. Кайбер сүзләрнең дифтонглы әйтелешкә күчүләренә карамастан, мәгънәләре үзгәрмәгән. Мәсәлән, *таг→тау, баг→бау, бозак→бозау, саг→сау* (исән-сау) һ. б.

Шул ук *баг* тамырыннан үзгәргән *бәй* сүзе исә үзенең төп *баг* мәгънәсеннән ераклаша төшкән, исемлек

төшенчәсе өстенә фигыльлек мәгънәсен дә алган. Без инде *багла* яки *баула* димибез, *бәйлә* дибез. *Сүз — сөйлә* формасында да шундый ук грамматик категория төсмерен алган үзгәреш бар, чөнки *күзлә, эзлә, ашла, башла* сүзләрен фигыльләштереп булган кебек, *сүз* тамырын турыдан-туры фигыльгә әйләндереп булмый, моның өчен иң элек *сүз⟶сөй* формасына әйләнергә, шуннан соң *лә* өстәлеп, *сөйлә* фигыле ясалырга тиеш. *Тук⟶туйдыр, туйды; туемсыз...* сүзләрендә дә шулай ук.

Менә шундый реаль моментлар, аерым шартларда, дифтонглаштыруның да сүзнең мәгънәсе үзгәрүгә бәйләнешле булуын күрсәтәләр.

Дифтонглар формалашу тарихы күзлегеннән карaганда, татар теленең жирле диалектлары бер-береннән бик нык аерылалар. Урта диалектның Казан арты сөйләшендә дифтонглар һәм саннары, һәм сыйфатлары белән зур гына үсеш алганнар. Көнбатыш һәм көнчыгыш диалектлар исә, киресенчә, монофтонглаштыруны, ягъни бер сузыкка калдырып әйтелешне үстергәннәр. Мәсәлән, *көйлә* (ур. д.)⟶*күлә* (көнб. д.), *кайту* (ур. д.)⟶*кат'у* (көнб. д.), *коймак* (ур. д.)⟶*кимак* (көнб. д.) һ. б.

Хәзерге татар әдәби телендә нормалашкан кушык сузыкларның зур күпчелеге Казан арты сөйләшеннән алынганнар.

Югарыда теркәлгәннәр татар теле фонетик төзелешендәге кушык сузыкларга карата түбәндәгечә йомгак ясарга мөмкинлек бирәләр. Беренчедән, кушык сузыкларны ниндидер „беренчел“ күренеш итеп санарга туры килми. Алар, телнең эчке законнары жирлегендә, соңыннан барлыкка килгәннәр. Татар теле формалашу процессында кушык сузыклар барлыкка килү, язма документларга һәм белгечләрнең күзәтүләренә карaганда, XII—XIII йөзләрдән башлана. Икенче төрле әйткәндә, татар телендәге дифтонглар болгар чорында яшәгән кабиләләр, жирле диалектлар, сөйләшләр теленә барып тоташалар.

Икенчедән, кушыклар формалашуда сузыклар белән тартыклар арасындагы артикуляцион, физиологик мөнәсәбәтнең шактый зур роле булган. Шуның белән бергә, тел чараларының иске сыйфаттан яңа сыйфатка акрынлап күчүләре рәвешендә, кушыклар, билгеле

күләмдә, сүзләрнең мәгънәләрен ачыклауга да хезмәт иткәннәр.

Ниһаять, кушык сузыклар формалашу процессын тарих сызыгында күзәтү сүзләрнең этимологияләрен дөрес ачарга ярдәм итә торган ышанычлы чаралардан берсе булып тора. Һәм бу, И. В. Сталин өйрәткәнчә, телнең күп эпохалар буена эволюцион юл белән үсеш тарихын фактлар өстендә аңларга юл ача.

* * *

Бер яктан, үз күзәтүебезгә, икенче яктан, фән дөньясында теркәлгән фикерләргә таянып, татар телендәге сузык һәм тартык авазларның кайберләре тарихына кыскача экскурс ясыйбыз.

Бу өлкәгә кергәндә, башлыча, түбәндәгеләргә әһәмият бирергә кирәк. Профессор Н. К. Дмитриев: „Башкорт телен башка төрөк телдәренә, шулай ук уның фонетикаһын рус фонетикаһына сагыштырып карау юлы менән, башкорт телендәге һуҙынкы өндәр тарихе буйынса шундай һөҙөмтәгә килеп була. Башкорт теле һуҙынкылары ике категорияга бүленә: боронго өндәр (первичные) һәм сагыштырмаса яңырак өндәр (вторичные). Боронго өндәр категорияһына *ы, ә, а* өндәре инә“[1], — дип яза.

Татар телендәге сузыклар формалашу мәсьәләсенә карата исә, Г. Алпаров шактый кыю һәм үзенчәлекле бер фикер әйткән иде. Аныңча, сузыкларның „беренчел“ чыганагы, „прототипы“ е(э) кебегрәк бер аваз була. Шушы аваздан, ике тармак буенча китеп, калган сузыклар формалашалар. Аның схемасы болай: беренче сызык буйлап е(э) ⟶ а ⟶ о ⟵⟶ у ⟶ ы; икенче сызыктан исә е(э) ⟶ ө ⟶ и авазлары килеп чыга.

Бу тезисларның һәр икесе дә әлегә ачыкланмаган, фактик материаллар белән беркетелмәгән, алар тик гипотеза, ягъни ачылмаган ихтимал гына булып торалар.

Татар теле тарихын өйрәнү белән шөгыльләнгән кешенең төп бурычы — шушы тарихның үз барышында күзәтелгән һәм фактик материаллар белән расланган

---

[1] Проф. Н. К. Дмитриев, „Башкорт теленең грамматикаһы“, 1950 ел 7 бит.

үзгәрешләрне мөмкин чаклы анык итеп ачу һәм билгеле алудан тора. Бигрәк тә мәктәп, укыту практикасында әнә андый чишелмәгән, ачыкланмаган мәсьәләләргә кереп китү көтелгән нәтиҗәне бирмәячәк. Без үзебезнең бу тикшеренүләребезне менә шушы принципка нигезләргә тырыштык.

## III. СУЗЫКЛАР ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ҮЗГӘРЕШЛӘР

### 1. А авазының ике төрле әйтелеш мәсьәләсе: 1) ачык *а*, 2) иренләшмә *ạ*

Хәзерге көнне, фактик материаллардан чыгып, *а* авазы әйтелеше буенча, татар теленең көнбатыш диалектын *алаштыручы*, ягъни *а* авазын ачык (рус *а* сына якын) әйтүче, урта диалектны исә *олаштыручы*, ягъни *ạ*[1] авазын иренләштереп (рус *о* сына тартымрак итеп) әйтүче, дип санау урнашып бара. Бу — очраклы хәл түгел, әлбәттә. Моның төбендә тарихилык ята. Шуның белән бергә, татар, башкорт һәм гомумән төрки телләр буенча фәнни-тикшеренү алып барган теоретикларның бу турыда инде карашлары да теркәлгән дип әйтергә мөмкин. Мәсәлән, Г. Алпаров, татар телендә сүзнең алгы (1, 2, 3) иҗекләрендә ачык *а* гомумән әйтелми, тик соңгы иҗекләрендә генә ул ачык ишетелә, дигән караштa торган һәм үзенең бу аңлатмасын түбәндәге схема белән күрсәткән иде.




[1] Бу төр ạ ны, гадәттә, аңлаешлырак булсын дип, å формасында транскрипцияләү дә бар. Мәсәлән, *бåлåлар*... формасында язалар. Мондагы *о* билгесе *а* ның иренләштерелеп әйтелүен күрсәтә, астына нокта куелган ạ (Н. К. Дмитриев билгесе) да иренләшмә *а* ны белдерә. *Автор.*

Димәк, Г. Алпаровча, татар телендәге *а* авазының ике төрле әйтелеше менә шушы схемада күрсәтелгән „законлылыкка“ нигезләнгән була һәм, „кагыйдәчә“, татар телендә төп сүзләрнең беренче иҗегендә рус телендәге кебек саф *а* авазы булмый. „Бездә беренче иҗектәге *а* авазы һәрвакыт ирен тартуы белән, *о* га якын бер аваз белән әйтелә... *А* авазының ирен тартуы белән „олашуы“ 2 нче, 3 нче иҗекләргә таба киткән саен кими барып, азаккы иҗекләрдә бөтенләй ачылып җитә, саф *а* га әйләнә“[1], — дип билгели Г. Алпаров.

Г. Алпаровның бу „кагыйдәсе“ турыдан-туры механистик карашка кайтып кала, ягъни монда нинди дә булса тарихилык та, аерым сүз, сүз тезмәләренең эчке төзелешләрендә табылырга мөмкин булган интонацион, ритмик, тоник яки башка законлылыклар да исәпкә алынмыйлар. Шунлыктан бу „кагыйдәне“ фәнни нигезләнгән дип булмый.

Профессор Н. К. Дмитриев „Башкорт теленең грамматикаһы“нда бу төр *а* авазына киң генә туктала һәм аның төрки телләр системасында, башлыча, башкорт теле белән татар теленә генә хас икәнлеген әйтә. Бу *а* ны ул „түбәнге-арткы-киң әйтелешле иренләшкән өн“ дип атый һәм моның гадәттәге ачык *а* дан аермасы иренләшүдән, ягъни „үзенең әйтелешендә иреннәрдән өстәмә эш-хәрәкәт таләп итүеннән (лабиализациядән)“[2] тора, дип билгели.

Сүзнең тәүге иҗекләрендә иренләшкән *а* әйтелеп тә, соңгы иҗекләрендә ачык *а* ишетелүнең сәбәбен *басым* көчү аркасында булырга кирәк, дип аңлата Н. К. Дмитриев (шунда ук, 9 бит).

Проф. В. А. Богородицкий, борынгы төрки теленең *а* авазы татарча әйтелешендә сизелерлек үзгәрмәгән, беренче иҗектә аның („а“ ның) бераз иренләшүе, бәлки, артикуляциясе тирән — арткы булуыннан килә торгандыр, дип әйтү белән чикләнә[3].

В. А. Богородицкийның шунда ук, җәя эченә кертеп: „Мишәр сөйләше бу урында хәтта *о* га якын

---

[1] Г ы й б а д А л п а р о в, „Сайланма хезмәтләр“, 1945 ел, 46 бит.

[2] П р о ф. Н. К. Д м и т р и е в, „Башкорт теленең грамматикаһы“, 1950 ел, 8 бит.

[3] П р о ф. В. А. Б о г о р о д и ц к и й, „Введение в татарское языкознание...“, 1934 ел, 36 бит.

аваз әйтә“, — дигән тезисы дөреслектән ерак тора, ул монда мишәрнең *у* урынына *о* әйтүен бутаган булырга тиеш. Чөнки, киресенчә, мишәрдә *а̣* (олашкан *а̣*) инде бөтенләй калмаган. Н. К. Дмитриев та: „Әйтергә кирәк, мишәр диалекты *а̣* авазын бөтенләй белми“, — дип яза (шунда ук, 9 бит). Шуның белән бергә, *а̣* ның, татар һәм башкорт телләреннән кала, бүтән төрки телләрдә күзәтелмәве дә теркәлә.

Н. К. Дмитриев: „Төрөк телдәренең калгандарында *а̣* өнө иҫәпкә алынмаган“, — ди (шунда ук, 9 бит).

Н. А. Баскаков хезмәтләре дә шуны раслыйлар. Мәсәлән, ул үзенең турыдан-туры күзәтүе буенча, нугай телендә *а* авазының ачык, ягъни иренләшми әйтелүчән булуын терки[1].

Ләкин без, гомумтатар теле һәм аның диалектларыннан чыгып, кечкенә генә бер төзәтмә кертергә тиешбез. Н. К. Дмитриев иренләшмә *а̣* авазы „башкорт әҙәби теле һәм диалекттәре өсөн генә түгел, бәлки татар әҙәби теле һәм диалекттәре өсөн дә характерле“, — (шунда ук, 8 бит) дигән тезис куя. Безнеңчә, аның бу тезисы төзәтмәгә мохтаж һәм үз-үзенә каршы килә. Чөнки югарыда күргәнебезчә, ул үзе дә мишәрләрдә иренләшмә *а̣* ның бөтенләй булмавын әйткән иде.

Иренләшмә *а̣* ның хәзерге татар телендәге торышын тулырак ачыклау аның җирле диалектларын җентекләп өйрәнү ярдәмендә генә була ала. Соңгы елларда ясалган тикшерүләр бу вариант *а* ның яшәеше турында түбәндәге мәгълүматларны бирделәр. Көнбатыш диалект вәкилләре әйтелешендә *а̣* ачык, ягъни иреннәр катнашыннан башка әйтелә. Мәсәлән, *карга, багана, балалар*... Урта диалектның Нократ-Кистем сөйләшендә иренләшмә *а̣* тулы саклanмаган, алар әйтешендә *а* авазы билгеле позицияләрдә, үзенә бертөрле нечкәлек белән, *ә* авазына тартымрак ишетелә; *ә* исә, билгеле булганча, иренләшмә аваз түгел. Ләкин Нократ-Кистем сөйләшендәге бу *а* ны мишәр *а* сы белән охшаш, ягъни боларны бер-беренә тигез авазлар итеп

[1] Н. А. Баскаков, „Ногайский язык и его диалекты“, 1940 ел, 7 бит.

карау дөрес булмас. Нократлылар сөйләшендәге *а* — эксперименталь анализ таләп итә торган үзенчәлекле бер аваз дип әйтергә була.

Чын-чыннан иренләшмә *а* авазы татар теленең урта диалектына караган Казан арты, Минзәлә һәм Тау ягы сөйләшләренә хас күренеш булып тора. Мәсәлән, мишәр әйтешендә *бала, балаларга, кала*; *карәле* (кара әле), *кая барасын*, ягъни ачык һәм өлешчә йомшартылган а белән ишетелә торган сүзләр урта диалект вәкилләре сөйләмендә *бала, балаларга, кара*, *карале* булып, олаштырылган иренләшмә *а* белән әйтеләләр.

Менә шушы төрлелекнең тарихи нигезен эзләп табу өчен, В. А. Богородицкий кулланган методтан файдалану мөмкин булыр кебек сизелә. Ул метод исә татар телендәге *а* авазы белән чуваш телендәге тәңгәлләрне табуга нигезләнгән. Татарның *а* сы урынына чуваш телендә *о—у* авазлары килә. Мисаллар (В. А. Богородицкий мисаллары, 38 бит): „татарча — *б.ш* (голова), чувашча — *пос*". Тагын берничә мисал өстик:

| | | | |
|---|---|---|---|
| Татарча: | *табыш* | чувашча: | *тупыш* |
| „ | *талаш* | „ | *тулаш* |
| „ | *тайак* | „ | *тойа(к)*... |

Мисаллардан күренгәнчә, татар *а* сына чувашның *о—у* авазлары, ягъни ирен авазлары тәңгәл киләләр. Бу исә, беренчедән, ерак тарихка, барыннан да элек, болгар чоры төрки кабиләләре теленә барырга юл ача. Чөнки чуваш теле Идел-Кама болгарлары чорында бер диалект була. Һәм чуваш теле андагы үзенчәлекләрне чагыштырмача тулырак саклаган да.

Шуның белән бергә, бу чагыштырма, безнең уебызча, татар теленең урта диалектында сакланган иренләшмә *а* ның шулай ук болгар чоры кабиләләре теленнән килүе турында уйларга мөмкинлек бирә. Монысы — беренчедән.

Икенчедән, мәсьәләнең мондый планда чишелеше, „был өн (*а* авазы, Л. Ж.), асылда, *о* ның кайһы бер элементен эсенә алган шул ук *а* икәнлеген күрһәтеп тора..."[1] дигән әһәмиятле бер фикерне киңрәк итеп

[1] Н. К. Дмитриев, „Башкорт теле грамматикаһы", 1950 ел, 8 бит.

куярга мөмкинлек бирә; ягъни татар теленең урта диалектында сакланган иренләшмә *a* үзенең тарихында борынгы *о* авазының алашып, ачылып бара торган варианты итеп карала ала.

Уебызча, мондый гипотезаны кую урынсыз булмаячак. Чагыштырма-тарихи метод белән эш иткәндә, бу гипотезаның уңай чишелүен өмет итәргә мөмкин.

Иренләшмә *a* ның иренсезләнү процессын кайберәүләр сүзләрнең баш өлешендәге икенче дәрәҗә басым йомшару аркылы килгән дип аңлаталар. Бу караш бөтенләй үк әһәмиятсез түгел, чөнки басымның гомумән сузыклар әйтелешенә йогынтысы зур. Ләкин монда шуны онытмаска кирәк, татар телендә (урта диалектта) *a* ның иренләшмә торышы басымсыз иҗекләрдә килеп тә, басымлы иҗекләрдә ул ачык, иренсез әйтелә. Мәсәлән, *багана́*, *карага́й*. Димәк, басым көчүенең бу очракта йогынтысы сизелми.

Иренләшмә *a* ның иренсез ачык а га әверелүе күп фактлар белән аңлатылырга мөмкин. Беренчедән, аның ясалыш урыны (артикуляцион базасы) акрынлап күчү, үзгәрү аркасында була ала. Икенчедән, гомумән, теге яки бу аваз әйтелешендәге үзгәреш аның икенче бер авазлар белән комбинатор мөнәсәбәткә керүеннән дә баглы. Мәсәлән, *бел* сүзендә е (э) авазы шактый ачык ишетелә, *бер* сүзендә исә ул бераз йомшара (редукцияләнә). Басым урыны алмашыну уңаенда, шул ук сүзләрдәге е (э) нең бөтенләй йотылуы да бар: *блә*, *блём*, *блёш* (знакомый); *брәү*, *брёк*... кебек сүзләрнең беренче иҗекләрендә е (э) ишетелми.

Өченчедән, фәндә расланганча, бер үк телнең төрле диалект, сөйләшләрендә теге яки бу авазларның ясалыш һәм әйтелешләре төрле төсмер алган булырга мөмкин, һәм ул шулай да. Моның ачык мисалын к—г авазлары әйтелешендә күрәбез; урта диалект әйтешендә к — г — тирән тел арты авазы, көнбатыш диалектта исә болар тел артына күчкән һәм сиземле генә ачылган (рус к сы әйтелешен алган) аваз булып торалар.

Шунсы характерлы: менә бу аерма к—г әйтелеше белән генә чикләнми, бәлки аерым сүзләр әйтелешенең бөтен күләменә йогынты ясый. Түбәндәге мисал-

лар шуны күрсәтәләр. Урта диалектта *Къазан*[1], көнбатыш диалектта *Казан* (шәһәре) дип әйтәләр. Мондагы ике вариант *к* ның үзеннән соң килгән *а* әйтелешенә йогынтысы сизелеп тора, беренчесендә *а* иренләшә, икенчесендә иренсезләнә, ачыла. Моны дәлилли торган икенче бер фактлар да бар. Мәсәлән, гомумтатар телендәге *коймак* (урта диалект *къоймак*) көнбатыш диалектның кайбер сөйләшләрендә *кимак* формасында *к* ны *к*ᶦ гә, *ой* ны *и* гә күчереп әйтелә. Әдәби язылышы *күпер* формасында йөртелә торган сүз урта диалектта *купер* дип, к ны русча *куб* сүзендәге *к* итеп һәм *ү* не *у* белән алмаштырып әйтелә, көнбатыш диалектта исә бу сүз *күперь* дип, *к* не дә нечкәртеп һәм нечкә *ү* белән әйтелә.

Гомумтатар телендәге *кайҗиргә* (кая, кай яры мәгънәсендә) формалы сүз урынына көнбатыш диалектының кайбер сөйләшләрендә *к'ар'е* диләр. Бу сүздәге *к, а, р*, чагыштырмача, нечкә әйтеләләр. Димәк, *к* ның нечкәлеге *а* га, *а* ның нечкәлеге, үз чиратында, *р* авазына йогынты ясый[2].

Шул рәвешчә, бу мисаллар авазлар әйтелешендәге төсмерләрнең барлыкка килүе аларның төрле комбинацияләргә керүләре җирлегендә булганлыгын күрсәтә.

Ниһаять, гомумән бер телдәге яки аның диалектларындагы үзенчәлекләрне тикшергәндә, тышкы фактларны да исәпкә алмый булмый. Тышкы фактларга культура үсеше, икенче бер халыклар белән аралашу кебек иҗтимагый, тарихи моментлар керә. Мәсәлән, соңгы утыз ел арасында татар теленә рус, Европа телләренә хас о, э, е авазлары кереп активлаша башлады. Элек заманда русның *подвал* сүзе татар теленә *пудбал* булып урнашкан булса, безнең заманда русча *совет* сүзе, нәкъ Москва әйтешендәгечә, *савет* булып урнашты. Шулай булгач, мишәр артикуляциясендә к—г, л — р авазларының йомшаруларына, *а* ның ачылуына рус теле культурасының йогынтысы булган дип уйларга тарихи нигез юк түгел.

Бу уңайда түбәндәге бер фактны теркәп узу урын-

---

[1] *къ* билгесе тел арты тирәнлегендә, бугазда ясала торган *к* ны күрсәтә.

[2] Тартык авазларның уң ягына куелган текә сызыкча (ʹ) аларның нечкә әйтелүләрен белдерә, мәсәлән, *к'ар'е*.

сыз булмас. Татарның иске дини мәдрәсәләрендә гарәп телен көчләп-көчләп укыткан заманнарда „укымышлы“ дип аталган кешеләр сөйләменә дифтонгсыман (дифтонгоид) *ә* (йә) урнашкан була. Мәсәлән, хәзерге көнне *Камал* формасында языла һәм әйтелә торган сүзләрне *Кәмаль* дип, *к* дән соңгы сузыкны *а* белән *ә* арасында ишетелә торган һәм *й* элементы катнаш бер аваз итеп әйткәннәр. *Сәлам*, *сәгать*... кебек сүзләрдәге *ә* дә шундый ук аваз була. Хәзерге көнне мондый авазның барлыгын хәтта тел белгечләре сөйләшеннән дә сизә алмыйсың. Бу бик табигый, чөнки моның саклап килерлек сәбәбе дә һәм хаҗәте дә юк. Хәзер инде *Камал, сәгать, каләм* кебек сүзләр татар теленең үз фонетик төзелешенә буйсындырылалар.

Рус теле фонетик төзелешенең татар теленә йогынтысы шулай ук бик күптәннән килә. Ләкин бу йогынты татар теленең аерым диалектларына карата төрлечә булган, мәсәлән, көнбатыш диалектка көчлерәк, урта диалектка йомшаграк. Хәзерге көнне рус теле безнең икенче туган телебез булып тора. Шул җирлектә без аңа хас фонетик төзелешне төгәл үзләштерәбез, һәм бу хәл, законлы рәвештә, телебезнең фонетик төзелешенә яңалыклар кертә, аның үсешенә уңай йогынты ясый.

Кыскасы, телдәге кечкенә генә үзенчәлек, үзгәрешләр дә киң аңлатма таләп итәләр. И. В. Сталин күрсәткәнчә, телдәге законлылыкларны аның иҗатчысы булган халык тарихы белән бәйләнештә өйрәнгәндә генә дөрес аңларга мөмкин.

Шулай, хәзерге татар телендә яшәешләрен дәвам иттерә торган *а* (иренләшмә) һәм *а* (иренсез) авазларының тарихы борынгы болгар һәм кыпчак кабиләләренә барып тоташа. Мишәр *а* сы — төрки халыкларның кыпчак (куман) дип аталган төркеменә хас аваз, *а* исә Идел-Кама болгарлары, борынгы башкорт һәм чуваш кабиләләренә хас, дип аңлату дөрес булыр.

Татар теле тарихында бу *а* лар беркайчан да икесе ике фонема, ягъни ике мәгънә бирә торган аваз ролен үтәмәгәннәр, тик диалекталь вариантлар булып кына килгәннәр. Хәзерге әдәби тел орфографиясендә дә болар аерылмыйлар, ягъни әле бүген дә диалекталь вариант килеш кенә дәвам итәләр.

## 2. *О—ө* һәм *у—ү* авазлары формалашу мәсьәләсе

Хәзерге гомумтатар телендә *о—ө* хәрефләре белән языла торган арткы һәм алгы рәт иренләшмә сузыклар яшәп килә. Бер яктан, тарихи фактларга, икенче яктан, хәзерге җирле диалектларда сакланган тел материалларына караганда, бу авазларның тагын чагыштырмача арткырак рәт иренләшмә вариантлары да булган. Бу ике төрнең аермасы транскрипциядә *о̄ — ө̄* һәм *о̆ — ө̆* билгеләре белән күрсәтелә. Боларның артикуляцион (ясалыш) һәм акустик (әйтелеш) аермалары исә түбәндәгедән тора: *о̄ — ө̄* вариантлары авыз куышлыгының түрендәрәк, борын куышлыгына якынрак урында ясалып, һава тирбәлеше ягыннан бераз гына борын авазы яңгырашын алалар, боларның ясалышына тел пассиврак катнаша — ятма торышын саклый, һәм аскы ирен, үз хәлендә калып, өске иреннең бөрешүе түбәнгә таба тартыла, ниһаять, бу авазлар, сузыла төшеп, үзләренә басым алып әйтеләләр. Мәсәлән, о̇лым (улым), о̇т (ут), ө̇лде (үлде); *о̆ — ө̆* (хәзерге *о—ө*) вариантлары исә — арткы һәм алгы (кыска) иренләшмә авазлар. Болар авыз куышлыгының чагыштырмача алгырак өлешендә, телнең билгеле хәрәкәте катнашында һәм ике иреннең дә алга сузылуы белән ясалалар, әйтелешләре дә бераз кыска була, мәсәлән, *о̆ло̆* (орф. олы), *ө̆лө̆ш* (орф. өлеш) һ. б.

Бу авазлар, шул рәвешчә, беренче пар варианттан шактый сиземле аерылалар. о̄ — (ө̄) ләрнең рус *о* сына якын әйтелешләре көчлерәк һәм тулырак.

Төрки телләр өстендә фәнни күзәтүчеләрдән берсе булган П. М. Мелиоранский борынгы телдә әнә шушы ике вариант о—ө авазлары булуына ишарә ясый һәм кайбер аңлатма да бирә. Ул үзенең „Араб — филолог...“ (XXVII бит) дип аталган хезмәтендә авторның (Ибне Мөһаннаның) او хәрефе белән күрсәтелгән фонемаларны дөрес ачканлыгын әйтә. Мәсәлән, ул اوت сүзенең автор тарафыннан биш мәгънәдә йөртелгәнен ачып бирә.

1) اوت — уенда *от* (транскрипция белән *ŏт* языла).

2) اوت — („с неясным произношением вава“).

Хәзерге татар телендә ут — чүп үлән мәгънәсендә йөри торган *ōт* булган була.

3) اوت — „железы“, безнеңчә, *ут*, мәсәлән, *уте* шешкән мәгънәдә, *ө̄т* булырга тиеш.

4) اوت — үтеп китү, *уткен* сүзенең тамыры, *ут* була.

5) اوت — хайван йонын өтү, ө̆т була.

Бу схемага без алтынчы „ اوت “ ны да арттырабыз, анысы ут (огонь) мәгънәсендә була. Бу бик табигый һәм Мелиоранский үзе дә او хәрефен у — ү, ō — ө̄, ŏ — ө̆ (ӱ) хәрефләре белән билгеләгән.

Югарыда китерелгәннәр *о—ө* авазларының борынгы төрки телләрдә икешәр вариант әйтелешләре булганлыкны раслыйлар, дип әйтә алабыз.

Хәзерге татар телендә соңгы елларда бу сузыкларның берәр генә варианты калуы, арткы *о—ө* вариантларының исә тик көнбатыш диалектка караган Сергач һәм тагы кайбер сөйләшләрендә генә сакланганлыгы ачылды.

Р. Ф. Шакирова үзенең диссертациясендә *ō—ŏ, ө̄—ө̆* авазларының әле бүген дә Горький өлкәсе мишәрләре сөйләшендә *ōт* (огонь), *ŏт* (уйнап от) һәм *ө̄леш* (үлеш, үлешү, үлем), *ө̆леш* (доля, өлеш) мәгънәләрен тәгъбир итүгә йөргәнлекләрен ышандыргыч дәлилләр белән күрсәтте.

Югарыда күрсәтелгән фактлардан чыгып, без, татар теле формалашу тарихында хәзерге *о—ө* авазларының *ō—ŏ, ө̄—ө̆* вариантлары булган, һәм алар фонематик функция үтәгәннәр, дип әйтергә хаклыбыз.

Алга табарак китеп, бу авазларның эволюциясенә, үзгәрү процессларына күз салыйк. Тюркологларның бу турыда әһәмиятле генә фикерләре бар. Академик

В. В. Радлов, куман телен тикшерүеннән чыгып, бу чорда әле (XIII йөзләр) куман телендә о ның у га күчүе булмаган, дип әйтә (13 бит). Ул моны берничә телдән алынган чагыштырма фактлар белән беркетә.

**Без аның ул чагыштырмасын түбәндәгечә китерәбез:**

| | Алтайларда | Кыргызларда | Куманнарда | Казан татарларында |
|---|---|---|---|---|
| игра | оен | оен | оен | уен |
| наперсток | оймак | оймак | оймак | уймак |

Бу чагыштырма, беренчедән, В. В. Радловның үзе әйткәнчә, куман (кыпчак) диалектындагы сузыклар көнчыгыш һәм көнбатыш төрки телләренә якын булганлыкны күрсәтә, икенчедән, безнең өчен иң әһәмиятлесе, Идел-Кама төрки халыкларындагы сузыкларның ерак тарихтан ук нинди үзенчәлекләре булуын ачыкларга ярдәм итә, өченчедән, Идел-Кама төркиләре телендә борынгы төрки *о* авазының ачык *у* га күчүе, үз чиратында, о—у авазлары арасында тәңгәллек булу турында сөйли.

В. А. Богородицкий, гомумән, татар телендәге сузыкларның борынгы төрки телдәге һәм борынгы язма документлардагы сузыклардан үзгәргән булуларын әйтә. Шул күзлектән карап, ул, борынгы урта сузыклар татар телендә тарайганнар, мәсәлән, *ä*—→*и*, *о*—→*у*, *ө*—→*ү* һәм, киресенчә, тар ирен авазлары *у*—→*о*, *ү*—→*ө* гә күчеп киңәйгәннәр, дип саный[1]. Ул үзенең бу фикерен түбәндәге чагыштырмалар белән дәлилли:

| Борынгы төрки | Татарча | Алтайча | Казахча | Төркмәнчә |
|---|---|---|---|---|
| ө | үл (умри) | өл | өл | өл |
| о | тун (шуба) | тон | тон | дон |
| у | тор (стой) | түр | түр | дур |
| ү | көн (день) | күн | күн | гүн |

[1] В. А. Богородицкий, „Введение в татарское языкознание...", 1934 ел, 35—36 битләр.

Димәк, В. А. Богородицкий о⟷у күчешен, В. В. Радлов кебек, бер яклы гына карамый, бәлки, кара-каршы булган итеп таный. Һичшиксез, болай аңлату дөресрәк, тарихи яктан чынбарлыклырак, чөнки авазлар арасындагы тәңгәллек, төбендә, шушындый икеяклылыкны таләп итә. Мәсәлән, татар телендә з—җ авазлары тәңгәлләр, шул нигездә, русча о з и м о й сүзе татарча *уҗым* булып урнашкан. Татарның „Җылан тавы" дигән сүзен рус галимнәре „Зилантова гора" дип атыйлар. Шуның белән беррәттән, татарның гомумхалык телендә *җил, җиләк, җыелыш, кәҗә...* кебек җ белән урнашкан сүзләр аның кайбер сөйләшләрендә *зил, зиләк, зыелыш, кәзә* дип, зеләштерелеп әйтеләләр.

Шул рәвешчә, без о⟷у, ө⟷ү авазлары үзара күчешкәннәр дип әйтә алабыз. Хәтта алаи гына да түгел, шул ук вакытта о—ө һәм у—ү авазлары арасында да күчешү булган һәм хәзер дә бар. Мәсәлән, *бу көн⟶бүген* һ. б. Монда семантик аерма да бар.

О⟷у арасында кара-каршы күчеш булганлыгын борынгы *огол* сүзенең *ул* га күчүе һәм, киресенчә, *бу* сүзенең *моңа, мондый, бусы⟶монсы* формасына күчү фактлары да бик ачык күрсәтеп торалар.

Н. К. Дмитриев „Башкорт теленең грамматикаһы"нда *о—ө* авазларына киң генә анализ ясый, аларның башкорт, татар телләренә хас булуларын әйтә һәм, тарихи яктан, бу авазлар у—ү ләрнең акрынлап иренсезләшүләре уңаенда килеп чыкканнар дип аңлата (9—12 битләр).

Бу уңайда Н. К. Дмитриевның бик әһәмиятле бер кисәтүен дә исәпкә алырга кирәк. О авазы турында ул, кыпчак тибындагы башка төрки телләрдә (казак, нугай һ. б.) мондый авазның үзе юк, тик моңа бераз якынрак торган аваз гына бар[1], дигән нәтиҗәгә килә. Аның бу күрсәтмәсе, безнең уебызча, мәсьәләне киңрәк һәм тирәнрәк алып чишәргә ярдәм итә, ягъни югарыда китергән *о̄—ŏ, ө̄—ө̆* вариантларының соңгырак чорда нинди күчешләргә очраган булуларын ачарга, гомумән болар арасындагы тарихи субүләрне табарга юнәлеш бирә.

---

[1] Н. К. Д м и т р и е в, „Башкорт теленең грамматикаһы", 1950 ел, 9 бит.

Иң элек бу урында югарыда китерелгән материалларның башлангыч йомгагын ясыйк. Димәк, о—у, ө—ү авазлары арасындагы күчешкә карата өч белгеч өч төрле аңлатма бирә: В. В. Радловча, о⟶у, ө⟶ү килеп чыга, В. А. Богородицкийча, *о⟷у*, *ө⟷ү* кара-каршы күчешкәннәр, Н. К. Дмитриевча, *у⟶о*, *ү⟶ө* гә күчкән була.

Бу процессның тарихи субүләрен дөрес билгеләү, фикеребезчә, түбәндәге ике төп моментның ачыклануына бәйләнгән.

Беренчедән, нәкъ В. А. Богородицкий әйткәнчә, *о—у*, *ө—ү* авазлары үзара күчешкәннәр, мәсәлән, *ту ⟶ токым* (у⟶о), *бодон ⟶ буын* (о⟶у); *коры ⟶ куыр* (ку⟷ко); *төп ⟶ түбә* һәм *тәбәнәк* (ө⟶ү⟶ә).

Мондый күчешләрнең төбендә, бер яктан, телнең аваз төзелешенә хас эчке законлылыклар, мәсәлән, авазларның комбинатор үзгәрешләре, ритмика, аһәң, басым, сөйләү органнарының җайлашуы, камилләшүе, артикуляцион базадагы үзгәрешләр, икенче яктан, шуңа бәйләнешле рәвештә, фонемалар аныклану күренешләре ята.

Икенчедән, хәзерге көнне татарның көнбатыш диалекттагы кайбер сөйләшләрендә (Сергач, Пенза һ. б. сөйләшләрдә) сакланып калган *о̄—ө̄* фонемаларына, барыннан да элек, тарихи яктан килеп карарга тиешбез. Югарыда күргәнебезчә, Н. К. Дмитриев, кыпчак тибына кергән төрки телләрдәге *о—ө* авазлары хәзерге татар, башкорт телләрендәге *о—ө* авазларына бәрабәр түгелләр, дип аңлата. Төп мәсьәлә дә шунда: гомумтатар телендәге бүгенге *о—ө* авазлары белән көнбатыш диалект сөйләшләрендә сакланган *о—ө* авазлары арасындагы тарихи якынлык һәм аерманы ачарга кирәк. Шуңа ирешми торып, мәсьәлә чишелми.

Безнең ышануыбызча, борынгы төрки телләрдәге, шулар арасыннан куман телендәге *о—ө* авазлары, мөгаен, әнә шул арткы *о̄—ө̄* ләр булалар. В. В. Радловның куманча *оен*, А. П. Мелиоранскийның борынгы *о̄т* (үлән), В. А. Богородицкийның *йо̄л* (юл) сүзләрендәге *о̄* авазын да без шундый ук аваз дип билгелибез. Бу, һичшиксез, безне чынбарлыкка якын китерә һәм хәзерге татар телендәге *о—у*, *ө—ү* авазларының төп чыганагын табарга юл ача. Түбәндә, бу авазларның һәр

ике пары да, ягъни *о—у* һәм *ө—ү* авазлары әнә шул борынгы арткы о̄—ө̄ авазларының үзгәреш нәтиҗәсе булып торалар. Куман телендәге *оен* сүзенең (В. В. Радлов мисалы) татарда *уен* га күчүе дә һәм Алтай телендәге йол сүзенең (В. А. Богородицкий мисалы) татарда *йул* булып әйтелүе дә шул турыда сөйли, әлбәттә.

Хәзерге гомумтатар телендә *у* белән әйтелә торган *дус* сүзен Пенза мишәрләренең *до́стым* дип әйтүе дә моңа ачык мисал була ала. Монда тагын шуны да абайларга кирәк: Пенза өлкәсендәге Шокша авылы татарлары бу сүзнең басымын да әле беренче иҗектә саклаган. Мәсәлән, анда „Кая барасын, *до́стым?*" — дип әйтәләр.

Борынгы телдәге арткы-киң-ярым иренләшмә *о̄* дан арткы кысык-тулы иренләшмә сузык *у* ның формалашуы туры гына килеп чыкмаган, чөнки *о̄* белән *у* уртасында, аралык булып, *о̆* авазы тора. Һәм ул баскыч *о̄глым* ⟶ *о̄лым* ⟶ *улым* схемасында бик ачык күренә. Хәзерге татар телендә бу өч әйтелешнең өчесе дә бар әле. Гомумтатар телендә *улым*, Пенза татарларында *о̆лым*, Сергач татарларында *о̄лым* дип әйтелә; соңгысы *о̆лым* дисә, *олысы* (старший) була. Монысы бер яктан. Шулай ук хәзерге татар телендә бер төркем сүзләрнең у һәм о белән, ягъни икешәр вариантта әйтелеп йөрүләре дә моңа дәлил була ала. Мәсәлән, *шоның—шуның, шунда — шолай, шонсы — шунлыктан... бутка — ботка, улау — олау* һ. б.

Аннары тагын бер характерлы тарихи фактны исәпкә алырга кирәк. Борынгы чорда рус теленнән кергән сүзләрдәге о (рус о сы) татар телендә у белән алмаштырылган. Мәсәлән, *подвал* ⟶ *пудбал, болото* ⟶ *мулата, молоток* ⟶ *малатук* (мишәр), *потолок* ⟶ *путалак* (мишәр), *борозда* ⟶ *буразна* һ. б. Менә бу хәл, ягъни рус о сының татарча у га әйләнүе борынгы төрки *о* ның хәзерге у га тәңгәл булуын раслый. Чөнки куман о сы (шартлы рәвештә шулай атыйк) 75—80% рус о сына якын тора, боларның артикуляцион базалары бер-беренә бик якын.

Менә шушы фактлар мәсьәләне ышандырырлык ачалар, булса кирәк. Инде борынгы куман (шартлы)

*ō* сыннан *ŏ* һәм *у* авазлары ясалуның физиологик ягы турында бер-ике сүз әйтик. Борынгы *ō* — авыз куышлыгы тирәнлегендә, борын куышлыгы тирәсендә ясала торган аваз. Тел гыйлемендә билгеле булганча, авазларның артикуляцион базасы гомумән алгарак күчкән. Һәм мондый процесєның булганлыгы татар теленең үзендәге күп кенә фактлар белән дә раслана, мәсәлән, бугаз тирәнлеге, тел арты куышлыгында ясалган каты *къ* авазының хәзерге көнне инде тел арты авазына күчеп баруы (мишәрдә бигрәк тә) шуны күрсәтә.

*Ō* авазы да нәкъ шундый процессны уздырган, ягъни аның да артикуляцион базасы күчкән һәм катлауланган. Конкрет алганда, ō авазы авыз куышлыгының алгырак өлешенә күчкән, ияк хәрәкәте өскә һәм алгарак чыгу белән бергә, аскы иреннең дә алга сузылуы көчәеп, урта-кыска-иренләшмә ŏ авазына әверелгән. Шул ук уңайда, артикуляцион базаның тагын да алгарак күчүе һәм, ияк кысыла төшеп, иреннәрнең алга сузылуы көчәеп, кысык-озын-иренләшмә *у* барлыкка килгән. Шулай итеп, *ō*⟶*ŏ*⟶*у* күчеше булган.

Бу процесста фонетик басымның соңгы иҗеккә күчүе дә роль уйнаган. Борынгы төрки телләрдә басымның күбрәк алгы иҗекләрдә булып та, соңыннан сүзнең азаккы иҗегенә күчүе турында инде лингвистикада кайбер фикерләр әйтелгән.

Монда тагын шуны да өстәргә кирәк, күп кенә сүзләрдән бугаз авазы *къ—гъ* ларның төшеп калуы борынгы арткы *о* ның алгарак күчүенә билгеле күләмдә сәбәпче булган дип уйларга урын бар. Чөнки моның шулай икәнен хәзер көнбатыш диалектта, к йомшау аркасында, сузыкларның йомшак, нечкә вариантлары активлашып барудан да бик ачык күрәбез. Мәсәлән, урта диалектның калын *къ* белән әйтелә торган *къояш, къыйный* кебек сүзләрен көнбатыш диалектта *кияш, киный* дип нечкәртәләр.

Шулай булгач, *оглан, огыл, йыгла*... кебек сүзләрнең, *г* төшеп яки алмашынып, *олан* || *ылан, ул, йыла* формаларына калуларын әнә шул фактның бер күренеше итеп санарга мөмкин.

Без монда *о—ө* һәм *у—ү* парлары арасындагы үзара чиратлашу мәсьәләсенә тукталмыйбыз, мәсәлән, *йул* ⟶ *йүләр, йүнсез* (юлсыз дигән сүз), *йүнәлеш*... Мондый

күренешләр, бер яктан, авазлар гармониясе, эчке аһәңлелек, ассимиляция моментлары, икенче яктан, болар арасындагы тарихи тәңгәллек һәм фонематик бүленеш нәтиҗәсе булып торалар.

Шулай итеп, безнең уебызча, $\bar{o} \rightarrow o \rightarrow y$ авазлары формалашуга карата белгеч-тюркологларыбыз тарафыннан әйтелгән, теркәлгән фикерләрне әнә шундый аңлатма белән йомгакларга мөмкин.

### 3. Сузыклар гармониясе яки иренләшү охшашлыгы

Тюркологик әдәбиятта „иренләшмәле тартылыш", „сузыклар гармониясе", „сингармония" терминнары белән атала торган мәсьәләгә зур урын бирелгән, күп кенә белгечләр болар турында байтак тикшеренгәннәр, һәм бу төр үзенчәлекнең тик төрки телләр фонетикасына гына хас икәнлеген дә ачканнар. Шуның белән бергә, бу күренешнең тышкы төзелеше, табигатенә карата берберенә капма-каршы ике фикер дә туган. Берәүләр моны, ягъни сузыклар арасындагы гармоник охшашлануны саф механик, акустик момент кына дип билгеләгәннәр, икенче берләре исә, киресенчә, бу күренешнең эчтәлек белән, телнең логикасы белән бәйләнеше бар дип аңлатканнар.

Ниһаять, иренләшмә сузыклармы яки иренсез сузыклармы борынгырак дигән сорау тирәсендә дә галимнәр фикер көрәштергәннәр. Бу мәсьәлә борынгы текстларның транслитерациясе (күчереп язу) ничек булырга тиешлек проблемасын чишү уңаенда килеп чыккан. Ф. Е. Корш борынгы текстларда сыйфат ясагыч кушымча функциясен үтәгән *лык—лыг* ны *лук—луг* формасында, ягъни иренләшмә сузык *у* белән язарга тәкъдим иткән, П. М. Мелиоранский, киресенчә, *лк—лг* (лык—лыг) дип, иренсез сузык белән язуны дөрес санаган.

Ф. Е. Корш үзенең бу карашын борынгы чорда (орхун язмалары чорында) *у* белән *ы* әле аерылып, мөстәкыйль авазларга әверелеп җитмәгән булалар дип дәлилләргә тырышкан. В. В. Радлов иренләшмә кин сузык $\bar{o}$—$\bar{ө}$ авазлары, көньяк һәм Урта Азия төркиләре шивәләрендәге кебек үк, куманнарда да сүзнең тамыр иҗекләрендә генә киләләр дип билгели (18 бит), һәм,

шуңа бәйләп, „иренләшмәле тартылыш“ теориясен китереп чыгара. Бу теория сүзнең тамыр өлешендәге *о—ө* авазлары тамырга кушылган аффикслардагы сузыкларның да иренләшеп әйтелүләрен таләп итә дигән кагыйдәдән тора.

В. В. Радлов, шушы кагыйдәгә нигезләп, куман текстында нинди төр иренләшүләр булганлыгын үзенчә бер схемага салып күрсәтә. Мәсәлән, ул анда түбәндәге төр „иренләшүләр“ саный:

1. *О* дан соң *а* килә: *соңра* (аның транскрипциясе);
2. *О* дан соң *у* килә: *коркутмас* (куркытмас);
3. *Ө* дән соң *ү* килә: *көрүнүрмән* (күренермен);
4. *Ө* дән соң *ә* килә: *өзгәцә* (үзгәчә);
5. *У* дан соң *а* килә: *тутмак* (тотмак, тоту), *куткардуцы* (коткаручы).
6. *У* дан соң *у* килә: *унудмак, унутурмын* (онытмак, онытырмын).
7. *Ү* дән соң *ә* килә: *цүпрәк, үрәнгәймен* (чүпрәк, өйрәнермен).
8. *Ү* дән соң *ү* килә: *күцлү* (көчле).

Димәк, В. В. Радлов сигез төрле иренләшү саный, һәм, аныңча, *а—ә* авазлары да иренләшмәләр төркеменә керәләр була. Ләкин ул шунда ук куман шивәсендә иренләшүнең артык көчле булмавын, анда бу күренешнең ике иҗектән артыкка бармавын әйтеп китә (21 бит).

В. В. Радловның бу материаллары безгә берничә яктан әһәмиятле. Беренчедән, без монда үткән бүлекчәдә сөйләгән фикернең, ягъни *о—у*, *ө—ү* авазлары арасында көчеш булганлыкны раслый торган фактларны күрәбез. Мәсәлән, хәзерге татар телендә *у*, *ү* авазлары белән әйтелә торган сүзләр анда *о*, *ө* ләр белән әйтеләләр: *курку* ⟶ *корку, үзгәрү* ⟶ *өзгәрү*, һәм, киресенчә, *тотмак* ⟶ *тутмак*, хәзерге телдә *көчле* (*ө* белән) дип әйтелә торган сүз анда *күцлү*, дип *ү* белән әйтелгән булып чыга. Бу факт көнбатыш диалектның кайбер сөйләшләрендә (Сергач, Пенза) әле дә сакланган. *Олым* (әдәби телдә улым), *от* (әдәби телдә *ут*) кебек әйтелешләр әнә шул ук куманнарга барып тоташа дип әйтергә һәм, гомумән, *ботка—бутка, шулай—шолай* формаларында икешәр вариантта әйтелә торган авазларның тарихын күзалларга мөмкинлек туа.

Икенчедән, иренләштерү күренешенең борынгы чорда чагыштырмача көчлерәк булганлыгы ачыла.

Мәгълүм ки, хәзерге татар телендә *у—ү* авазлары үзләреннән соң килгән *ы—э* ләрнең иренләшүен таләп иткәннәр, мәсәлән, *урын→урыны, үтемле* һ. б.

Борынгы текстларда мондый очраклар күбесенчә ирен авазлары белән формалаштырыла торган булганнар.

Мисаллар:

„*Дүрлү* нигъмәт аш *кәтүрди*" („Йосыф-Зөләйха")[1].

„*Сүрәтләре* мөнәүүер (нурлы мәгънәсендә) *дүрлү-дүрлү*" („И. З.").

„*Ултуруб торор* ирде" („Нәһж-эл-фәрадис")[2].

„*Куркуг* кереб *торор*" („Н. Ф.").

„Бу йирдә арслан *укуш* (күп мәгънәсендә) *булур*... Бу кичә уйаг *тороң*, арсланнар сезләргә йә тәкый *колоңларыңызга* зәхмәт *тикүрмәсүн* тиде..." („Н. Ф.", 14 бит).

„Аркасы берлә *утун кәлтүрүр* ирде тәкый сатар ирде, бәһасыни өч өлеш кылур ирде" („Н. Ф.", 410 бит).

„*Углу* — кызы *күрүклүк йөзлүк* вә хүб *сурәтлүк* булгай („Нәсыйхат-эл-Салихин")[3].

Менә шушы форма, традицион рәвештә, татар язу тарихында бер төркем сүзләр һәм кушымчалар язылышында хәтта XX йөз башларына чаклы дәвам итә. Мәсәлән, Каюм Насыйри текстларында сыйфат кушымчасының *луг, лү, лы* формалары янәшә кулланылалар. Мисаллар:

„Бик *олуг* вә газиз нәрсәдер"; „*олуг* вә кечек адәмнәргә..." („Фәвакиһ-эл-җөласә", 5 бит).

„Олуг шагыйрьләр" (шунда ук, 11 бит).

Лу—лү (→ лы—ле) формасы (сыйфат) К. Насыйрида әле бик актив яши дип була. Мисаллар:

*Мәхәббәтлү* (сыйфат *лү* формасы белән бирелгән): „җумартлык кешене дусларына *мәхәббәтлү* күрсәтер" (шунда ук, 14 бит).

„Күзе *яшьлүләргә* мәрхәмәт итмәгән кеше" (шунда ук, 14 бит).

---

[1] Искәрмә: җыйнаклык өчен, моннан алда „Йосыф-Зөләйха" урынына „Й. З." билгесе генә куячакбыз.

[2] Алда, җыйнаклык өчен, „Нәһж-эл-фәрадис" дигән китап исемен „Н. Ф." билгесе белән генә күрсәтәчәкбез.

[3] „Нәсыйхат-эл-Салихин" — китап исеме, алда без бу исемне „Н. С." билгесе белән генә йөртәчәкбез.

Лы—ле (сыйфат) формасына мисаллар:

„Сөзешсән, *мөгезле* белән сөзеш" (шунда ук, 8 бит), „эт оясында *көчле*" (10 бит), „бер сабый бала *кояшлы* көнне бер йирдә йөргәндә күләгәсен күрде..." (шунда ук, 100 бит) һ. б.[1]

Шул рәвешчә, татар язма әдәби телендә иренләшү гармониясен саклау озак дәвам иткән була. Моны әнә шул сыйфат ясагыч *лы—ле* (хәзерге) аффиксының *лу—лү* формасында язылып килүе дәлилли.

Ләкин бу форма гомумхалык сөйләм телендә шулай ук озак сакланган дыр, дип уйларга туры килми. Халык сөйләм практикасында бу кушымчаны иренсезләштерү, ягъни шул ук *лу—лү* не *лы—ле* дип әйтү күптәннән үк урнашкан.

Хәзерге татар теле белемендә иренләшү гармониясенең теоретик яктыртылышы тик *о—ө* ләрнең *ы—э* авазларына йогынтысы күләмендә генә алына, чөнки *у—ү* авазлары инде мондый көчне югалтканнар.

Без Г. Алпаровның, *о—ө* авазлары тамырның беренче иҗегендә генә килеп, үзләреннән соңгы *ы—э* авазларына 3—4 буынга (иҗеккә Л. Ж.) житкәнче тәэсир итә алалар, дип аңлатуын югарыда әйтеп киткән идек. Аның бу турыда үзенчә ясаган схемасын да күрсәттек, ягъни, аныңча, „о—ө авазлары сүзнең баштагы иҗегендә көчле әйтелеп тә, өченче, дүртенче иҗекләрдә тоташ ы—э гә әйләнәләр"[2].

Н. К. Дмитриев, татар әдәби телендә *о—ө* авазлары сүзнең тик беренче иҗегендә генә, башкорт әдәби телендә, киресенчә, сүзнең бөтен күләменә җәелә дип аңлата. Мәсәлән, башкортча — *йокоһоз* ⟶ *йокоһозлоктоң*, татарча — *йокысыз* ⟶ *йокысызлыкның* языла. Менә шушы язылыш формасыннан чыгып, Н. К. Дмитриев татар телендәге о (ө) авазы иренләштерү көчен югалткан, башкорт телендә бу күренеш сакланган дип карый (10 бит).

Дөрес, хәзерге татар әдәби телендә яшәп килә торган орфография буенча язылыш шулай, ягъни *о—ө* ләрнең *ы—э* авазларына иренләштерү йогынтысы язуда

---

[1] Искәрмә. Без бу форманы М. Гафури, Г. Тукай текстларында да очратабыз. Кыскасы, бу форма, нигездә, Бөек Октябрь социалистик революциягә чаклы дәвам итә.

[2] Г. Алпаров, „Сайланма хезмәтләр", 1945 ел, 47 бит.

күрсәтелми. Ләкин халыкның сөйләм практикасында, аерата урта диалект вәкилләре сөйләмендә олаштыру һәм өләштерү әле үзенең көчен шактый нык саклаган. Алар, *тормошо, бөтөнөсө*... дип әйтәләр. Алай гына да түгел, хәтта *кебек, кыш* формасындагы сүзләрне дә *көбөк, кош көне* дип әйтү Казан арты сөйләшендә бик ачык сизелә.

Безнең уебызча, урта диалектның *төзөлөш, бөтөн, төтөн, йоко* || *йокосо* дип әйтү формасын хәзерге әдәби телгә орфоэпик норма итеп алу дөрес һәм рациональ булачак.

Бу төр гармониянең тарихи ягын аңлатканда, берничә моментка ачыклык кертү кирәк. Барыннан да элек, иренләшмә гармонияме, әллә иренсезләү гармониясеме „беренчел" булган, дип кую тарихи чынбарлыкны ача алмаячак. В. В. Радлов үзе үк куман текстында *артук* һәм *артык* (artuk — artjык, аның транскрипциясе) формалары очрый дип әйтә (19 бит).

Шул ук хәлне без, „Йосыф-Зөләйха", „Нәһҗ-эл-фәрадис"лардан башлап, XX йөзгәчә аралыкта булган текстларда күпләп очратабыз. Мәсәлән, „Нәһҗ-эл-фәрадис" текстында: *„яркулук", „ивнең төнлөкө", „казгулуг"* (кайгылы)... кебек формалар белән беррәттән, *„атлыг", „олуглык", „сыйфатлыг"* дип, ягъни бер үк кушымчаның *лук* һәм *лык* || *лыг* формаларында язылышы зур гына урын ала.

Иялек килеше кушымчасы *нық—нең* „Нәһҗ-эл-фәрадис"та өч төрле язылган. Мәсәлән: *„Кемнуң"* (نونڭ), *„Эмме Җәмилниң"* (نینڭ), *„Мән ан(ы)ң"* (آننڭ). *Дым—дем* кушымчасын да *„ултурдум"* (دوم) *„ирдүңез"* (ایردونکیز) һәм *„ирдим"* (ایردیم) формаларында язылган килеш очратабыз.

Әйткәнебезчә, аналогик төрлелекләр борынгы текстларда бик озак дәвам итәләр. Һәм бу фактлар, үз чиратларында, *лук* яки *лык, дум* яки *дым* формасы „беренчел" дигән тезисны инкарь итәләр. Болар икесе дә, диалекталь күренеш буларак, ыруглар чорыннан ук килгәннәр һәм язма әдәбиятта бер-берсе белән янәшә кулланылыш алганнар, дип аңлату дөресрәк булачак.

Икенчедән, борынгы текстларда *лук-луг* формасының нигез урын тотуын шартлы рәвештә генә кабул итеп, *лык* формасы гомумхалык телендә чагыштырмача киңрәк урын алган һәм, традицион сакланып килгән *лук* формасын кысрыклап, бик күптәннән үк язма текстларга да кергән дип аңлату фәнни аныклык бирәчәк.

Ниһаять, иренләшү гармониясен тарих сызыгында тикшерүне тамырлар һәм кушымчалар гармониясе дигән ике моментка бүлеп карау, уебызча, фәнни төгәлрәк булачак. Чөнки, язма әдәбият тарихында күзәтелгәнчә, кушымчаларның байтагы, тамыр яки нигез гармониясенә карамастан, ирен сузыгы белән язылып килгәннәр. Мондыйларга сорау кушымчасы *му* (⟶*мы*), хәз. заман хәл фигыль кушымчасы *уб—үб* (⟶*ып—әп*), сыйфат ясагыч *лу—лү* (⟶ *лы—ле*), хикәя фигыль ясагыч *ур—үр* (⟶ *ыр—әр*), иялек килеш кушымчасы *нуң* (⟶*ның*) һәм тагы кайбер кушымчалар керәләр.

Хәзерге гомумтатар телендә сорау кушымчасы *мы—ме* формасында, ягъни иренсез сузык белән әйтелә. Аерым сөйләш, урынчылыкларда бу кушымчаның әле *ма—мә* формасы да бар. Мәсәлән, Арча урынчылыгында *барма* (бармы), *юкма* (юкмы), *киләмә* (киләме), *улма* (улмы)... дип әйтәләр.

Менә шушы төрлелек үзе генә дә бу кушымчаның фонетик төзелешендә үзгәреш булганлыкка ишарә итә. Борынгы текстларда без бу кушымчаның *му* формасында язылышын беләбез, һәм бу язылыш, язма әдәбиятта урнашкан алым буенча, XIII—XIV йөзләрдән алып, К. Насыйриларга чаклы килә.

Билгеле, без бу урында әнә шушы аралыкта язылган барлык документларга туктала алмыйбыз, берничә үрнәк китерү җитәчәк.

„Н. Ф.“ текстында сорау кушымчасы тик *му* формасы белән генә язылган. Мисаллар:

„Сахрага чыксаң *булмасму*“, „Безем берлә барсаң *булмасму*“, „Бер эчем *су булмасму*“, „Мәне *сусызму* үлтерерсез“, „*китәрмүсән*“, „Бакаен, *терекмү* торыр? (422—424 битләр).

Ниһаять, Г. Кандалыйда „*килүрсенму*“, „Сүзем кабул *идәрмүсен?*“, „бүтән ярга *китәрмусен?*“, „миңа бавыр *итәрмүсен?*“, „*көтәрмусен?*“, „сулга *сүтәрмүсен?*“ кебек формалар актив урын тоталар.

Каюм Насыйри текстларында исә сорау кушымчасының *му* һәм *мы* формалары янәшә йөртеләләр. Мисаллар:

„Хаҗәтең вә бурычың *бармы?*“ „*азму... купму*“, „*белерменму*“, „балалары „*булурму*, ягъни *тугармуʔ*“, „*укырлармы*“, „разый *булурмы*“ („Фәвакиһ-эл-җөласә“, 516—528 бит).

„Йир *өстендәму*, я йир *остындаму*, я *судаму*, я *утдаму*... (Гали Махмудов, „Үлгән кебек булган кеше...“, 1851 ел).

Бу материаллар татар телендәге сорау кушымчасына карата түбәндәге фикерне теркәргә мөмкинлек бирәләр. Борынгы татар язма әдәбияты текстларында, хәтта XIX йөз азакларына чаклы бу кушымчаны *му* формасында, ягъни иренләшмә сузык белән йөрткәннәр. Насыйрилар чорында шул ук кушымчаның *мы* формасы активлаштырылган, икенче төрле әйткәндә, иренсез сузык белән әйтелеш варианты урнашкан.

Гомумән алганда, бу кушымчаның татар телендә *му*, *ма*, һәм *мы* вариантлары булган; *му* — язма әдәбиятта традицион нигездә сакланып килгән, *мы* бик күптәннән үк гомумхалык теленә урнашкан булган һәм соңыннан, татарның милли әдәби теле формалашу процессында, әдәби норма итеп беркетелгән, *ма* формасы исә, тар диалекталь күренеш буларак, аерым урынчылыкларда бүгенгәчә сакланып килә. Шуның белән бергә, *му* формасы урынына *мы* ның алынуы, иренләшмә форманың иренсез форма белән алмаштырылу күренеше дә булып тора.

Бу урында шуны әйтеп китәргә кирәк: Габдулла Тукай сорау кушымчасының *мә* формасын бер уңайда язып калдырган:

„Ул ихсанлы кеше кем? *Улмә?* Ул — мин!“[1] („Кемдән ярдәм эзләргә“).

Шулай, Г. Тукай, монысы урынчылык, тегесе әдәби дип тормаган, Арча, Дөбъяз урынчылыкларында гына сакланган *мә* (сорау) кушымчасын да тарихка кертеп калдырган.

---

[1] Тукайның академик басмасында, ни өчендер, гомумән шушындый үзенчәлекле, фәнни әһәмиятле моментларны „төзәткәннәр“. Мәсәлән, Тукайча, бу шигырьнең исеме — „*Кемдән* ярдәм эзләргә?“ Академик басмада (I том, 1943 ел, 124 б.)— „*кемнән...*“, Тукайча — „*Улмә*“, акад. басмада — „*улмы*“.

Хәзерге заман хәл фигыль кушымчасы да үзенең формалашу тарихында катлаулы гына фонетик үзгәрешкә тарыган, ләкин без әлегә андый киңлеккә кермибез. Бу кушымча хәзерге татар телендә, кирәк язуда, кирәк сөйләм практикасында булсын, *ып—эп* формасы белән йөртелә. Борынгы текстлардан алып, XX йөзгә чаклы исә, ул *уб—үб*, ягъни иренләшмә сузык (*у — ү*) белән язылып килә. Мисаллар: „*ултуруб*" (утырып), „*куркуб* уйганды", „төшләр *күрүб* торор", „*булуб*", „*кудуб*" (куйып) һ. б. („Н. Ф."). Кандалый текстларында да „*түзүб*", „*иштүб*", „*карышуб*", „*күрүб*" „*диүб*", „*язуб*"... формасы система булып тора.

Ниһаять, бу кушымчаны *уб—үб* формасында язу К. Насыйрида да төп урынны ала. Мәсәлән, ул „*алуб*", „озак *торуб* кайтды", „йомошны *бетрүб* кайтур", „була *торуб*" дип язган; дөрес, аның текстларында *дип* сүзен *диб* һәм *диүб* формаларында язу да очрый, ләкин бу әле К. Насыйрида система түгел.

*Ал, бел, тарт, кит*... кебек иренсез сузыклар белән әйтелә торган тамырларга *уб — үб* кушымчасының ялгануы, асылда, иренләшү гармониясенең бик үзенчәлекле ягын ачып бирә. Без монда кушымчаның үзенә мөстәкыйль әйтелеш саклавын һәм тамыр яки нигездәге сузыклар гармониясенә буйсынмавын күрәбез. Мәсәлән: *алуб, белүб, тартуб, китүб*...

„Атының җүгәнен *тартуб китүб* барган" (К. Насыйри „Ф. җөласә", 480 бит).

Әгәр дә сузыклар гармониясе төгәл законлылык саклый торган булса, бу фразадагы сүзләр *җүгәнүн, тартыб, китеб* формаларында язылырга тиешләр иде. Фактта нәкъ киресенчә килеп чыга. Димәк, *уб—үб* кушымчасы тамыр, нигездәге гармониягә буйсындырылмаган була. Күренә ки, хәзерге *ып—эп* кушымчасы да үзенең фонетик тышчасын үзгәрткән, иренләшмә формадан иренсез әйтелешкә күчкән.

Сыйфат ясагыч кушымча, югарыда күреп үткәнебезчә, борынгы текстларда *лук* ‖ *лык*, *луг* ‖ *лыйг* формаларында язылып йөртелгән һәм ике функцияне үтәгән: а) сыйфат ясаган, мәсәлән, „айга *яңлыйг*" (айга охшашлы), „көнеш *яңлыйг*" (кояшка охшашлы), „*төрлук* сачкә" (төрле чәчкә), „*төрлөк* мивә" (төрле җимеш) кебек тезмәләрдәге сыйфатлар әнә шул борынгы

*лук* || *лүк, ләк, лыйг* || *лыг, лык — лек* кушымчасы белән формалаштырылганнар; б) шул ук кушымча борыннан ук сыйфат-исем (имя-качество) ясауга да, мәсәлән, *олуглук, тәкәбберлек...* һәм һөнәр, профессия атамалары ясауга да йөргән, мәсәлән, борынгы текстларда *игенчелек, сунарчылык, куйчылык, балчылык* кебек сүзләр очрыйлар.

Менә шушы сыйфат-исем (имя-качество) һәм төрле һөнәрчелек, производство тармакларына караган атамалар ясый торган *лык—лек* кушымчасы (иренсез сузык белән) хәзерге гомумтатар телендә актив кулланылышын саклый. Мисаллар: *тотанаклылык, белемлелек, эшчәнлек, сизгерлек...* (сыйфат-исемнәр) һәм *кырчылык, терлекчелек, игенчелек, кошчылык, бакчачылык, укытучылык, язучылык...* (һөнәр, производство атамалары).

Сыйфат ясагыч кушымча шактый сиземле үзгәреш алган, ул әнә шул борынгы *лук* || *луг, лык* || *лыйг* формасыннан, фонетик кыскарып, *лы — ле* гә калган, ягъни җыйнаклану, шомаруга очраган. Беренчедән, бу кушымчаның азаккы авазы к, г төшеп *лу — лү* формасына калган. Һәм, соңыннан *лы — ле* гә күчкән. Мәсәлән, борынгы *куәтлук ⟶ куәтлу* формаларыннан хәзер ⟶ *куәтле* гә калган.

Сыйфат ясагыч кушымчаның *лы — ле* формасы, законлы рәвештә, элек халык авыз иҗатына кереп урнаша. Мәсәлән, К. Насыйри тарафыннан һәм аңардан элек язып алынган халык җырларында *татлы, тышаулы, охшаулы, дәртле, моңлы, нурлы...* формалары бердәнбер форма булып торалар.

Каюм Насыйриның үз текстларында исә, югарыда әйткәнебезчә, бу кушымчаның *куәтле, куәтлерәк* һәм *төрлү, баглу* (бәйле) формалары янәшә йөриләр.

XX йөзгә чыккач, М. Гафури кебек демократик язучылар, бу кушымчаның иске формасын ташлап, гомумхалык телендәге вариантын активлаштыралар: „*кызыклы, күңелле, төрле-төрле, файдалы...*“ — дип яза Гафури.

Кыскасы, XV—XVI йөзләрдәге *татлыйграк* формасы XX йөз татар язма әдәбиятында *татлырак* булып әверелә. Монда да ирен сузыгы белән йөртелгән кушымчаның (лу — к) иренсез сузыклы форма белән (лы) алмаштырылуын күрәбез.

Ниһаять, хәзерге-киләчәк заман хикәя фигыль ясагыч *ыр — эр* кушымчасының да язма әдәбиятта кулланылган формасы шактый характерлы. Бу кушымча, нинди гармонияле тамыр яки нигезгә кушылуына карамастан, бик озак заманнар буе, хәтта Бөек Октябрь социалистик революциясенә чаклы, *ур—үр* формасында, ирен сузыгы белән язылып килә. Берничә мисал: „*чакрур*" (кычкыра), „Хуш чимкән *булур*" (матур чирәм булыр)... („Н. Ф.").

Хикәя фигыль кушымчасының менә шундый *ур—үр* формасында язылышы, бик борынгы текстлардан алып, М. Гафурилар, Г. Тукайлар чорына чаклы дәвам итә.

„Хәсидләр бәйләнергә хәзер *турур*,
Кагуб куйган баганадай урам чатка" (М. Гафури).

„Яман дуст юк урында хафа *салур*" (М. Гафури).

„Балалар бер вакытта зур *булурлар*,
Яхшы булса, нур өстенә нур *булурлар*" (М. Гафури).

„Бу җегет абзаң *булур бу*...", „Кем *килүб йолкор* мине", „*Ялтурмын*, янармын да көярмен", „Тик бер ялгыз корсагыңны *зурайтурга*", „Бу эшне ул, үзе сизсә, *ачуланур*", „... яшь күңел *дулкынланур* һәм *диүр*: „Ай-һай матурмын, кем *алур* тик кем *алур*" (Г. Тукай.)

Мисаллардан күренгәнчә, хәзерге телдә иренсез сузык белән әйтелә һәм языла торган *ыр — эр* кушымчасы бик озак заманнар буена *ур — үр* формасында язылып килә. Димәк, бу очракта да иренләшмә гармониядән иренсез әйтелешкә күчү булган.

Борынгы заманнарда тартым, зат кушымчасын да *ум — үм* дип, ягъни ирен сузыгы белән язып йөртү булган, мәсәлән, *хатунум*, *угъланум*, *кәлдүм*... Ләкин бу форма озак дәвам итми.

Менә шушындый тар гына бер сызык буйлап күзәтү дә, фикеребезчә, „иренләшү гармониясе", „иренләшмәле тартылыш" дип йөртелә торган фонетик күренешкә шактый зур ачыклык кертә. Беренчедән, кушымчалар гармониясе (әйтелеше) тамыр һәм нигездәге гармониягә буйсыналар дигән гомуми кагыйдәнең дөрес булмаганлыгы ачыла, һәм кушымчалар үзләре ялганган сүзләргә тик калынлык, нечкәлектә генә буйсыналар, иренләшү гармониясе буенча аларның үзләренә хас законлылык элек-электән үк яшәп килгән, дип төзәтмә, аныклык кертү кирәклеге туа.

Икенчедән, хәзерге татар телендәге ирен авазларыннан *у — ү* нең үзеннән соңгы иренсез авазларга йогынты ясау көче беткән булу фактлар белән ачыклана, мәсәлән, борынгы язмаларда *утун* дип язылган сүз хәзер *утын* дип әйтелә һәм языла.

Бу хәл, үз чиратында, гомумән иренләшү гармониясенең бик борыннан ук җимерелә килүен һәм хәзерге телдә аның бик чикле булуын, конкрет алганда, *о — ө* авазларында гына калганлыгын раслый.

Өченчедән, иренләшү гармониясе күренешенең язма текстларда бик озак сакланып та, гомумхалык телендә күптәннән үк җимерелгән булуы дәлилләнә.

Ниһаять, хәзерге татар телендә „иренләшмә тартылыш“ урта диалектка хас булып та, иренсез авазлар белән сөйләү күбрәк көнбатыш диалект үзенчәлеге булу ачыклана. Мәсәлән: *тотоноп* (ур. д.), *тытынып* (көнб. д.).

Бу аерманың тарихи чыганагы булып борынгы болгар һәм кыпчак кабиләләре торалар. Болгар төркеменә караган кабиләләр — иренләштерүчеләр, кыпчак төркеменә караганнары исә — иренсезләндерүчеләр. Һәм, шушыннан чыгып, борынгы язмалардагы иренләштерү гармониясен болгар чоры әдәби теле калдыгы дип санарга тиешле булабыз. Мондый аңлатма безне тарихи чынбарлыкка якынайтачак.

Дүртенчедән, татар теле фонетик системасында *ә* (ä) авазының кысык-тар сузык *и* белән алмашыну факты теркәлә. В. В. Радлов Идел буе шивәсендә *и* белән урнашкан сүзләр куман телендә әле *ә* (ä) белән әйтелүдән күчмәгән булалар дип күрсәтә (14 бит) һәм үзенең шушы тезисына түбәндәге чагыштырманы дәлил итеп китерә:

| Алтайда | | Кыргызда | Куманда | Татарда |
|---|---|---|---|---|
| ты | сäн | сен | сен | син |
| земля | нäр | жер | йөр | жир |

Күрәсез, чагыштырмага алынган телләрдәге *ä*, *е* (э) урынына татарда *и* авазы кулланыла.

Борында ә белән әйтелгән сүзләрнең байтагы хәзерге татар телендә *и* белән әйтелүгә күчкәнлек — дәгъвасыз. Мәсәлән: кәрәк ⟶ кирәк, бәк ⟶ бик, кәлде ⟶ килде, сән ⟶ син, мән ⟶ мин.

XV—XVI йөз татар кабер ташбилге язмаларында хәзерге *иде* сүзенең *әти* (آتی) т—*ити* (اِتی) , *ирде*, *әрде* формаларында язылган булуы да шул турыда сөйли.

Моның калдыгы татар теленең төрле диалект һәм сөйләшләрендә әле бүген дә яши. Мәсәлән: *мәңа, сәңа* (көнб. диал.; урта диалектның Тау ягы сөйләше һ. б.); *бәк яхшы* (Казан арты сөйл.), *кәм* (ким) (көнб. д.) һ. б.

Ләкин шуны әйтергә кирәк, бу күчеш турыдантуры *ә* ⟶ *и* формасында түгел, бәлки *ә* ⟶ *э* ⟶ *и* буйлап килгән дип күзаллау дөресрәк булыр. Чөнки моңа дәлилләр бар. Мәсәлән, *мән* була, моның татар телендә *мен* һәм *мин* формалары калган. *Мин* бара*мын*, *син* килә*сең*, дигәндә *син* һәм *сең(н)*, *мин* һәм *мын* || *мен* формалары янәшә яшиләр.

Монда характерлы бер тарихи законлылык бар: *мән* — *сән* — зат алмашлыклары, субстантлашкан урынбасарлар. Шул ук алмашлыклардан зат һәм тартым кушымчалары *мын* — *сын* (⟶ сың) һәм *ым* — *ың* нар да ясалганнар. *Мин барамын*, *син киләсен* (әдәби киләсең) дигәндәге *мын* һәм *сен* шулай ук *мин*, *син* дигән төшенчәне бирәләр — *мин бар-а-мын* = *мин бара ул-мин*, була. *Син бар-а-сың* = шулай ук *барул-син*, ягъни бару эшен син эшлисең була.

Күренә ки, зат алмашлыклары *мин* һәм *син* борынгы *мән*, *сән* формасыннан *мин* гә (ә ⟶ и), зат кушымчалары исә *мен*, *сен* гә (*ә* ⟶ *э*) күчеп нормалашканнар. Болардагы *и* һәм *э* нең зат алмашлыгы (мин) белән зат кушымчасы (мен) арасындагы эчтәлек аермасын күрсәтү ягыннан да зур гына әһәмиятләре бар.

Бу мәсьәлә артык детальләүгә мохтаҗ булмаганлыктан, мисаллар китереп торуның да кирәге юк. Тик шуны гына теркәргә кирәк: *мин, син, сиез*... кебек сүзләрне *сән*, *мән*, *сәкез* дип язу Каюм Насыйриларга чаклы дәвам итә. Берничә мисал: „*Сәкез* төрлү һәдия китүрдиләр“, „*Мәңа* бер кемсәнә бер һәдия күндүрүб... *мән сәңа* һәдия бирдем“...; „фәлән кемсәгә *мәндән* сәлам әйт...“ (К. Насыйри, „Ф. җөласә“, 318—320 битләр).

Шул рәвешчә, димәк, бер төркем сүзләрнең борынгы әйтелешләре (мәсәлән, ә белән әйтелеш формалары) язуда бик озак сакланган, һәм *мәңа* урынына *миңа* дип язу шулай ук шактый соңгарып, гомумхалык сөйләм практикасы басымы астында кереп урнашкан була.

*Ә* (ä) ⟶ *э* (е) ⟶ и күчеше, алмашынуы процессы күзлегеннән караганда, хәзерге татар теленең җирле диалект һәм сөйләшләре бер-береннән сиземле аерылалар. Мәсәлән, гомумхалык телендә *инде* формалы әйтелә торган сүзне Норлат-Кайбыч урынчылыгында *энде, миңа* сүзен *мәңа* дип әйтәләр; Нократ-Кистем сөйләшендә гомумән ачык *и* күп кенә очракларда *э* гә күчә, алар *экмәк* (әдәб. икмәк), *элле* (илле), *кэрек* (кирәк)... дип сөйлиләр, ягъни боларда *ә* һәм *и* авазларының икесе дә *э* гә якын артикуляция белән әйтеләләр. Свердлов — Молотов өлкәләре татарларына һәм өлешчә Минзәлә сөйләшенә иләштерү характерлы, мәсәлән, алар *инәй* (әни), *печин* (печән), *синәк* (сәнәк) *тирәзә* (тәрәзә) ... дип әйтәләр.

Менә шушындый төрлелекләр, һичшиксез, татар теле фонетик төзелешендә *әләштерүдән иләштерүгә* күчү булганлыгын күрсәтәләр.

Ләкин без монда *и* авазы үзе *ә* дән яки *э* дән килеп чыккан, шуларның артикуляцион үзгәреше булып тора, дип әйтергә һич тә җыенмыйбыз.

Менә шушы югарыда әйтелгәннәр татар теле фонетик системасы формалашу процессында сузык авазлар үзгәрешенә караган төп моментларны якынча чагылдыралар дип уйлыйбыз.

## IV. ТАРТЫКЛАР ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ҮЗГӘРЕШЛӘР

Татар теле фонетик төзелеше тарихында тартык авазлар буенча үзгәреш, алмашынулар катлаулырак һәм күбрәк булган. Ләкин бу безнең башлангыч күзәтүебез аларның барысына да деталь ачыклык бирә алудан әлегә ерак тора.

### 1. Тартыклар гармониясе һәм андагы үзгәрешләр

Бу күренеш үзе берничә һәм шактый каршылыклы моментларны эченә ала:

а) Тамырның соңгы авазына кушымчаның беренче

авазы, ассимиляция законы нигезендә, охшашлану, бер гармониягә күчү.

Фәндә урнашкан традиция буенча, Н. К. Дмитриев, бу моментны кирәгеннән артык гомумиләштереп, „әгәр дә сүзнең тамыры саңгырауга бетсә, аңа өстәлә торган аффикс та тик саңгырау аваздан гына башлана ала һәм, киресенчә, яңгырау тартыктан (шулай ук сузыктан) соң өстәлгән аффикс тик яңгыраудан гына башлана ала“[1], — дип аңлата.

Билгеле, болай гомумиләштерү реаль фактларны тулы ача алмый, чөнки *таш* ⟶ *ташта, ташка, таштан; эш* ⟶ *эштә, эштән, эшкә; юл* ⟶ *юлда, юлдан, юлга; ир* ⟶ *ирдән, иргә; кеше* ⟶ *кешегә*... кебек мисалларда килеш кушымчаларына карата бу кагыйдә туры килсә дә, *эшле, көчле, ташлау, ятлау, аклау, аклам, ашлык, татлы* һ. б. шундыйлар ул кагыйдәне бөтенләй җимерәләр.

Димәк, бу кагыйдәгә, сонорлардан башланган аффикслар тамыр яки нигезнең соңгы авазы тарафыннан йотылмыйлар, охшашланмыйлар, дигән тулы бер искәрмә кертергә тиешле булабыз, мәсәлән: *атлар, балалар, кошлар; атны, баланы, кошны; атмы, кошмы, баламы*...

Шуның белән бергә, бу искәрмәнең үзенә хас чыгармасы да юк түгел. Әгәр дә тамыр яки нигез сонор авазга бетсә, аңа ялганган кушымчаның беренче авазы, сонор булса да, ассимиляциягә бирелә, мәсәлән, *аң* ⟶ *аңны* (⟵ *лы*, әйтелештә), *сан* ⟶ *саннар* (⟵ *лар*) һ. б.

Хәзерге татар телендә кушымчалар белән тамыр, нигез тартыклары арасындагы охшашлану әнә шулай тора.

Борынгы телдә, язма текстларга караганда, бу момент шактый үзенчәлекле була. Ул үзенчәлекләр исә кушымчаларның фонетик төзелешләре берәр генә варианттан торудан гыйбарәт; мәсәлән: күплек кушымчасы анда тик *лар* — *ләр* формасында гына йөртелә: „ул үлгәнне орган*лар*“, „белмәгән*ләр*“, „яшь яфрак*лар*“ („Н. Ф.“).

Килеш кушымчалары да шулай ук бик озак заман-

---

[1] Проф. Н. К. Дмитриев, „Грамматика кумыкского языка“, 1940 ел, 22 бит.

нар буе берәр генә вариантта кулланылып килгәннәр. Мәсәлән, чыгыш килеш кушымчасы хәзерге телдә *нан (нән), дан, тан* формаларында өч төрле әйтелә һәм языла. Борынгы язмаларда исә, күбрәк боларның *дин* ‖ *дан* вариантларын язып йөрткәннәр. Мисаллар, „*Сумгасыдин* төште тәкый монлар *катыйга* кәлде". Хәзергечә сумгасыннан (салашыннан), һәм *катына* (юнәлеш килеше), „бу *көндин* соң" (көннән); „*дөньядин* кәчте" (дөньядан), „бер заман *йитмешдин* соң" (җитмештән...), „*катымдин* кәтеп" (катымнан) һ. б. („Н. Ф.").

Чыгыш килеш кушымчасын тик бер генә формада язу Бөек Октябрь социалистик революциягә чаклы дәвам итә. „*Сәндән... мәндән* сәлам"; „*андан* яхшырак", „*соңындан*", „*кешедән*", „*ризыкымдан* арткан" (ризыгымнан); „имтихан *йөзендән*" (йөзеннән), „*күкдән* ягъмур яуган"; „*ни сәбәпдән*" һ. б. (Бу мисаллар Каюм Насыйри текстларыннан алындылар.)

„Сугыш син, һич тә армас, *туктамасдан*", „Качармы *юлбарысдан* бер арслан", „Ни ярдәм килсә дә килсен *үзеңдин*", „Сиңа *миндән* киңәш шул", „*мактаулардан*", „*барындан*", „*өстендән*", „*таң алдындан*", „*таң аткачдин*", „авыр *җөкдин*", „күк *күкрәгәндин* соң", „күзне ачалмаслык *бурандин* соң", „*бераздан*", „арттыра, күрдем, кояш *гадәттәгедән* балкуын", „яр *башындан* тыңладым", „*сөйгәнемдән* шүрәле төсле качам", „шәһринә *күбдән* барып җиткән, диләр", „тешләренең *гәүһәрендән* кабызып алдым" һ. б. (Г. Тукай).

Димәк, Г. Тукайда да чыгыш килеш кушымчасы тик *дан — дән* һәм өлешчә *дин* формаларында гына язылып йөртелгән була. Һәм, шул рәвештә, чыгыш килеш кушымчасының *тан — тән, нан — нән* формаларының тик совет чоры татар язма әдәби теленә генә кереп урнашкан булулары дәлилләнә.

Хәзерге татар телендә юнәлеш килеш кушымчасы шулай ук берничә вариантта кулланыла, һәм ул формалар юнәлеш килеш кушымчасының тамыр, нигез сүзгә охшашлануын, уртак гармониягә керүен чагылдыралар. Мәсәлән: күк ⟶ *күккә*; йолдыз ⟶ *йолдызга*; атасы ⟶ *атасына;* әнисе ⟶ *әнисенә;* мин ⟶ *миңа*; син ⟶ *сиңа*; ул ⟶ *аңа*; бу ⟶ *моңа*... Шул рәвешчә, юнәлеш килеше кушымчалары а) *ка — кә, га — гә,*

б) *на — нә*, в) *а — ә* формаларына бүленәләр, һәм аларның һәркайсы үз урыннарында кулланылалар. Саңгырау тартыкка беткән сүзләргә *ка—кә* ялгана: *таш*→*ташка; эш* → *эшкә*... Яңгырау тартык һәм сузык авазга беткән сүзләргә *га — гә* ялгана: *урам* → *урамга; без* → *безгә; юл* → *юлга; җир* → *җиргә; ата* → *атага*... Өченче зат тартым кушымчасына беткән сүзләргә *на — нә* ялгана: *авылы* → *авылына*; *урам* → *урамына; эше* → *эшенә; китабы* → *китабына*... Беренче, икенче зат тартым алган сүзләргә һәм зат алмашлыкларына а — ә ялгана: *улым* → *улыма; кызың* → *кызыңа; китабым* → *китабыма; сүзең* → *сүзеңә..., мин* → *миңа;* (← минга), *син* → *сиңа* (← *синга*), *ул* → *аңа* (← улга, анга).

Борынгы (VIII—XVI йөзләр) чорга караган текстларда бу кушымчаларның кулланылышы характерлы гына үзенчәлекле була.

Зат алмашлыкларының юнәлеш килеш белән төрләнүләре нәкъ хәзерге телдәгечә, *мәңа—сәңа, аңа* формаларында язылa. Тартымлы сүзләрдән соң исә, *на—нә* түгел, бәлки *га—гә* яки *ка—кә* ялгана. Мисаллар: „*Угъланларыга* уку васыять кылды...“, „Тигәнне *аркасынга* йөкләде тәкый *буйныга* хөрмә йәбдин ишелмеш йәбне кәмәште“, „Моңлар *катыйга* кәлде“ һ. б. („Н. Ф.“).

Бу мисаллардагы *угъланларыга* (улларына), *аркасынга* (аркасына), *буйныга* (муенына), *катыйга* (катынаянына) сүзләре барысы да тартым алганнар һәм юнәлеш кушымчаларының *га* варианты белән төрләндерелгәннәр.

Юнәлеш килеш кушымчасының *на — нә* формасы барлыкка килүен ике төрле нигездән аңлатырга була. Беренчедән, урта диалектның Кама Тамагы урынчылыгында сакланган *нар—нәр* формасыннан *р* төшеп, *на—нә* калган дип карый алабыз. Мәсәлән, алар, *өстенәргә* (нәргә), *мәсьәләсенәргә* (нәргә) дип сөйлиләр. Бу формаларда юнәлеш килеш кушымчалары тавтологик кабатланалар: *мәсьәләсенә—мәсьәләсе+нәр+гә*. Көнбатыш диалектта да *анарга* дип сөйләү бар (*а+нар+га*), әдәби телдә *аңар* || *аңа*. Кушымчаларның авазлары төшү һәм кыскарулары—закончлы күренеш. Димәк, *нар—нәр* нең *р* авазы югалып, *на—нә* гә калу бик мөмкин, *аңар* → *аңа* га калган кебек.

Икенчедән, ике яки аннан да артык кушымча укмашып, бер кушымча барлыкка килү мөмкинлегеннән чыгып, *на*, асылда, тартымлы төшем килеше кушымчасы *ын*+ юнәлеш килеш кушымчасы *га* катнашмасыннан, ягъни *ынга* дан г төшеп, *ына* ⟶ *на* элементына калган дип аңлатырга мөмкин. Борынгы язмаларда без „*козог кырагынга кәлтүрделәр*“ („Н. Ф.“, XIV йөз) кебек форманы очратабыз. Мондагы *кырагынга* сүзе түбәндәге кисәкләрдән тора: *кыраг* — тамыр, *ы* — тартым, *н* — төшем килеше, *га* — юнәлеш килеш кушымчасы. Менә шушы формадан хәзерге татар телендәге *кырына* ‖ *кырыйына* калган. Шул рәвешчә, *кыраг*+*ынга* дагы *г* төшеп, *ына* га (тартымлы юнәлеш), *на* (юнәлеш килеше) формасы калган итеп карарга була.

*Ка—кә* һәм *га—гә* вариантларының үзләрен дә бутап куллану булган, ягъни *га* язылысы урынга *ка* язып, кушымча белән сүзнең тамыр, нигез өлеше арасындагы гармонияне җимерү булган. Мәсәлән: „Мән тәкый *Шамка* барсам“ (кирәк иде Шамга), „*Җәлладка* фәрманлады“ һ. б. („Н. Ф.“).

XVI—XVII йөзләргә караган язма текстларда ук юнәлеш килеш кушымчасының кулланылышы (язылышы), нигездә, хәзерге телдәгечә тәртипкә салына, аерата *на—нә* варианты урнашып китә. Бу, билгеле, гомумхалык сөйләм практикасының язма әдәбият теленә йогынтысы булып тора.

Төшем килеше *ны—не* кушымчасын куллану буенча бераз гына үзгәреш булганын теркәп узарга тиешбез. Эш моннан гыйбарәт: хәзерге татар телендә тартым кушымчасыннан соң килгән төшем килеше ике формада йөри: а) беренче һәм икенче затка караган тартымнан соң килгән төшем килеше кушымчасы үзенең тулы формасын (ны — не) саклый. Мәсәлән: „Сөям чүмеч кебек *борыныңны,* җаным“ (Г. Т.); „Минем *гомеремне*“ (Г. Т.). Өченче зат тартым кушымчасыннан соң килгән төшем килеш аффиксы кыскара, *н* генә килә, ягъни тартым белән кушылу аркасында, *ны—не* кушымчасының *ы—э* се йотыла, төшә. Мәсәлән: „Сабый *вакытын* (вакытыны түгел, Л. Ж.) сагынмакта һәр шагыйрь дә“ (Г. Тукай); „Бер мәхәббәтнең *газабын, михнәтен* күргән кеше“ (Г. Тукай).

„Инглиз *сәясәтен* нәзар итсәң,
Боларның хәйләләре катлы-катлы...

*Мәмләкәтнең* *берен* йоткан, *берен* капкан,
*Өченчесен* кабарга дип кулга тоткан,
*Дүртенчесен* ашарга дип салуб куюб,
Ашармыз дип, бишенчегә кылыч чапкан"
(М. Гафури).

Борынгы текстларда менә шушы тартымлы төшем килеш кушымчасын „Сән кабул итдең аның *сүзене*" (М. Яр.), „*үзене*", „*кыш көнене*" дип, *ыне—эне* формасында кулланганнар. XVII—XVIII йөзләрдә исә шул кушымчаның *н* формасы (хәзерге форма) кулланыла башлый: „Бу күңелнең *күзен* (күзене түгел. Л. Җ.) ачсам" (М. К.). Ләкин бу форма Тукайлар чорына чаклы тулысынча урнашып җитә алмый. Без әле Каюм Насыйри текстларында да ике төрле, ягъни *н* һәм *ны—не, сыны, сене* формаларында язылышны очратабыз. Мисаллар: „*Хаҗәт* ияләренең хаҗәтен...", „Аның *җәвабын*" һәм „бу сүзләрнең *берсене*" (берсен түгел) (К. Насыйри).

б) Тартыклар гармониясенә караган моментлардан икенчесе — *к* авазының ике сузык яки бер сузык һәм бер сонор аваз арасында килгән очракларда үзенең яңгырау пары *г* га күчүе.

Мисаллар: чык→*чыга, чыгып, чыгарма, чыганак*.., ак→*ага* (су), ак→*агы* (сыйфат); як→*яга* (мичкә); ал→*алга* (алка түгел); ур→*урган;* үр→ *үргә* (менә), түр→*түргә* (уз), белем→*белемгә* (омтылу); як→*ягасы* (Иделнең) һ. б.

Ләкин моны абсолют закон итеп карарга ярамый, чөнки, билгеле төркем сүзләрдә, семантик аныклык таләбе белән, шундый ук тирәлектә килүенә карамастан, *к* авазы *г* га күчми. Мәсәлән, як→*яга* (к→г), ләкин тун, пальто *ягасы* түгел, бәлки *якасы;* бак→*бага,* әмма *бака; шалган* түгел, *шалкан; талкан, салкын,* ләкин *талгын* (су), *сөлге,* ләкин *төлке*...

Күренә ки, монда да каршылык килеп чыга, ләкин законнан тыш түгел, чөнки сүзләрнең эчтәлекләре шуны таләп итә.

Борынгы текстларда *к* авазын барлык комбинацияләрдә дә үзен язу алымы шактый озак дәвам итә, хәтта К. Насыйри текстларында да әле *чыкар* (чыгар) дип язылыш еш очрый. Борынгы язмалардан моңа ачык мисал итеп, *тәкый* (хәзерге тагы, тагын), *тануки*

(таныгы), *чыкаргайлар* (чыгарырлар) һ. б. сүзләр язылышын китерә алабыз. Димәк, бу тармак буенча да тартыклар гармониясе дигән кагыйдә тиешле төгәллек алмаган була.

в) Ниһаять, тартыклар гармониясенең законлы бер күренеше итеп, ябык иҗекләрдә саңгыраулар килү моментын алырга тиешбез. Ләкин бу категориягә сонор авазлар керми, мәсәлән, таң, куян, суган, кул, юл, телем, белем, яр, кар һ. б.

Борынгы текстларда ябык иҗекләрне яңгырау аваз хәрефе белән язу система төсе алган була. Мисаллар: *казгулуг булды* (кайгылы булды); *каюг* (кайсы); *үлтүрүб* (үтереп); *ултуруб* (утырып); *булмаз* (булмас) һ. б.

*Ып—эп* кушымчасын *уб—үб, ыб—эб* формасында яңгырау *б* белән язу Тукайлар чорына чаклы дәвам итә.

Шул рәвешчә, бу бүлекчәдә теркәлгәннәр тартыклар гармониясенең шактый катлаулы бер күренеш булуын күрсәтәләр.

## 2. Тартыклар арасындагы тәңгәллек һәм аларның бер-беренә күчүләре

Авазлар тәңгәллеге мәгълүм бер телнең үз эчендә яки бер семьяга (төркемгә) кергән телләрдә теге яки бу сүзләрнең төрле авазлар белән урнашкан булуларыннан тора. Мондый фактларны хәзерге татар теленең төрле диалект һәм сөйләшләреннән күпләп таба алабыз. Мәсәлән, урта диалект *җлаштыру* белән характерлы, анда *җаңа, җарык, җук, җарый...* дип сөйлиләр. Көнбатыш диалект исә, киресенчә, *йлаштыручы* санала, ягъни аларда *җ* авазы юк, шунлыктан алар йырак, йаңа, йук, йил, йиләк, йир... дип сөйлиләр.

Шул рәвешчә, татар телендә, диалектлары күзлегеннән караганда, *й—җ* авазлары әле бүген дә тәңгәлләр булып чыга. *Печән, песчән, песән, пецән* дип сөйләү дә бар, монда, димәк, *ч—сч—с—ц* шулай ук диалекталь тәңгәлләр булып торалар.

Конкрет бер телнең фонетик төзелешен тарих сызыгында тикшерүче әнә шушы тәңгәллекләрнең үткәндәге торышларын, алмашыну һәм үзгәрешләрен күзәтергә тиеш була.

Без дә шушы күренешкә кыскача тукталып узачакбыз.

### а. *Ш—л* авазлары арасындагы тарихи тәңгәллек

Югарыда әйткәнебезчә, безнең максат бик ерак тарихларга китү түгел, гомумән, төрки телләрнең ерак үткәннәренә барып, аларның *прототипын,* иң борынгы уртак материалын эзләп табу — тюркология эше. Күп эпохалар дәвамында теге я бу үзгәрешне алган тел фактларын бик кыска вакыт аралыгында гына күзәтү тиешле нәтиҗәне бирә алмый. *Ш — л* авазлары арасындагы тарихи тәңгәллек мәсьәләсе мөгаен шундый проблемалардан берсе булып тора.

Бу ике авазның төрки телләрдә тәңгәл булуы турында күптән үк кайбер фикерләр әйтелгән һәм чагыштырма материаллар да теркәлгән. Моның үрнәге итеп, Н. И. Золотницкий тарафыннан „Чуваш-рус сүзлегенә" (1875 елда басылган) урнаштырылган таблицаны алырга мөмкин. Ул монда *ш—с—л* авазлары арасындагы тәңгәллеккә (соответствие) түбәндәге мисалларны китерә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| татарча: | *кыш* | *көмеш* | *тыш* |
| кыргызча: | *кыс* | *күмес* | *тыш* |
| алтайча: | *кыш* | *күмүш* | *тыш* |
| якутча: | *кыс* | *көмүс* | *тас* |
| чувашча: | *хиль* | *хүмүль* | *тол* |

Таблицадан күренгәнчә, татарча *ш* авазына чувашча *л* авазы тәңгәл килә; *алтмыш—ултмыл* кебек сүзләр чагыштырмасында да шул ук факт.

Бу авазлар арасындагы тәңгәллек, әйткәнебезчә, ерак тарихта, борынгы төрки, болгар кабиләләре замасында ук булып үткән күренешләрдән берсе булып тора. Ләкин без моңа үткән дә беткән искелек итеп карамыйбыз. Чөнки бу тәңгәллек байтак кына сүзләрнең этимологик чыганакларын табу чарасы булып хезмәт итә ала. Мәсәлән: *иш* һәм *ил, яшь* һәм *йыл* сүзләре бар. *Иш* белән *ил*—болар икесе дә коллектив, бергәлек, җәмгыять, семья һәм күп мәгънәсен аңлаталар. Татарстанда Казиле, Муллиле.. һәм Лаеш, Мамадыш, Тәкәнеш... дип аталган авыл һәм шәһәрләр бар. Менә шушы атамалардагы *ил* һәм *эш* ‖ *ыш* кушымчасы шул ук *ил*—җәмгыять мәгънәсендә түгелме? Һичшиксез шулай, чөнки чувашча *ыйш* (иш) киң

мәгънәсендә семья, общество дигән төшенчәгә беркелелеп калган[1].

*Яшь* белән *йыл* сүзләренең дә, төбендә, бер тамырдан килүләре һәркемгә аңлашылырлык, ачык булса кирәк.

Кыскасы, *ш—л* тәңгәллеге тирәнрәк тикшерүгә лаеклы.

### 6. *Р—з—с* тартыклары арасындагы тарихи тәңгәллек

Бу авазлар —тарихи корреспондентлар, ягъни гомумән төрки телләрдә, бигрәк тә Идел буе болгар-татар теле формалашу процессында характерлы урын тоткан тәңгәлләр.

Идел буе болгарлары составына кергән төрки тел вәкилләре арасында *р, з* төркемнәре булганлык, икенче төрле әйткәндә, андагы җирле диалект һәм кабиләләрнең *р* һәм *з* төркемнәренә бүленгән булулары лингвистикада инде ачык, чишелгән мәсьәлә санала. Чуваш теле белгече, филология фәннәре докторы Г. В. Егоров үзенең соңгы бер хезмәтендә *р—з* тәңгәллеген хәтта чуваш теле белән татар теле арасындагы иң төп аерманы күрсәткеч билге итеп санаганлыгын белдерә. Безнеңчә, мәсьәләнең асылы анда түгел. Чөнки *р—з* тәңгәллеге татар һәм чуваш телләре арасы белән генә чикләнми. Хәзерге татар теленең үз эчендәге урта һәм көнбатыш диалектлары да нәкъ шушы ике авазны тәңгәл куллануда бер-береннән сиземле аерылалар. Без моны йөкләтү юнәлеше кушымчасы әйтелешендә бик ачык күрәбез. Ул кушымчалар: *кар—кыр* һәм *каз—кыз*. Урта диалектта һәм әдәби телдә *яткыр, коткар, мендер, кидер* дип әйтелә торган боерыкларны көнбатыш диалект вәкилләре *яткыз, котказ, менгез, кигез, кергез*... дип *з* авазы белән әйтә. Бу момент, безнең уебызча, киресенчә, татар теленең урта диалекты вәкилләрен чувашка якынайтып, гомумән, кыпчак төркеме төркиләрдән аера һәм, шул нигездә, аларның болгар төркиләре телен дәвам иттерүчеләр булуын раслый.

Лингвистик фактлар Идел-Кама болгарлары составында *р*лаштыру диалекты *з*лаштыру диалектына

---

[1] Н. И. Золотницкий „Корневой чувашско-русский словарь“, 15 бит

караганда чагыштырмача көчле һәм борынгырак булу турында сөйлиләр. Ул фактлардан берсе һәм иң көчлесе чуваш телендә *р* авазының һәм тамырларда, һәм аффиксларда нык сакланган булуыннан гыйбарәт. Мисаллар:

| татарча | чувашча |
|---|---|
| *каз* | *хер* (гусь) |
| *кыз* | *херь* (дочь) |
| *көз* | *курь* (осень) |
| *тугыз* | *туххырь* (девять) |
| *сигез* | *саккыр* (восемь) |
| *йөз* | *сьурь* (сто) һ. б. |

Билгеле бер төркем сүзләрнең һәм *р,* һәм *з* аваз-хәрефләре белән янәшә язылышлары болгар-татар кабер ташъязмаларында XIII—XIV йөзләргә чаклы дәвам итә. Берничә мисал китерик:

„Алты жур тухырван алтыс жал ит“

آلطن جورطوروان آلطس جال ات

„жиат жур жал“ جيات جور جال

„йитте йөз йыл“ ييتى يوز يل

Идел-Кама болгарлары телендә *з* авазы урынына *р* авазын йөртү борынгырак булганлыкны хәзерге чуваш телендәге сакланып калган юклык кушымчаларыннан *мар* һәм *сыр* ышандыргычрак дәлилилләр. Хәзерге татар телендә юклык кушымчасы *сыз—сез* чуваш телендә *сыр—сер* вариантында сакланган. Мәсәлән: чув. *ачасыр*—татарда *баласыз;* чув. *аттесер*—тат. *атасыз* һ. б. Юклык кушымчасының *сыр—сер* варианты борынгы төрки диалектларда бик күптәннән үк булган. Без аны Орхон язмаларында ук (VIII йөз) очратабыз. Мәсәлән: анда *„әллегег әлсерәтдемез, каганлыгыг кагансыратдымыз...“* дигән фразаны тикшереп карыйк. Мондагы *„әлсерәтдемез“*—илсез иттек, илсезләндердек, *„кагансыратдымыз“*—хансыз иттек, хансызландырдык дигән мәгънәне аңлаталар; димәк, бу сүзләрдәге *сыр—сер*—юклык кушымчалары (сез—сыз) булып тора.

Шул рәвешчә, *сыр—сер* формасы, күптәнге булarак, болгар кабиләләре аркылы чуваш теленә кереп

калган. Хәзерге татар теленә исә шул ук кушымчаның *сез—сыз* варианты урнашкан.

Шундый ук инкарь төшенчәсен тәгъбир итә торган *мас—маз* кушымчасының бүгенге чуваш телендәге *мар* варианты исә, безнең белүебезчә, борынгы төрки язмаларның берсендә дә күренми һәм, без (шартлы рәвештә) бу форманы болгар-чуваш кушымчасы, дип атыйбыз. Мәсәлән: чувашча *кирлемар* сүзе, татарча—*кирәкмәс,* дөресрәге, *кирәк* (*и*)*мәс* дигән сүз.

Димәк, татар теле формалашу процессында, *р* ның тәңгәле *з* (*с*) авазы активлашып, *маз→мас* урнашкан була. Ләкин шуны әйтергә кирәк, *мар* варианты беләи беррәттән, *мас* формасы чуваш теленә дә кергән. Мәсәлән, чуваш *каймастеп,* ди (бармасмын—бармыймын, дигән сүз). Чуваш телендә бу форма соңга табарак кергән күренеш булса кирәк.

*Сыр* (*сер*) һәм *мар* (*мәр*) формалы юклык аффиксларының татар теленә дә азмы-күпме кереп калган булулары турында кайбер фикерләр генә әйтә алабыз. Әхмәт Булатов үзенең моннан берничә еллар элек ясаган гыйльми докладында татарның әлсерәү сүзендәге *сер* кушымчасын инкарь аффиксы *сез* нең борынгы варианты дип таныганлыгын аңлаткан иде. Аның карашынча, *әлсер=әл* (хәл), *сер* (сез), ягъни *әлсерәү*—хәлсезләнү була. Безнең уебызча, Булатовның бу аңлатмасы шактый мавыктыргыч һәм ышандыргыч.

Шул ук рәткә куеп, хәзерге татар телендәге *исәр, җүләр* (юләр), *сыңар* кебек сүзләрдәге *әр—ар* кушымчаларын да борынгы *сыр—сер* кушымчасыннан кыскарган вариантлар итеп карарга мөмкин. Димәк, *исәр,* асылда, *иссәр* (иссез, аңсыз), *җүләр ⟵ җүлсәр* (җүнсез — юлсыз), *сыңар ⟶ сансар* (сансыз, пары юк, ялгыз мәгънәсендә) булып чыга. Шул рәвешчә, *р↔з↔с* авазлары тәңгәлләшү күренеше хәзерге татар теле өчен шактый борынгы, еракта калган факт булып тора. Ләкин бу тармакны киңрәк һәм тирәнрәк тикшерәсе бар әле.

### в. Э—й—җ авазлары арасындагы тарихи тәңгәллек, чиратлашулар

Иң элек *й* авазының үзе турында тарихи белешмә бирик. Рус лингвистлары, шактый озак еллар буе, бу авазның табигате турында бәхәс алып барганнар.

Бераүләр моны тартык, икенче берләре исә ярым сузык (иҗек ясамый торган сузык) дип атаганнар. Бу мәсьәлә рус телендәге дифтонглар табигатен билгеләү уңаенда килеп чыккан була.

Татар теле тарихында *й* авазы, — барыннан да элек, иҗек ясамый торган кыска сузык. Аның иң характерлы үзенчәлеге күтәрелмә һәм төшерелмә дифтонглар ясаудан гыйбарәт. Мәсәлән: *йа* (я), *йә* (я); *йу* (ю); *йү* (ю); *йо, йө йэ* (е), *йы* (е) — күтәрелмә дифтонглар; *ай—әй, уй—үй, ой—өй*; *ый—ий* (диалекталь) төшерелмә дифтонглар.

Татар телендәге *й* авазының үзенчәлеге итеп, югарыда тикшереп үткәнебезчә, беренчедән, билгеле ритмик, интонацион, басым көчеше яки көчәеше шартларында аның озын сузык *и* дән кыскаруын, икенчедән, тартыклардан *җ, з* (d), *к—г* авазлары белән тәңгәлләшүен санарга кирәк.

Бу авазларның борынгы төрки телдә үзара тәңгәлләшеп йөргән булулары турында XI йөз филологы Мәхмүд Кашгари, гомумән төрки телдә *й* авазы белән башлана торган сүзләрнең барысы да угыз һәм кыпчакларда *э* (әлиф) яки *җ* авазы белән әйтеләләр дигән мәгълүматны бирә. Аның үзе китергән мисаллар:

йылыг сув — (җылы су) يلغ سوو

Элыг сүв — (җылы су) الغ سوو

энжүг — (энже) انجوع

җәнжүг — (энҗе) جنجوع

Иң элек монда шундый бер искәрмә кертергә тиешбез. Кашгариның кыпчак, угызлар *й* урынына *җ* әйтәләр дигән белдерүен без шартлы рәвештә генә кабул итәбез, чөнки кыпчак төркеменә кергән төркиләрнең барысы да җләштерүчеләр санала алмыйлар, шулай ук угыз төркеменә дә җләштерү хас түгел. Ләкин безгә фактның үзе житкән, *й—э—җ* авазлары борында ук бер-беренә тәңгәл йөргәннәр.

Татар теле формалашу тарихында *й—җ* тәңгәллеге, ягъни боларның янәшә фонема булып йөрүләре борынгы чор язма документларында аз чагыла, хәтта Бөек Октябрь социалистик революциягә чаклы йләштерү варианты өстенлек алып килә. Безгә мәгълүм

булганча, совет чоры татар әдәби телен фәнни эшкәртү уңаенда гына *й* һәм *җ* авазларын куллану буенча конкрет законлылык кертелә. Җирле диалектларда исә *й—җ* тәңгәллеге әле бүгенге көндә дә шактый киң күләм ала, алай гына да түгел, бу момент, бер яктан, урта диалект, икенче яктан, көнбатыш һәм көнчыгыш диалектлар арасындагы төп аерманы билгеләү күрсәткече дә булып тора.

Болгар-татар чоры язма документлары телендәге фактларга караганда, анда йләштерүче һәм жләштерүче сөйләшләрнең булганлыгы ачык. Без моның мисалын ул чорның эпитафик әдәбияты (кабер ташъязмалары) текстларында күрәбез. Берничә үрнәк.

**җ белән һәм й белән язылган текстлар**

1) Ахирәт ятуы һижрәтдән алты жөр тохур ваным жал. (1291 елга туры килә) үз тексты:

آخِرَةْ يَطُوْ هِجْرَةْ دان آلطى

جور طوحور وانم جال ...

2) Тарих жиат жур жерм үжем жал...

تاريخ جيات جور جرم جم جال

جيات جور (جوت) جيرم بيالم جال

(Тарих жиде йөз егерме өч ел, дигән сүз. 1323 кә туры килә.)

3) Җиат җүр жерм биалем жал жерм сәкер (сикез) куан ите.

(1325 елга туры килә.)

4) Вафат тарихы *җиат җүр җирмә* экшәр *җал.* (722 нче ел дингә сүз.)

1. Былгари Муса угылы Рәҗәб зиарате торыр... Ахир вафаты бирелмеш тарихта *йите йөз икерме тукызында* ирде.

2. Рабигаль ахыр аеның сәкезендә, тарих *йите йөз утуз тургтә* ирде. (1338 елга туры килә).

3. Екерме ике яшендә вафат булды, һижрәтдә *йите йөз* унбердә. (1311 елда була.)

4... *Йикерме ике йәшенә* вафаты булды... йылы эт җыр-

( جرتار )

тан *йите йөз* утуз *йитедә.*

Күренә ки, бу текстларда бер төркем сүзләрне *й* һәм *җ* хәрефләре белән ике төрле язып йөрткәннәр. Әйткәнебезчә, моннан соңгы чорларда (XIV йөзләрдән соң) бу төр янәшәлек күзәтелми.

Кайбер лингвистлар һәм тарихчылар болгар кабер ташъязмаларындагы җләштерүне чуваш теленә хас күренеш итеп аңлатканнар, ягъни, аларча, „җиат җур“ дип язылган ташлар чуваш теленә кайтып кала була. Икенче төрле әйткәндә, болгар чорындагы кабиләләрдән тик чувашлар гына *җ* төркеменә кергәннәр булып чыга. Бу дөрес түгел. Моның дөрес булмавын хәзерге татар теленең үзендә үк, югарыда әйтелгәнчә, *җ* һәм *й* диалектларының яшәп килүе күрсәтеп тора. Болгар дәүләтенә кергән төрки кабиләләренең *җ* һәм *й* төркемнәренә бүленүләре болгар һәм чуваш кабиләләре белән генә чикләнмәгән, әлбәттә.

Мәсьәлә ачыклана төшсен өчен, без тагын түбәндәге детальләрне дә өстәргә тиешбез. Хәзерге татар теленең урта диалектында җ авазының көчле һәм бик күптәннән килгәнлеген, беренчедән, Кама тамагы урынчылыгында бу авазның хәтта сүз уртасындагы *й* урынына һәм *з* авазы урынына йөрүе, мәсәлән, *Мәрҗәм* (әдәб. Мәрьям), кәҗә (коза) һәм, икенчедән, моның берничә варианты булу да раслый. Урта диалект сөйләш һәм урынчылыкларында әле бүгенге көндә дә *җ* авазының *дж*, *зж*, *дз* вариантлары бар. Мәсәлән: *джук, зжук, дзук* (юк).

Шул рәвешчә, бу фактлар, бер яктан, *җ* авазының татар теленә болгардан килүенә һәм, икенче яктан, бу авазның *й* авазыннан үзгәргән вариант кына түгел икәнлегенә дә ышандыралар.

### г. *Й—з—d—г* арасындагы тарихи тәңгәллек һәм үзгәрешләр

*Й* авазының тәңгәллеге *җ* белән генә чикләнми, борынгы язма документларда күренгәнчә, ул тагын *з—d* һәм *г* авазлары белән дә чиратлаша.

Бу турыда М. Кашгари түбәндәге мәгълүматны бирә: „Кыпчак, ямәк, суар, болгарларның русларга һәм румнарга якынрак яшәүчеләре *d* авазын ачык *з* белән әйтәләр“[1], — ди ул, һәм мисалга „*adak*“ (آداق) — *азак* (آزاق) формаларын ала (болар икесе дә *аяк* дигән мәгънәне аңлаталар). Шуңа ук

---

[1] Мәхмүд Кашгари, „Диване лөгать төрки“, 1 т., 33 бит.

ялгап (34 бит), *М.* Кашгари төрки халыкларда *й* белән *з*, *ď* авазларын тәңгәл куллану да бар икәнен әйтә; монысына мисал итеп, „Карын *тудты* (قارن تودتى)

һәм „карын *туйды*“ (قارن تويدى) тезмәләрендәге *тудты—туйды* формаларын китерә.

Димәк, Идел буе болгарлары ул чорда ук (X—XI йөзләр) *з*, *d* авазлары урынына *й* авазы әйтә торган булганнар.

Монда бик әһәмиятле тарихи бер моментның астына сызып китәргә тиешбез. *М.* Кашгари Идел буе Болгар, Суар, Кыпчак кабиләләре телендә тулы сызгырык *з* авазын (тешләрара аваз) *d* дан (тел-теш авазы) аерып әйтү бик күптәннән килеп, бу аерманың руслар белән аралашу нәтиҗәсе булуына ишарә ясый. Бу бик характерлы һәм игътибарга лаеклы момент.

Татар язма әдәбияты тарихында *з*↔*d*↔*й* аваз хәрефләрен тәңгәл йөртү, ягъни янәшә куллану XVII йөзләргә чаклы дәвам итә. Бу алым билгеле бер төркем сүзләрнең язылышында бик ачык чагыла. Ул сүзләр, башлыча, түбәндәгеләр:

*азак* || *адак* ⟶ *айак* (нога).

*Азак* формасындагы *з*, традицион рәвештә, күпчелек тарафыннан *адак* (آداق) , ягъни тел-теш аваз хәрефе белән язылып килә. Берничә мисал:

„*Адакы* берлә орды“ („Н. Ф.“).

А. Гарнати сүзлегендә дә (XV йөз) „адак“ (آذاق)

язылган. „Ике *адакым* бардыр“ (آذاقم) (XVII йөз).

Шуның белән бергә, бу сүзнең *айак* (آياق)

формасында язылуы да бик ерактан башланган. Мәсәлән: „Баг — богауын чишмәгел *айагындан*“, „Әл — айакым“ („Йосыф - Зөләйха“ текстыннан).

Бу факт артында характерлы ике момент ята. Беренчедән, *айак*, һичшиксез, борында ук гомумхалык телендә урнашкан форма булып тора, *азак* || *адак* исә, җирле диалектларның берсенә хас форма рәвешендә генә, язма телдә сакланып килгән; икенчедән,

*й—з* тәңгәллегенең бүгенгә чаклы сакланган калдыгы жирле сөйләшләрдә очрый торган *йил* || *зил*; *йиләк* || *зиләк*; *йыйылыш* || *зыйылыш* (Беренче Май районында) һ. б. фонетик формалардан тора.

*Кадгу* ⟶ *кайгы*. Борынгы чорда ук боларның икесе дә очрыйлар. Мәсәлән, „Н. Ф." та *кадгу, кадгулуг*; „Й. З." да исә, *кайгурмагул* формалы язылыш очрый. Аннан соңгы якта *кадгу* формасын күрмибез.

*Кадгы* || *казгы* формасының калдыгы, дөресрәге, шул тамырдан ясалган сүз *казгану* (забота) була. Халык жырларында бу сүз йөргән, ни өчендер, әдәби телгә кертелмәгән.

Хәзерге *кое* сүзенең *кодок* || *козык* формасы „Н. Ф." та гына бар, бүтән текстларда, әгәр дә без ялгышмый торган булсак, система рәвешендә, *койу* („Й. З." да), *кое* дип язганнар.

*Кодок* || *козык* формасы кое сүзенең этимологик тамырын *казу, казылган* төшенчәсенә илтеп тоташтыра: *казу* (*з* ⟶ *й*) *койу*—*кое*.

Борынгы язмаларда *ийә* (хужа) мәгънәсендә *изә* формасы йөри, һәм бу форма XVII йөзләргә чаклы дәвам итә, аннары *ийә* формасы урнаша. *Сүзләү* ⟶ *сүйләү, сүзләмәк, сүзләгәй, сүзлә* формасы XVIII йөзгә чаклы килә, ләкин, шуның белән беррәттән, „*сүзен сүйләр*", „*җавап силәр*" („Й. З.") формасы да бик күптәннән үк әдәби язмаларга кергән була.

„Н. Ф." та *куймады* сүзенең *кузмады*, ягъни *й* урынына *з* язылган формасы бар. Димәк, *куй* || *куймак* сүзенең дә *куз* || *кузмак* дип, *з* белән әйтелеше борынгы төрки кабиләләренең кайберләрендә булган икән. Шулай ук *айырсаң* сүзенең дә *адырсаң* (آذرساڭ) формасында язылышын очратабыз.

Кыскасы, *з* ⟷ *й* арасындагы борынгы тәңгәллекне раслый торган байтак кына материаллар бар.

*Йыгылу*—*йыйылу*—*җыелу*. Болардан борынгысы—*йыгылу*, һәм бу форманы без „Н. Ф." та гына очратабыз. Борынгы язмаларда *тикү* (тийү)—„Сезгә *тикмәсүн*" (тимәсен, „Н. Ф.")—сүзе дә очрый һәм бу форманы без XVII йөздәге текстларда да күрәбез.

*К*—*г* һәм *й* авазлары арасындагы тарихи тәңгәллекнең булуы һәм борында *к*—*г* белән әйтелгән сүзләрнең соңыннан *й* белән әйтелешкә күчүләре ул сүзләрнең

этимологияләрен, „беренчел“ тамырларын эзләргә мөмкинлек бирә. Мәсәлән, урта диалектның Бәрәңге сөйләше татарларында *тиеш* сүзен *туган, кардәш* мәгънәсенә йөртү бар. Гомумтатар телендә исә без бу сүздән *тиә торган,* мәсәлән, *тияр* хакы (должная цена, соответствующая стоимость), *тиәр* өлеше, шул әйбергә тигез бәясе, *тиеше* (то, чему он достоин) кебек төшенчәне аңлыйбыз. Грамматик анализ ясаганда, бу сүздән *тик + иш, к → й = тий + иш → тий → эш* килеп чыга. *Иш* — коллектив, бергә, пар (иш-куш), *тигез* (сердәш ← сердә иш, тигез) мәгънәсен бирә; *тик — тиң* (бәрабәр) *тик* ← тук ‖ туг (ыруг), шуннан *туган,* димәк, *тук → тик, тик + иш → тикиш* → (к → й) → *тий-эш,* түбәндә, бер ыруг кешесе, ыругдаш дигән сүзгә барып тоташа, дип уйларга мөмкинлек бар. Бу бик нормаль халь, чөнки кешеләр арасында якынлык, туганлык, бердәмлек коллектив тормыш белән билгеләнә; кешенең аңын яшәеше билгели, һәм ул, борынгы кеше, үзенең ыругдашларын, гүяки, бер карыннан туганнар, карындашлар итеп күзаллый.

„Сүзләрнең һәм әйтелмәләрнең мәгънә ягы телне өйрәнү эшендә җитди әһәмияткә ия. Шунлыктан тел гыйлемендә семантикага (семасиологиягә) үзенә лаек урын бирелергә тиеш“[1], — ди И. В. Сталин.

Аңлашыла ки, татар теле фонетик төзелеше уздырган үзгәреш, алмашынуларны күзәткәндә, семантикага да, теге яки бу сүзләрнең мәгънәләре тарихына да лаеклы урын бирергә тиешле булабыз. Ләкин бу тармак буенча эш иткәндә, коры семантика, табигый материясеннән аерылып алынган „саф“ мәгънә белән генә мавыгып китүдән сак булырга кирәк.

Й авазының икенче бер тартыклар белән тәңгәллеген күзәткәндә, М. Кашгариның, кайбер төрки телләрдә *й* урынына *н* әйтәләр дигән искәрмәсен дә хәтердә тотарга ярый. Моңа мисал итеп, ул *куй → кун* (мәгънәсе *кайсы* га туры килә)[2].

Гомумтатар телендәге *кайда* ның көнбатыш диалектының кайбер сөйләшләрендә *кане* дип әйтелүе, бәлки, әнә шуңа бара торгандыр.

[1] И. В. Сталин, Марксизм һәм тел гыйлеме мәсьәләләре, Татгосиздат, 1951 ел, 34 бит.

[2] М. Кашгари, „Диване лөгать төрек“, 1 том, 32 б.

## д. Б—м авазлары арасындагы тарихи тәңгәллек

Бу авазларның артикуляцион базалары бер-берсенә бик якын: *м* иреннәрнең бикләнүләре, *б* исә, киресенчә, бикләнгән иреннәрнең кинәт ачылулары белән ясалалар. Шуңа күрә булса кирәк, төрки телләрнең күбесендә бу авазлар сиземле тәңгәлләшәләр.

Борынгы төрки телләрдәге *м—б* тәңгәллегенә карата М. Кашгари характерлы мәгълүмат бирә: „Төрки сүзләр башында килә торган *м* авазы угыз, кыпчак һәм суарларда *б* гә күчә",— ди. Мисалга түбәндәге сүзләрне ала: төркичә — *„мән бардым"*, угыз, кыпчак, суарларда — *„бән бардым"*, төркичә *„мунь"* (муен), угыз, кыпчак, суарларда — *„бунь"* дип әйтелә[1],—ди ул.

Татар теле тарихында бу ике авазның үзара чиратлашуы характерлы күренеш ала. Конкрет мисаллар итеп, түбәндәге берничә сүзне теркәргә мөмкин.

*Мән* (мин) — *бән* (зат алмашлыклары):

— Бу күндин соң *бәнем* өчен нә әйтерсең? („Й. З.")

— Ул сәбәбдин *мәне* монда куйдылар;

Бүре *монда* кермәгәй, тиб айдылар (М. Мөхәммәтьяр, XVI йөз).

*Мең — бең* (сан исеме):

— Ун ике *бең* ат берлә атландыйлар („Й. З").

— Кәтәбе, галә яд-эл-зәгыйфь, Кадир Гали бине Хусум би тарихның *мең* дә унберендә куян елы ... бу тарихны тәмам кылды (Җәмаиг-эл-тәварих, 1600 еллар).

— *бона — мона* (күрсәтү алмашлыгы)

— *бонча — монча*

— *бондаг — мондаг*

— *боны* һичкемгә аймагыл („Й. З.").

— *Моны* килтердем (М. Яр).

— *бенү — менү*.

— Ат *бендерделәр* („Й. З.").

— Учакка *менде* („Н. Ф.").

— Тәүәсенә *менеп*, ул дәм тотты юл (М. Яр).

Мисаллардан күренә ки, *м* урынына *б* әйтү язма әдәбият телендә ул чаклы сиземле урын тотмый, хәтта „Йосыф-Зөләйха" да гына күренеп, борынгы китапларның барысында да *м* куллану системалы төс ала.

---

[1] М. Кашгари, „Диване лөгать төрек", 1 т., 32 бит.

Идел-Кама татарлары телендә *м* авазының төп урын алуы — бу, асылда, болгар кабиләсенә, көнбатыш диалектында *б* әйтү исә суар һәм кыпчак кабиләләренә барып тоташа дип әйтә алабыз.

Татар теленең хәзерге җирле диалектларында бу төр тәңгәллекнең калдыгы, дөресрәге, дәвамы әле шактый сиземле; мәсәлән, көнбатыш диалектының кайбер сөйләшләрендә *бунь, буен, бәңа, бусы* һәм, киресенчә, *белән* сүзен *мән, менән* дип әйтү; *балан, бөрлегән*... кебек сүзләрне *малан, мөрлегән* дип әйтү (Тау ягында) — боларның барысы да әнә шул ерактан килгән күренешне раслыйлар.

Рустан алынган сүзләрнең татар теленә, бигрәк тә урта диалект вәкилләре теленә *м* белән урнашкан булулары да шуны күрсәтә. Мәсәлән, рус. — *бочка*, тат. — *мичкә*, рус. — *печь*, тат. — *мич*, *пастьба* — *пажма*, *болота* ⟶ *мулата* (диал.), *баклушка* ⟶ *мукләшкә* һ. б. *Бадья* ⟶ *мадиа, бадиан* ⟶ *мадиан, богыл* ⟶ *могыл, букәй* ⟶ *мукай* ‖ *мокай*, хәтта *мәче* ⟶ *песи* сүзләрен дә шул ук планда карарга була.

Әйтергә кирәк, мондый тәңгәллек чагыштырмача борынгы якта булган һәм, шуннан чыгып, без, бигрәк тә, икенче бер телләрдән, мәсәлән, рус теленнән кергән сүзләрнең татар телендә яшәү тарихларын билгели алабыз.

Ниһаять, гомумтатар телендә *бу* (күрсәтү алмашлыгы) сүзенең баш килештә генә үзенең „төп" формасын саклап, калган килешләрдә *моның, моңа, моны, моннан, монда,* ягъни *м* белән әйтелешкә күчүе дә ерак тарихтан ук килгән һәм характерлы күренеш булып тора. Шул рәвешчә, бу момент татар телендә *бу* алмашлыгының тамыры суар, кыпчакча, килешләр белән төрләнү уңаендагы формасы исә болгарча дигән нәтиҗәгә килергә мөмкинлек бирә. Мондый фактлар үз чиратында гомумтатар теле формалашу процессы тарихында җирле диалектларның катнашу чамасын ачарга таянычлы материал була алалар.

### е. Б—у (v) авазлары арасындагы тарихи тәңгәллек

*Мәгълүм* төркем сүзләрдә *б* һәм *у* (иҗек ясамый торган *у* яки *вау*) авазларының чиратлашулары, ягъни бер-берсе урынына йөрүләре борынгы телдә шулай

ук характерлы күренеш санала ала. *Б* авазын *у* (v) га күчерү — бу, төбендә, борынгы угыз диалектларына хас һәм, гомумән, борынгы төрки диалектлар белән угыз кабиләләре теле арасындагы аерманы билгеләргә дә ачык күрсәткеч булып тора.

Татарның язма әдәбияты тарихында *б* урынына *у* (v) язу, мәгълүм рәвештә, үзенчәлекле бер төс ала. Борынгы чорда без моны „Йосыф-Зөләйха" текстында очратабыз. Аннан соң Утыз Имәнигә чаклы (XVIII йөз) бу форманы кулланучы очрамый. Утыз Имәнидә исә моңа зур гына урын бирелә. Мәсәлән:

— Безем илә Йосыфның билә *уарсун*... („Й. З." 6 бит, *барсын* дигән сүз).

— Күрдекендин сезә кәлүб хәбәр *уйрсун* (шунда ук, *бирсен* дигән сүз).

— Галәм кырдын *корауыз*, *үлдүрәүез* („Й. З.", 7 бит, *кырабыз, үтерәбез* дигән сүзләр).

— Укларымыз алгалы *уардык* иде („Й. З.", 14 бит).

— Укун алуб кош атмага *уарды* („Й. З.").

Күренгәнчә, *бару, бирү* сүзләре һәм *без* кушымчасы монда *уару, уиру, уез* формаларында язылганнар. XIII йөзләрдә тик бер генә китап текстында очраган шушы алымны XVIII йөздә, әйткәнебезчә, Утыз Имәни кабатлый. Мисаллар:

— Егет булсаң, егетлек күрген илгә,
Мәхәббәт путасын багла билгә;
*Үиреб* даим тәсаддык әйлә ихсан,
Сәңа куншы адәмләр *улса* нокас.

Монда „биреп" сүзендәге *б* авазы *ү* (v) белән алмаштырылган.

Билгеле, Утыз Имәнинең бу алымны алга сөрүе очраклы күренеш кенә түгел, бәлки, ул чорлардагы жаргонлаштыру тенденциясенең билгеле бер чагылышы булып тора. XIX йөзгә чыккач, татарга төрек телен „әдәби" тел итеп кертү тенденциясе белән агуланган буржуаз идеологлар шул ук стильне кабатлап маташалар, ләкин тарих боларны юкка чыгара.

Хәзерге татар теленең сөйләм практикасында (язуда түгел) кайбер сүзләрдә *б* урынына *у* (v) әйтеп йөртү бар, ләкин бу момент инде хәзер хәтта сизелмәслек дәрәҗәдә азайган. Андый сүзләр: *кабып* (языла) — *кауып* (әйтелә), *ябып* (языла) — *яуып* (әйтелә), *табып* (языла) — *тауып* (әйтелә).

Мондый әйтелеш әнә шушы борынгы тел калдыгы булып тора.

### ж. *Т—д* авазлары арасындагы тарихи тәңгәллек һәм үзгәрешләр

Бу авазлар турында сүз башлагач, гомуми бер проблема турында әйтеп китү кирәклеге сизелә. Проблема моннан тора: кешенең сөйләм сәләте формалашу процессында саңгырау авазлармы әллә яңгыраулармы элегрәк барлыкка килгәннәр? Бу сорауга кырт кисеп җавап бирергә ашыгу урынсыз булыр иде.

Төрки телләр өстендә зур гына күзәтүләр алып барган белгечләрнең кайберләре, мәсәлән, С. Е. Малов, бу телләрдә саңгырау авазлар яңгырауларга караганда борынгырак дигән фикерне яклый.

Һичшиксез, бу проблеманың тел тарихы өчен әһәмияте зур. Һәм моңа, Ф. Энгельс әйткәнчә, маймылның дорфа бугазы бүленмәле авазларның берсе артыннан икенчесен әйтә алуга ипләшкән булу моментыннан карап килергә кирәк. Аннары саңгырау тартыклар белән яңгыраулар арасындагы әйтелеш аермасы да исәпкә алынырга тиеш. Саңгырауларда тавыш бөтенләй юк, аларда тик шау (шум) гына бар. Яңгырауларда аз булса да тавыш бар. Икенче төрле әйткәндә, яңгыраулар тавыш бирү ягыннан саңгырауларга караганда ипләшә төшкән авазлар санала алалар. Менә шушы хәлдән чыгып, бәлки, саңгыраулар борынгырак, яңгыраулар чагыштырмача соңгырак дип әйтергә була торгандыр.

Бер яктан, язма документлар, икенче яктан, хәзерге көндә яшәп килә торган диалект һәм сөйләшләрдәге тере фактларга караганда, борынгы болгар-татар телендә саңгыраулаштыру шактый көчле булганлык сизелә. Без моны аерата *к, т* аваз хәрефләренең чагыштырма күп һәм озак вакытлар буена кулланылышта булулары белән аңлатабыз.

Болгар-татар эпитафикасы текстларында тлаштыру һәм клаштыру система булып тора.

Берничә мисал:

„Алты җөр *сикеруан* җиатеш.
Җал... куан *ите*... (1288 ел).
„Тарих *йите* йөз *йәкерме түрттә*“ (1324 ел).
„Тарих *йите* йөз *утуз түрттә*“ (1334 ел).

„Тарих *җиат* жөр җерм *сәкер* жал... *сәкер* куан *ите*“ (1328 ел).

„Бәлкүш ул Хөсәен *блуку*“ (XIII йөз).

„*Йәкетләр* күрке, күңелләр *үзәке*, галимнәрне агырлаган, ятим, тол, үксезләрне асраган Муса углы... (1317 ел).

Бу текстларда хәзерге телдәге *сигез* ⟶ *сәкер*, *йәгерме* ⟶ *йәкерме*, *дүрт* ⟶ *түрт*, *җиде* ⟶ *йите*, *иде* ⟶ *ите*, *билгесе* ⟶ *блуку*, *йәгетләр*⟶*йәкетләр*, *үзәге* ⟶ *үзәке*... дип язылганнар.

Күренә ки, эпитафик әдәбиятта саңгыраулаштыру өстенлек ала.

Гомумтатар теленең хәзерге көнге аерым диалект, сөйләшләренә килсәк, эш болай тора. Урта диалектның Минзәлә сөйләшендә *ди* (әйтә) сүзен *ти* дип әйтү күзәтелә. Мисаллар:

— „Ике җәшлек ат кырыкмыш *тип* атала“ (Актаныш); „Җыйылышка барам *тиде*“ (Минзәлә) һ. б.

Татар теленең көнчыгыш диалекты гомумән саңгыраулаштыручы булуы белән характерлы. Алар *б, д, з* авазлары урынына, системалы рәвештә, *п, т, с* авазлары куеп сөйлиләр. Мәсәлән, „*Сигес яныпыс касерентә*“ (Тобол). Бу фразадагы „*яныпыс*“ — җаныбыз, „*касерентә*“ — хәзерендә дигән сүзләр булалар.

Менә боларның барысы бергә югарыда куелган тезисны, ягъни борынгы татар телендә саңгыраулаштыру көчлерәк булганлыкны күрсәтәләр, дип әйтә алабыз.

*Т—д* авазлары арасындагы тарихи тәңгәллек һәм бер-беренә күчеш моментлары түбәндәгеләр белән билгеләнәләр. XIII—XIV йөзләр язма әдәбиятында байтак кына сүзләрнең *т* һәм *д* белән, ягъни ике формада язылып йөртелүләре бар.

Мисаллар:

— Ничә *дөрле?* Өч *дөрле*...

— Йосыфның биленә йәб *дагуб*...

— Зөләйха бер көн ятуб бер *дөш* күрде.

— Колак *дотыб дыңлаңыз*!

— Сәндәк (кеше) *дугмыш дәгел*...

— *Дезен* чүгеб...

— *Дибрәнде*, ул Йосыфка сәлам уйрде (мисаллар „Й. З.“ дан).

Бу фразалардагы *дәгел* (түгел), *дөрле* (төрле), *дөш* (төш), *дотыб* (тотып), *дыңлаңыз* (тыңлагыз), *дугмыш*

(тумыш), *дезен* (тезен), *дибрәнде* (тибрәнде) сүзләре *д* белән язылганнар.

Шул ук чорларга караган „Нәһҗ-эл-фәрадис“ һ. б. китапларда исә, мондый сүзләр күбрәк очракта *т* хәрефе белән язылганнар.

Мисаллар:

— Оглан *әйде,* андаг кылаен *тиде.*

— *Тәкый тотдылар,* ул *үлтергәнне.*

— Бер кичә ятур иркән куркуб уйганды, *төшләр* күрүб торор.

— Сандыкны *ачты*...

(Мисаллар „Н. Ф.“ тән).

— *Турт* яндагы баглар... („Н. С.“)

Мөхәммәдьяр текстларында бу төр сүзләр *„тыңладылар“*, „ул хикәят кылды мәңа, *тыңлаңыз“, „тиңездә* йөрер идек“, *„юлыктым“* һ. б. формаларында язылганнар.

Мөхәммәдьярда хәзерге *тәңкә* сүзен *„дәнкә“* дип язуны очратабыз. Ләкин аның әсәрләрендә *д—т* авазларын алмаштыру бөтенләй юк, дип була. Һәм бу момент язучының үз чоры гомумхалык телендәге әйтелеш формаларын үзләштергән булуын күрсәтә. Шуның белән бергә, *тип* (дип), *тиде* (диде) сүзләреннән калганнарын *т—д* лар белән ике төрле язып йөртү, нигездә, туктала. Тик XVIII йөз азакларында Утыз Имәни һәм XIX йөз азакларында пантюркист буржуа идеологлары гына, *дәгел, дөрлү*... кебек формаларны кулланып маташкан булалар. Күренекле мәгърифәтче К. Насыйри пантюркистларның бу кыланышларын әшәке хата дип саный һәм: *„Кәлди* дип язма — *килде* дип яз, *кәтти* дип язма — *китде* дип яз, *дәгел* дип язма — *түгел* диген, *кәрәк* дип язма — *кирәк* дип яз, *ничә* дип яз — *нәчә* димә, *ничек* дип яз — *нәчек* дип язма...“ — дип халык телендәге әйтелеш нормаларын әдәби телгә урнаштырырга чакырды[1].

Гомумхалык телендә *т, д* авазларын тәңгәл йөртү, ягъни бер үк сүзләрне икешәр төрле, мәсәлән, *даг — тау, дүрт — түрт, дәгел — түгел* һ. б. вариантларында әйтү күптән үк беткән, туктаган. Мондый чуарлыклар, гадәттә, „китап телендә“ традицион рәвештә чагыштырмача озак сакланганнар.

---

[1] К. Насыйри, „Кавагыйде китабәт“, 1892 елгы басма.

*Т—д* авазларының кулланылышы ягыннан хәзерге татар телен борынгы тел белән чагыштырганда, элек *т* белән әйтелгән сүзләрнең бүгенге көнне *д* белән әйтелешкә күчкән булулары һәм, киресенчә, элек *д* белән әйтелгән сүзләрнең *т* белән әйтелеш алган булулары ачыла. Беренчеләренә мисаллар: *түрт* (бор.) ⟶ дүрт; *тип* (бор.) ⟶ дип, *тиде* ⟶ диде; *йите* (бор.) ⟶ җиде... Икенчеләренә мисаллар: *дәгел* (бор.) ⟶ түгел; *дөрле* ⟶ төрле; *дыңла* ⟶ тыңла; *даг* ⟶ тау, дез ⟶ тез...

Димәк, бу авазлар буенча күчеш ике яклы булган, һәм моның тарихи җирлеге гомумтатар теле формалашуга төрле кабиләләр, җирле диалектлар катнашкан булуы белән билгеләнә. Угыз, кыпчак төркеме кабиләләре татар теленә *дләштерү*; болгар, суар кабиләләре исә *тләштерү* вариантларын керткәннәр.

Борынгылыкның калдыгы рәвешендә, гомумтатар теленә *т* яки *д* белән урнашкан кайбер сүз һәм кушымчаларның аерым диалект, сөйләш, урынчылыкларда ике төрле (*т* яки *д* белән) йөртелүләре әле бүген дә юк түгел. Мәсәлән, *түгел* (әдәб.) ⟶ *дөгел* (Краснобор тирәләрендә), *көянтә* (ур. д. әдәб.) — *куәндә* (Мәл.); *дару* (әдәб.) ⟶ *тару* (Зәй буе); *дип* (әдәб.) ⟶ *тип, тиде* (Минзәлә); *тилмерү* (әдәб.) ⟶ *дилмерү* (Зәй буе); *пышылдау* (әдәб.) ⟶ *пышылтау* (Зәй буе); *төрле-төрле* (әдәб.) ⟶ *дөрле-дөрле* (Зәй буе); *гөрселдәү* (әдәб.) — *гөрселтәү* (Зәй буе); *дага* (әдәб.) ⟶ *тага* (Корсун миш.); *тагын* (әдәб.) ⟶ *дагын* (Дөбъяз, Әтнә, Арча һәм Минзәлә урынчылыкларында).

Билгеле, мондый калдыклар, ниндидер очраклы күренешләр генә булмастан, төбендә, татар теле формалашу процессындагы реаль фактлар турында сөйлиләр.

### 3. К—х авазлары арасындагы тарихи тәңгәллек

Иң элек шуны әйтергә кирәк: төрки телләрнең күпчелегенә *к* хас, ягъни бу төркемгә кергән телләрдә *х* авазын куллану чагыштырмача аз урын ала. Хәтта *х* авазы төрки телләрдә яңарак, соңрак урнаш-

кан яки урнашып бара торган аваз ул дип әйтү дә урынсыз булмаячак[1].

Идел буе болгарлары исә, безгә билгеле булганча, хлаштыру һәм клаштыру диалектларына бүленгән булалар. Һәм моны ачыграк итеп тә әйтә алабыз: хлаштыручы — бу Суар диалекты, клаштыручы исә төп болгар диалекты була. Ул чорның кабер ташъязмаларында *тохыр — тукуз, хөрь — кыз, тохырван — туксан* кебек сүзләрнең янәшә йөрүләре шуны раслый — монысы беренче дәлил. Хәзерге көнне аерата Кама Тамагы кебек төбәкләрдә, ягъни борынгы болгарларга чагыштырмача якынрак торган татарлар телендә клаштыруның әле бүген дә көчле саклануы Идел буе төркиләрендә бу авазның өстенлек алган булуын күрсәтә — монысы икенче дәлил.

— *Патыйкымның каты-кабәре* килеп тора. Үзем дә жыш кына *катлар* җазам улыма",— ди Кариле авылының бер әби. Гомумән, керәшен татарлары һәм, өлешчә, мишәрләр *катын* (хатын), *кач* (хач) — *кызыл кач* (кызыл хач), *кат* (хат), *макмыр* (махмыр), *катфә* (хәтфә), *Кадичә* (Хәдичә), *калык* (халык), *казер* (хәзер), *акыры* (ахыры), *кужалык* (хуҗалык), *казайка* (хозяйка), *карактер* (характер), *якшы* (яхшы) һ. б. дип сөйлиләр.

*К* авазының Идел буе татарларында доминант урын тотканлыгына таянычлы дәлил булып, борынгы чорда рус теленнән алынган сүзләр әйтелешендәге үзенчәлекләр дә хезмәт итәләр. Мәсәлән, *сука* (соха), *камыт* (хомут), *сокари* (сухари), *карактер* (характер), *какуль* (хохлатка) һ. б. шундый сүзләр рус теленнән алынганнар һәм клаштырылып урнашканнар. Гарәп, фарсы телләреннән алынган сүзләрнең дә байтагы халыкның җанлы теленә шулай ук клашып кергәннәр. Мәсәлән, *такта* (фарсыча тахта), *казна* (гарәпчә, хәзинә), *каста* (гарәпчә, хәстә) дип әйтү система булып тора.

Боларның барысы да Идел буе татарлары телендә *к* авазы доминант урын тотканлыкны һәм соңыннан гына *х* авазы килеп урнашкан булуны күрсәтәләр.

---

[1] Бу турыда шундый бер искәрмә ясарга кирәк. Н. Ф. Катанов материалларына караганда, *к—х* тәңгәллеге төрки телләрдә бик аз процент урын ала. Мәсәлән, аның таблицасында (таблица 11, к. § 26, „Урянхайский язык", 46 бит), 48 исем белән аталган төрки шивәләренең тик икесендә генә *к—х* тәңгәллеге күрсәтелә.

Татар теленә *х* авазы керә башлау тарихын, якынча, XIV—XV йөзләр белән билгеләргә була. Шуның белән бергә, бу аваз татарның үз сүзләрендә, ягъни төрки сүзләрдә бөтенләй үк юк яки бик сирәк дип тә теркәп үтәргә тиешбез. Татар теленә бу авазның керүен ике моментка бүлеп карарга кирәк, ягъни төрки сүзләрнең *х* белән әйтелүгә күчүләрен бер момент, икенче бер телләрдән алынма сүзләрнең *х* белән урнашуларын үзенә аерым бер момент итеп карау дөресрәк булыр.

Татарның үз лексик фондында *х* белән әйтелә торган сүзләр бик аз, һәм алары да чагыштырмача соңрак чорларда хлаштырылганнар. Андый сүзләргә, башлыча, түбәндәгеләр керәләр: *дәхи*—борынгы телдә *тәкый*—*дагы* формаларында йөргән.

Мисаллар:

— „Йите ярмакка бер күнләк алдылар. Түрт ярмакка дәстар алдылар, *тәкый* ике түшәк алдылар“ („Н. Ф.“).

— „Аның ады һәм *дагый* Йосыф ирде.
Гаклы, күрке сездән *дагы* артук имде“.

— „Нәтә кем Якуб Йосыфе сәвәр иде, Йосыф аның уйлукындан кәтмәз иде, һәм Зөләйха атасына билә *ирде*, бәлки *дагы* артуграк сәвәр имде“. („Й. З.“)

— „Ул картның азакыга төштеләр *тәкый* әйделәр: „И карт, әйт, кем торырсың?“ —тиделәр“ („Н. С.“).

— „Сәңа бер көн *тәкый* килгәй яхшылык“...

— „Ул *тәкый* тоткай кулуң бер көн синең“ (Мөхәммәдъярдан).

— „Дөньяда хуб-хуб эшләр күб торур.
Һич моның тик бере *тәкый* юк торур“.

— „*Тәкый* анда тормадылар, китделәр“ („Кисекбаш“тан).

*Тәкый* ‖ *дагы*—теркәгеч функциясен үтәгән ярдәмче сүзләрдән берсе була. Хәзерге телдә бу сүздән *тагын* һәм *да—дә* теркәгечләре калган. Казан арты сөйләшендә сакланган *дагын—дәген* дә шуның дәвамы булып тора. Борынгы язма әдәбиятта бу чараны күп кулланганнар. Югарыда китерелгән мисалларда шулай күренә. Борынгы чорда моңа синоним итеп *янә* сүзен дә йөрткәннәр.

XVII йөзләргә чаклы фарсының *һәм* ен, өлешчә, гарәпнең *вә* (вә) сен күбрәк куллану хисабына, *тәкый, янә* кысыла башлый. Икенче яктан исә, шул ук *тәкый*

...ына фонетик үзгәртелгән *дәхи* формасын активлаштыру да була. Бу форманы без борынгы әсәр итеп саналган *„Ике былбыл“* хикәясендә үк очратабыз. Мәсәлән, „Бу ике егетнең берсе *дәхи* өйгә килүб керде ..., бу бай хужа кызы *дәхи*, аз булмасын юл хәрежене дип, *дәхи* бер алтун бирде“ („Ике былбыл“). Мондагы *дәхи* ләр әнә шул борынгы *тәкый* ның фонетик варианты булып торалар.

*Дәхи* янына гарәпнең *вә* сен өстәп, *вә дәхи* формасын куллану XIX йөздә көчәеп китә. Моның ачык мисалы Ш. Мәрҗани кебек кешеләр телендә чагыла. Совет чоры татар әдәби телендә *дәхи* бөтенләй кулланылмый башлады. Аның урынына *һәм, шулай ук, тагын* (сирәк), *аннары* сүзләре йөриләр.

Хәзерге татар телендә *катын* һәм *хатын* формалары йөри торган сүзнең борынгы язма әдәбиятта *хатын* (х белән) язылуы күптәннән үк килә. Мәсәлән, „Әйдер, я *хатун*, сәңа нә хәл... нә мәгънәдин бу халә төшдең имде?“ *„Хатун* әйдер: „Я дая, разый улдым!“ „Йосыф әйдер: „Я *хатун*, куйгыл бәне!“ („Й. З.“ дан). „*Хатун* бу сүз берлә ир күңелене алды“ (М. Яр).

Хәзерге телдә *к* белән әйтелә торган сүзләрнең кайберләрен элек *х* белән язу фактлары да булган. Мәсәлән, Шәрәфетдин-әл-болгари „Тәварих-эл-болгария“сендә (1600 елларда язылган) *кытай, якут халкы* дигән сүзләрне *х* хәрефе белән язган. Менә аның җөмләсе. „Бу эклимдә, ягъни йитенче Уралда мотталиг-әл-шәмес (кояш чыгу) вә һәм кичә вә көндезнең сәгатьләре мөхтәлифтер. *Хытайның* Пикин дидеке калгасында... эксары ләйла да (иң кыска кичләр дә, Л. Җ.) тукыз сәгатьдән ким улмаздыр, хәтта *яхут* халкына чыкканча, андан Уралның шәрык тарафында Тубыл суына кәләнчә...“ („Тәварихы Болгария“, 14 бит).

Шул рәвешчә, татар теле формалашу процессында *х* авазының катнашын түбәндәгечә күзалларга туры килә. Болгар кабиләсе һәм тагын башка кабиләләрнең күбесе клаштыручылар булалар. Татар теле тарихында әнә шул клаштыручылык, ягъни *тәкый, катын, кач* (хач)... дип әйтү өстенлек алып килә. Мондый сүзләрнең *х* белән әйтелешкә күчүләре соңыннан, икенче бер телләр йогынтысы белән килеп керә. Мәсәлән, *хатун, дәхи, хан* кебек берничә сүз формасын борынгы татар язучылары Чыгтай әдәбиятыннан алган-

нар. *Хытай* формасы да шуннан ук алынган була; *хур* (лану), *хуш* кебек сүзләр фарсыдан, *халык, хәбәр, хәер* (хәерче), *хәйлә, хикмәт*... кебекләре гарәптән, *хитри, халат* сүзләре рус теленнән кергәннәр.

Хәзерге татар телендә *х* авазы мөстәкыйль фонема санала. Чөнки *кат — хат, ката — хата* сүзләрен без үзләренә аерым мәгънә белдерүчеләр итеп йөртәбез.

### 3. К—г авазларының ясалу урыннары, әйтелешләрендәге үзгәреш һәм аларның бүтән авазлар белән алмашынулары

В. А. Богородицкий татар телендәге калын *къ*, аның мисалынча, *кара — „черный", куй — „овец"* сүзләрендәге *къ* белән *куз, бик* сүзләрендәге нечкә *к* авазы гомумән төрки телләрдә борынгы, башлангыч, бер-беренә бик якын торган (*л — л′* авазлары кебек, ди ул) $к^а$ — $к^и$[1] авазларыннан килеп чыккан булырга тиешләр дип аңлата („Введение в татарское языкознание", 48 бит).

Ул үзенең бу фикерен юнәлеш килеш кушымчасында $к^а$ һәм $к^и$ авазлары бер үк фонема булу белән беркетә. „*Атка* ‖ *эткә* сүзләрендә килгән кушымчалардагы $к^а$, $к^и$ авазларының бер үк морфемада чиратлашулары элек-электән үк (изначально) килгән булмаска тиеш. Алар элекке минималь аермадан ижектәге сузыклар белән бәйләнештә барлыкка килгәннәр. Чыганак фонема итеп $к^а$ ны алабыз",—ди ул (шунда ук).

Димәк, Богородицкий бу ике авазның „беренчеле" итеп палатальләшмәгән, ягъни калын $к^а$ ны саный, һәм нечкә $к^и$, аныңча, артикуляциясе күчү җирлегендә — палатальләшү уңаенда формалашкан була.

В. А. Богородицкий, талантлы күзәтүче буларак, билгеле, коры тезис куеп кына калмый, бәлки, ышандыргыч фактлар китерә. Беренчедән, хәтта калын сузыклар әйләнәсендә килгәндә дә *к* авазының тел арты артикуляциясеннән күчүе һәм, шуның аркасында, бөтен ижек артикуляциясендә бертөрле үзгәрү булуын әйтә. Ул, моңа мисал итеп, татар теленнән көнбатыш диалект *к* сын ала, ләкин мисал китерми.

Соңгы вакытта тикшерелеп ачыкланган материал-

---

[1] $к^а$ — калын к, $к^и$ — нечкә к. Бу билгеләр В. А. Богородицкийныкылар. *Автор.*

лар В. А. Богородицкийның бу аңлатмасын артыгы белән раслыйлар. Көнбатыш диалект вәкиле *к* авазын шул чаклы үзгәртә, хәтта ул тулысынча тел урталыгына күчә һәм үзеннән соң килгән сузыкның да палатальләшүенә (аңкаулашуына) сәбәп була. *Кояш, койма, коймак, кыяр*... кебек сүзләрнең көнбатыш диалектта *киаш, кима, кимак, киар* дип әйтелүләре шуны күрсәтә.

Икенчедән, В. А. Богородицкий мәгълүм комбинацияләрдә *к* авазының *г* авазы белән, соңгысының исә, кайбер сузыклар арасында бөтенләй югалып, сүз азакларында ирен авазы *у* (*v* — вау) яки тел алды авазы *й* гә күчүе булганлыгын да дөрес күзәткән[1].

Борынгы язма текстларны күзәтүдән чыгып, без профессор В. А. Богородицкий ясаган фәнни нәтиҗәләр расланалар, дип әйтә алабыз. Беренчедән, тел арты тирәнлегендә әйтелә торган $к^{а}$ ның алга күчүе унаенда, нечкә $к^{и}$ барлыкка килгән. Билгеле, бу процесс борыннан ук башланган була, ягъни без моны тик татар чорында гына булып үткән күренеш итеп санарга җыенмыйбыз. Шул ук вакытта, татар теле формалашу тарихында да бу процессның булганлыгын, дөресрәге, дәвам иткәнлеген күрсәтә торган фактлар бар. Мәсәлән, борынгы телдә *баек* формалы бер сүз *бик, биек* һәм *бөек* мәгънәләренә йөри. „Йосыф-Зөләйха“ текстында бу сүз нәкъ әнә шундый өч мәгънәдә кулланылган. Мисаллар:

— „Әя углум, инангыл баек бәңа“ („Й. З.“, 4 бит). Бу тезмәдә *баек* „бик ышан“ дигән мәгънәне бирә.

„Бигөнаһмын, *баек белең*, диюр имде“ („Й. З.“, 17 бит). Монда да *баек* „бик белегез“ мәгънәсендә килгән.

„Анлар әйдер, һичгөмансыз *баек* колдыр, колымызның өч дөрлү гаебе уардыр“ (22 бит). Бу тезмәдәге *баек* та шулай ук, *бик, чынлап, дөрестән дә* дигән төшенчәне тәгъбирли.

„Йосыф әйдер: Я Зөләйха, бәне күргел, *баек* Мисыр газизе бәнмен, белгел“ (39 бит). Бу тезмәдәге *баек*, аергыч буларак, *бөек Мисыр* дигән мәгънәне аңлата.

---

[1] В. А. Богородицкий. Введение в татарское языкознание. 49—50 битләр.

Түбәндәге фразада исә *баек*, анык рәвештә, *биек* (высокий) мәгънәсендә килә:

— Хатун әйдер: „Я Йосыф, . . . юхса *баек зиндан* эчерә калурмусын? („Й. З.“, 49 бит).

Югарыда китерелгән мисаллар *баек* сүзенең *бик*, *бөек* һәм *биек* мәгънәләренә йөргәнлегенә ышандыралар. Күренгәнчә, бу сүз күбрәк *бик* төшенчәсен аңлаткан. *Баек* ны шушы мәгънәдә соңгы тапкыр кулланучы Мәүла Колый була. Аңардан соңгы язучыларда очрамый.

Димәк, *бик, биек* һәм *бөек* сүзләре әнә шул *баек*тан үзгәрү юлы белән килеп чыкканнар. Бу процесста шактый гына фонетик үзгәреш бар, сүз азагында килгән иҗектә, $к^{а} \longrightarrow к^{и}$ гә күчкән һәм, В. А. Богородицкий әйткәнчә, бу үзгәреш бөтен иҗекнең артикуляциясе алмашынуны китереп чыгарган.

Хәзерге телдә нечкә *к* белән әйтелә торган *кире* сүзенең электә *кайра* дип язылуы булганын беләбез. Мәсәлән, М. Колый: „Үткән гомер *кайра* кайтмас“, — ди (кире кайтмас дигән сүз). Борынгы төрки телдәге *ака* ‖ *акагым* сүзенең *әкә* гә күчүе дә әнә шул процессның — $к^{а} \longrightarrow к^{и}$ гә әверелүенең бер күренеше булып тора.

Хәзерге гомумтатар теле диалект һәм сөйләшләрендә *к* ның берничә вариантта әйтелүе дә мәсьәләне ачыклый. Мәсәлән, урта диалектның Казан арты, Минзәлә, өлешчә, Тау ягы сөйләшләрендә *к* тел арты артикуляциясе белән әйтелә, шул ук диалектның Нократ сөйләшендә һәм көнбатыш диалектта гомумән *к* авазының тел уртасынарак күчкәнлеге сизелә. Касыйм татарлары сөйләшендә *к—г* авазлары тик читтән кергән сүзләрдә генә кулланылалар.

Бу фактларның барысы да татар телендәге *к—г* авазлары йомшара килгәнлек турында сөйлиләр.

В. В. Радлов, куман текстына анализ ясау уңаенда, әнә шул *к* авазының бер төркем сүзләрдә *г* авазына күчеп, шундый ук тезмәләрнең икенче берләрендә үзе сакланган булу күренешен терки. Аның мисаллары: *ак ⟶ агы*; *йазык ⟶ йазыкы*.

Димәк, *агы* дип, тартым алдында килгән *к* ны *г* авазына күчереп әйтү куманнарда инде XII—XIII йөзләрдә ук системага кергән яки керә башлаган була. Без күзәткән язма текстларда да шундый ук янәшә-

лек була. Мәсәлән, „Йосыф-Зөләйха“ да *угланчыкы* һәм *тапугы* кебек икетөрлелекләр тулып ята. Һәм бу халь язма әдәбият телендә хәтта XX йөз башларына чаклы дәвам итә. Шул рәвешчә, *к*⟶*г* күчешенең татар телендә бик күптәнге күренеш булганлыгы ачыклана.

*К* авазының тел арты артикуляциясеннән күчеше *г* авазына алмашыну белән генә чикләнми, кайбер авазлар тирәлегендә ул, турыдан-туры үзе яки *г* ның чиратлашуы формасында, тагын берничә төрле үзгәреш, алмашынуларга очрый. Алар, башлыча, түбәндәгеләрдән тора: а) сүз, иҗек азагындагы *к*—*г* авазлары төшеп кала, югала, б) *г* авазы иҗек ясамый торган нечкә авазы *у* (w) белән алмашына, в) *г* авазы билгеле комбинацияләрдә тел уртасы авазы й белән алмашына, г) кайбер очракларда *г* авазы *н*+*г*⟶*ң* гә күчә. Бу процессның шактый ачык чагылышы болгар-татар язма әдәбияты текстларында күренә:

а) сүз һәм иҗек азакларындагы *к*—*г* авазлары төшеп калу, югалу очракларын күрсәткән мисаллар:

| **Борынгы әдәбиятта язылышлары** | **Хәзерге көнне язылыш һәм әйтелешләре** |
|---|---|
| олуг | олы |
| ыруг | ыру ‖ ыруг[1] |
| оглы | улы |
| йыглау | йылау |
| йөзлүк | йөзле |
| баргучы | баручы һ. б. |

— „Әгәр ул дөш йиренә кәлүр улса,
Иосыф *олуг* падша улур улса,
Җөмләмез аңа хезмәт кылур улса,
Ул безләргә каты гардыр,—диерләр имде („Й. З.“, 4 бит).

— „Ун карындаш *йыглашуб* утурдылар“ („Й. З.“, 5 бит).

— „Пычак илә *үлдүрмәккә* хәмлә кылды. („Й. З.“, 10 бит).

— „Ул хатундан туган *углан* мән торырмын“ („Н. С.“).

---

[1] Ыру (род) төшенчәсен аныклау, ачыграк итү өчен, соңгы елларда ыру урынына ыруг язу яңадан кулланылышка кереп бара.

— Куюг казыб үзе төшкәй (М. Яр).

— Имәнкыл Нәдер *углы*, Чаманай Сарманай *угылыдыр*; Уразбакты Алдагыл *угылы*; Мәскәү Тимербулат *угылыдыр*“ („Тәварихы Болгария“, 18 бит. XVII йөз).

Бу моментка карата түбәндәге аңлатма, ачыкламаны кертергә тиешбез. *К—г* авазларын йотып, төшереп сөйләү Идел-Кама төркиләрендә болгар чорыннан ук башланган булуы андагы кабер ташбилге язмаларында *углы* һәм *ул* (ы) формалары янәшә кулланудан да күренеп тора. Ләкин язу традициясендә бу сүзнең *угыл* варианты бик озак саклана, хәтта К. Насыйри да күп урында *угылы, угылына* дип яза.

*К—г* авазлары төшеп калу белән бәйләнешле бер моментны теркәп узарга кирәк. Тюркологлар, борынгы язма әдәбиятны һәм тере телләрдәге фактларны өйрәнүдән чыгып, *к—г* авазлары югалу сәбәпле, төрки телләрдә сузыклар озаю булган, диләр. В. В. Радлов куман текстындагы *колаа* (кола), асылда, *колга* сүзеннән үзгәргән дип аңлата (42 бит). Аныңча, *колга*дагы *г* авазы төшү хисабына, соңгы *а* икеләтә сузылган һәм бу сүз *кола* (колаа) га әверелгән була. Татар телендә исә *к—г* авазлары төшеп калу сузыкларның икеләтә сузылуларын китереп чыгармаган. Мәсәлән, *огыл, олуг...* кебек сүзләрдән *г* төшкәч, *о—у* авазлары артык сузылыш алмаганнар, киресенчә, *олуг* дагы *у* иренсез-тар-кыска *ы* авазына күчкән. *Олуг⟶олу⟶олы* булган. Бу күренеш татар теленең үзенчәлеге саналырга тиеш.

б) *К—г* авазының ирен авазы *у* (*v*) га күчүе шулай ук катлаулы һәм озак дәвам иткән. Моның ачык мисалы итеп, тюркология фәнендә *таг⟶тау* сүзе йөртелә. Татар теле фонетик төзелеше формалашу процессында *к—г* авазларыннан *у* (*v*) га күчеш булганын, башлыча, *таг⟶тау*; *баг⟶бау*; *яг⟶яу; тагук⟶тавык; бозак⟶бозау; сагук⟶савык*; *саг⟶сау* кебек сүзләр язылышындагы үзгәрешләр раслыйлар.

В. В. Радлов күзәтүенчә, *аг* тезмәсенең *ау* (*av*) га күчүе куман телендә үк башланган була. Ул, мәсәлән, анда инде *баг⟶бау, яг⟶яу* формалары янәшә йөргәнлекне әйтә. Шул уңай белән В. В. Радлов, Идел буе шивәсендә *аг* дан *ау* га күчү инде барлык очракларда да тәмамланган дип күрсәтә, һәм ул *г* ның *у* (*v*)

авазына күчү процессы куман телендә көчле булмаганлыгын (мисаллары: *агул⟶аул*), моның исә, үз чиратында, куман теле белән Идел буе шивәләре, аерата көнбатыш диалект арасындагы тарихи бәйләнеш булуын, „куман теле әнә шушы сөйләшләр төркеменең борынгы стадиясе булуын раслый“, дигән фикергә килә (41 бит).

Шулай, Идел-Кама болгар-татарлары телендә тирән тел арты *к⟶г* авазлары ирен авазы *у* (*v*) белән алмашынган. Берничә мисал:

„Аякларым *агырды*“ („Й. З.“, 9 бит).

„Бу угланның *агарынча* алтун үиргел“ („Й. З.“, 43 бит).

„Йиде йыл күкдән ягмыр һич *ягмады*“ („Й. З.“, 67 бит).

„Барчасының *эл-азакы баглыдыр*“ („Кисекбаш“).

„*Таг* башында бар ирде күп манара“ (Мөхәммәдъяр).

„Ак Иделнең Чулман Иделе илән кушулдыкы йирдә бер *таг* уардыр, Юнча *таг*, диерләр“ („Тәварихы Болгария“, 15 бит). „Тарих бең йикерме түртдә тавышкан йылы Җәмәл *ягы* булды“.

(Елъязмалардан.)

*Тау, бау*... кебек сүзләрне *таг, баг* (баглау) формаларында язу әле XIX йөз азакларында да очрый.

Шул рәвешчә, *г* урынына *у* (*v*) әйтүгә күчү процессы да язма әдәбиятта шактый озак вакыт буена сузылып килә.

Бу момент буенча тагы шуны өстисе бар. Борында *к—г* белән әйтелгән иҗек һәм сүзләрдәге *у* (*v*) — бу, чын мәгънәсе белән ирен авазы. Моны, хәзерге орфографиядә *в* белән язылышына карап, ирен-теш авазы итеп санарга ярамый. Татар теленең урта диалектында *в* түгел, *у* (*v*) әйтелә. Мәсәлән, борынгы *агыл*⟶хәз. *ауыл*; борынгы *ягыз*⟶хәз. *яуыз*... Монда, кыска ачык *уау* ишетелә. Көнбатыш диалектта исә шул ук *у* (*v*) ны кайбер сүзләрдә ирен-теш авазы итеп, рус *в* сына якынайтып әйтү дә бар. Мәсәлән, борынгы *багыр* ‖ *бәгыр* сүзен, урта диалект вәкилләре *бауыр* дип әйтсә, көнбатыш диалектта бу сүз *бавыр* булып ишетелә.

Менә шушы фактны исәпкә алганда, *к* ⟶ *г* ⟶ *у* (*v*) һәм *в* авазларына күчеш булганлык ачыла. Асылда,

фәнни-тарихи аңлатма шулай булырга тиеш тә. Чөнки иҗек ясамый торган *уау* ике диалектта ике төрле акустик бизәк алган.

в) *к ⟶ г ⟶ й күчеше.* Тел арты тирәнлегендә ясала торган авазлардан мәгълүм тезмәдә алгы артикуляция авазларына күчешнең бер күренеше итеп, *к ⟶ г* авазларының *й* белән алмашынулары санала. В. В. Радлов *г* авазының *й* гә алмашыну процессы аның *у* (*v*) га күчүе белән бер үк вакытта булган дип аңлата. „Кодекс-куманикус" текстында моңа мисал итеп *сйр* (⟵ сыер ⟵ сыгыр) сүзе алына. *Сыгыр* сүзендәге *г⟶й* күчеше җирлегендә, *сыйыр* килеп чыккан. Ләкин, Радлов күзәткәнчә дә һәм хәзерге көнбатыш диалектның кайбер сөйләшләрендә дәвам иткәнчә дә, куманнарда „*сыгыр*"ның *г* авазы югалып, аның янәшәсендәге *ы* икеләтә сузылган, ягъни *сыгыр ⟶ сыр* ‖ *сйр* га күчкән була. Гомумтатар телендә исә *сыйыр* әйтелеше урнашып калган.

Борынгы телдә *г* белән әйтелеп һәм язылып йөргән сүзләрнең соңгы якта *й* белән әйтелешкә күчкән булуларын түбәндәге мисаллардан күрәбез.

— „Итәкенең алтенә *сыгындырды*, кардәшләре уфкәсендән саклар имде" („Й. З.", 11 бит).

Мондагы *сыгындырды ⟶ сыйындырды* дигән сүз.

— „Нил ермакы *крагына* якын дөшде" („Й. З.", 32 бит).

*Крагына ⟶ кырына ⟶ кырыена* дигән сүз.

— „Гыйлем *үгрәткән* галимдәр" („Н. С.", 32 бит).

— „Бер йәбне аркасындыйн кәлүб буйныга салды. Йәб буйныга төшмәде, беләкигә төшүб, андыйн кулун күтәрде ирсә, култыгыга төште, *баглаю* белмәделәр" („Н. С.", 34 бит). *Баглаю* белмәделәр — бәйли алмадылар була.

„Кинә тохымын игәрләр, билен *баглаб*, ясаныб" (М. Колый).

„Дөнья эчрә *андаг* таглар булса... (М. Колый).

„Игенченең эшен *мондаг,* блүр булсаң" (М. Колый).

„Качан таң атды ирсә, төш күргән халаиклар *йыгылуб* төшләрен әйделәр" („Н. С.", 36 бит). Мондагы „*йыгылуб*" — *җыйылып* ‖ йыйылып дигән сүз.

„Файда *тикермәк*" („Н. С.", 46 бит). Тикермәк ⟶ тиерү сүзенең борынгы формасы, *тикерү* нең *к* авазы *й* гә күчеп, *тийәрү* калган. „Мәңа *тикмәс* кем,

кәстахлык кыйлмага“ (Мөхәммәдъяр). Миңа шагыйрьлек итү, шигырь язу *тимәс* — насыйп булмас дигән сүз.

„*Сәнтәк* этләр еракдан күп өрәләр,
Ишеккә килсә, хак дип сорарлар“ (Мөхәммәдъяр).

Мондагы *сәнтәк* —→ *синдәй* гә күчкән. Хәзерге телдәге *дай — дәй, тай — тәй* кушымчасы әнә шул *так — тәк* | *даг — дәг* сүзеннән үзгәргән; *мондаг* —→ *мондый; андаг* —→ *андый; ушбундаг* —→ *шундый* һ. б. шулай ук *ак — аг* тезмәсенең *ай — ый* га күчү нигезендә формалашканнар.

„Мәне *антик* халь эчендә күрделәр“ („Җәмҗемә“); *антик* —→ *андый, шундый* хальдә дигән сүз.

„Бу халь эчрә бер йыл дагы тәмам улды, Зөләйха ул сурәте *кинә* күрде“ („Й. З.“). *Кинә* —→ *йәнә* дигән сүз (*к* —→ *й* күчкән).

Менә шушы үрнәкләр татар теле формалашу процессында *к — г* ның *й* белән алмашынуы һәм моның язма әдәбият телендә озак заманга сузылуы турында сөйлиләр.

*К — г* авазларының *у* (*v*) һәм *й* авазларына күчүләре уңаенда, бер үк тамырның ике төрле әйтелеш алуы да барлыкка килгән; борынгы *баг* сүзенең хәзерге телдә *бау* һәм *бәй* дип әйтелеш алуы шуны күрсәтә.

г) Ниһаять, татар телендәге кушык тартыклардан (аффрикаталардан) берсе булган *ң* авазы барлыкка килү тарихы да *к — г* авазы кичергән үзгәреш моментларыннан берсе булып тора.

## 4. Ң авазының килеп чыгышы һәм тарихи үзгәреше

*Ң* кушыгы, гомумән, төрки телләрнең байтагына хас һәм борынгы санала. „Башка төрөк телдәрендәгесә, башкорт телендә лә *ң* өнө иҫке һүҙҙәрҙә генә осрай, унда ла һүҙ башында килмәй, һүҙ уртаһында йәки аҙагында гына килә“,— ди Н. К. Дмитриев[1]. Ләкин бу аңлатмадагы „иске сүзләр“ дигән тәгъбир шактый абстракт, конкретлаштырылуга мохтаҗ.

*Ң* — бу, конкрет алганда, татар теле фонетик системасында характерлы кушык тартык (аффриката) санала. Моның компонентлары — *н* + *г* авазлары.

---

[1] Н. К. Дмитриев, „Башкорт теленең грамматикаһы“, 1950 ел, 26 бит.

П. М. Мелиоранский үзенең „Араб-филолог о турецком языке“ дигән кыйммәтле хезмәтендә *ң* авазына карата мондый мәгълүмат бирә: „Борын авазы *ң*, безнең авторча („Тәрҗеман-эл-терки вә гарәби“ дигән китапны язган гарәп телчесе буенча; бу китап XIII йөзнең беренче яртыларында язылган), *нон* (н) белән *гаф* яки *гәф* (г) авазларының „идъгамы“ (кушылуы) нәтиҗәсеннән гыйбарәт... Аның бу фикере шикләнергә урын калдырмый (XXVII бит)[1].

Аңлашыла ки, П. М. Мелиоранский гарәп-филологның фикерен яклый. Н. К. Дмитриевның *к — г* авазлары алдыннан килгән *н* авазы *ң* га күчә дип аңлатуы да, түбендә, шул ук фикерне раслый. Мәсәлән, башкортча „Син кем?“ тезмәсенең „һиңгем?“ формасына, татарның „Кабан күле“ ⟶ „Кабаңкүле“ дип әйтелүгә күчүе әнә шундый күренештән тора, ягъни монда *н + к* авазлары керешеп, *ң* барлыкка килә. Ләкин мондый очраклардагы *ң* ны тулы кушык санап булмый, чөнки бу әле авазлар арасындагы комбинатор ассимиляция чагылышы гына булып тора.

Чын мәгънәсендә кушыклашкан (аффрикаталашкан) *ң* авазы итеп, теләсә нинди комбинациядә дә үз әйтелешен саклый торган *ң* ны гына саныйбыз. Мәсәлән, *таң, аң* сүзләрендәге *ң* беркайчан да үзенең мөстәкыйль әйтелешен югалтмый: *таң, таңнан, таңга, таңнар* һ. б. Бу тезмәләрдәге *ң* үз әйтелешен югалту түгел, бәлки, үзе икенче бер авазларга йогынты ясый.

Кыскасы, *ң* авазының тарихы тюркология фәнендә инде ачыкланган мәсьәлә булып тора: *н + г (к) = ң* ны биргән.

Борын авазы *н* белән бугаз авазы *к — г* кушылып, борын-бугаз авазы *ң* барлыкка килү — бик табигый күренеш, чөнки *н* — борын куышлыгында, *к — г* исә тел арты куышлыгында ясала, ягъни боларның һава дулкыннары бер-беренә бик нык керешәләр; шул сәбәпле *нг* ⟶ *ң* булып кушылып китә, һәм кушык аваз барлыкка килә.

Кайберәүләр *ң* кушыгындагы *н* авазы инде бөтенләй югалган дип тә әйтәләр. Ләкин бу дөрес түгел һәм алай була да алмый. Әгәр дә мондый хәл булса, без *ң* ны аерым аваз итеп санамас та идек. Монда

---

[1] П. М. Мелиоранский, „Араб-филолог о турецком языке“, 1900 ел.

сүз тик *ң* составындагы *н* һәм *г* элементларының чамасы турында гына булырга мөмкин. Әйе, бу яктан карасак, *ң* әйтелешендә *г* элементының бераз гына көчлерәк ишетелүен сизүебез мөмкин. Ләкин бу момент *н* ның кушыклыгын инкарь итми.

Бу авазның татар теле тарихындагы урынын билгеләү, ачыклау өчен, түбәндәге берничә моментка тукталу кирәк. Беренчедән, татар язма әдәбияты тарихында, иң борынгы чорлардан башлап ук, *ң* авазы ике хәреф (نك - نگ ; = нк — нг) белән язылып килә, һәм бу билгеләрне куллану хәтта Октябрь социалистик революциягә чаклы дәвам итә. Латин алфавитына күчкәч, бу авазның билгесе, *n* хәрефенә „койрык“ тагып, n формасында ясала, хәзерге алфавиттагы билге дә шул ук принципта корылган, *ң* — бу, асылда, *н* га билге арттырып ясалган. Шуның белән бергә, бу билгеләрнең прототибы үткән йөзнең 60 — 70 елларында керәшен татарларына кертелгән рус алфавитындагы нг дан гыйбарәт. Бу фактлар *ң* авазының элек-электән үк *н* һәм *к — г* авазларыннан торган итеп санала килгәнлеге турында ачык дәлил булып торалар.

Икенчедән, татар язма әдәбияты телендә, әйткәнебезчә, бу аваз бик борыннан ук кулланылышка кергән була. Хәтта, әйтергә мөмкин, борынгы язма текстлардагы *ң* кулланылышы белән хәзерге язма әдәби тел нормалары арасында аерма бик аз. Төп аерма тик шунда, хәзерге телдә киләчәк заман хикәя һәм сыйфат фигыльнең икенче зат өчен берлеген тәгъбир итә торган *сың — сең* кушымчасын борынгы язмаларда *сун* ‖ *сын, сүн* ‖ *сен* дип язу шактый озак дәвам итә.

Берничә мисал:

Мәмләкәт иясе булдачысын (булачак*сың*, „Й. З.“, 4 бит).

„Якуб әйдер: „Я кызым, нә уарырсын“ („Й. З.“).

„Әйделәр: „И карт, әйткел, кем торырсын?“ („Н. С.“, 32 бит).

„Гали кошчы әйтде: „Я углан, сән нә учун егларсын?“ — диде“ („Тәварихы Болгария“, 31 бит).

„Йөрерсен ләбаса катып“, „туңып йиргә йокылур*сын*“;

„Шу дәкле каты туңар*сын*“ (Г. Кандалый).

„Әгәр ул серне кешегә сөйләсәң,

Сән аңа әсир булырсын“ (К. Насыйри, „Фәвакиһ-эл-җөласә“, 307 бит).

Бу момент, өстән караганда, үзе фонетик күренеш кенә булып сизелсә дә, төбендә, телнең синтаксик һәм морфологик төзелеше белән бик нык бәйләнештә тора. Шунлыктан моны дөрес чишә алу өчен, гомумән, зат алмашлыкларыннан ясалган кушымчаларга аңлатма бирү кирәк була.

## 5. Зат алмашлыкларыннан үзгәреп килеп чыккан кушымчалар

Без, билгеле, монда андый зур мәсьәләне тулы анализлау эшенә керешә алмыйбыз, чөнки моның өчен киң күләмдә этимологик күзәтү таләп ителә.

Гомумән, төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә дә зат алмашлыклары берничә төр кушымча биргәннәр. Һәм ул кушымчалар, законлы рәвештә, затларның, шул ук затлардан берсенә кергән гомумән предметларның (әйбер, предметлар һәм кеше үзе дә өченче зат позициясенә куела) эшкә һәм икенче әйберләргә мөнәсәбәтен билгелиләр. Мәсәлән, „минем китабым“ дигәндәге *ым* — *эм* аффикслары, төбендә, шул ук *мин* нең үзеннән ясалган килеш, беренче затның китапка мөнәсәбәтен белдерәләр, китап, димәк, „мин“ неке ⟶ минеке була.

Җыеп кына әйткәндә, татар телендәге зат алмашлыклары — *мин, син, ул* — болар зат, тартым һәм иялек аффикслары, ягъни хәбәрлекле (предикатив) һәм аергычлы (атрибутик) бәйләнешне тәгъбир итә торган грамматик чаралар да биргәннәр.

**Хәбәрлекле мөнәсәбәт:**

мин яза*м*
без яза*быз*
син яза*сың*
сез яза*сыз*
ул яз*а*
алар яза*лар*.

Бу җөмләләрнең барысында да хәбәр *яз* сүзеннән тора, һәм үзе, ияләрнең зат һәм саннарына ярашып, һәр очракта аерым бер аффикс ала:

язам—зат аффиксы — *м* (⟵ мин)
язабыз „ *быз* (⟵ без)
язасың „ *сың* (⟵ син)
язасыз—зат аффиксы *сыз* (⟵ сез)
яза „ *а* (⟵ ул)
язалар „ *лар* (⟵ алар),

**Аергычлы мөнәсәбәт:**

минем каләме*м*
безнең каләме*без*
синең каләме*ң*
сезнең каләме*гез*
аның каләм*е*
аларның каләм*нәре.*

Бу тезмәләрдә аергычлык бәйләнеше ике яклы күрсәткеч — иялек килеше һәм тартым кушымчалары белән белдерелә.

Монда иң характерлысы — тартым кушымчаларының да шул ук зат алмашлыкларыннан ясалган булуларында. Бу аффикслар, этимологик чыганаклары ягыннан, түбәндәгечә ачылалар:

| | | | |
|---|---|---|---|
| каләмем — тартым аффиксы — | | *м* | (⟵ мин) |
| каләмебез | „ | *без* | (⟵ без) |
| каләмең | „ | *ң* | (⟵ син) |
| каләмегез | „ | *гез* | (⟵ *сез*) |
| каләме | „ | *е* | (⟵ ул) |
| каләмнәре | „ | *нәр (е)* | (⟵ алар). |

Шул ук тезмәләрдәге иялек аффиксларына күз салсак, анда, система буларак, *ның — нең* килеп, тик беренче затның берлегендә генә *эм* (мин) сакланган.

Бу кушымчаларның аваз төзелешендә исә, *н* ның *ң* га күчүе тик икенче зат берлек санында гына реальләшкән. Мәсәлән, зат кушымчасы *син — сын*, *„язасың“* да *„сың“* булып, *каләм синеке* төшенчәсен бирә торган *„каләмең“* дә *„син“*нән тик *„ң“* гына калган ([си] н ⟶ ң).

Нәкъ шундый ук күчеш фигыльләрнең калган төркемнәрендә дә күзәтелә.

**Шарт фигыльләр:**

язсам *м* (⟵ мин)
язсак *к* (⟵ без)
язсаң *ң* (⟵ син)

язсагыз *гыз* (⟵ сез)
язса *а* (⟵ ул)
язсалар *лар* (⟵ алар).

Хикәя, сыйфат фигыльләрдә дә шундый ук күренеш; ягъни *н* ның *ң* га күчүе тик икенче затның берлек санына гына туры килә: язд*ың*, язас*ың*, язар*сың*; язган*сың*, язучы*сың*, язачак*сың*, димәк, барысында да *син* ⟶ *ың*, *сың* га күчә. Ләкин, шул ук *син* нән ясалган өченче зат өчен боерык кушымчасы *сын*, мәсәлән, бар*сын*, укы*сын*, яз*сын* һ. б. „*сың*" га күчмәгән.

Менә бу экскурс *ң* авазының, бер яктан, *н* га караганда соңгы күренеш булуын, икенче яктан, кайбер аффикслардагы *н* авазыннан *ң* га күчүнең мәгънә ачыклауга да бәйләнеше булуын күрсәтәләр.

Тартым һәм иялек аффиксларын (*ың — эң*, *ның—нең* кушымчаларын) *ын — эн*, *нын — нен* формасында язу татар әдәбиятының бер чорында да очрамый.

П. М. Мелиоранскийның „Тәрҗемане төрки вә гарәби"гә ясаган комментариясендә бу тармак буенча әһәмиятле мәгълүмат бар. Анда, мисаллардан күренгәнчә, иялек һәм тартым кушымчасын „нен", „ен" формаларында сөйләгән булалар. Мәсәлән, „ат бәкнен" (ат бәкнең, бәкнең аты[1]).

Автор бу форманы кыпчак төркеме теленнән алган булырга тиеш, чөнки Ибне Хайан Гарнатый да изафәгә (тартымлылык, аергычлыкка) карата сөйләгән бүлекләрендә[2] *ның — нең* һәм *ың — эң* формаларын бөтенләй телгә дә алмый, ул, система рәвешендә, *нын — нен* *ын — эн* формаларын куллана. Менә аның үз мисаллары: „Бу — Сәбхарнен дәр" (195 бит) һәм ул шунда ук „вә фи логате-эл-төркмәни: бу — Сәбхарендер" (195 бит) дип искәрмә дә ясый. „Сән кемнен сән" (195 бит).

П. М. Мелиоранский „Китаб-эл-идракъ" теле дә, „Кодекс-куманикус" теле дә һәм „Тәрҗемане төрки вә гарәби" теле дә, башлыча, кыпчак диалектына якын торалар, дип әйтә (IX бит).

Димәк, „Тәрҗемане төрки вә гарәби" һәм „Китаб-эл-идракъ" ләрдә теркәлгән „нын", „ын" формаларын, бәлки, борынгы кыпчак һәм угыз диалектларына хас күренеш дип билгеләргә мөмкиндер. Ләкин бу урында

---

[1] П. М. Мелиоранский, „Араб-филолог...", 15 бит.
[2] Кара: „Китаб-эл-идракъ", 156, 157, 194, 195 битләр.

әһәмиятле бер фактның астына сызып, тарихи ачыклык биреп узарга тиешбез. Борынгы куман, кыпчак диалектларына караган „Кодекс-куманикус“ телендәге тартым һәм иялек килеш кушымчалары инде нәкъ хәзерге татар телендәгечә формалашкан булалар. Без анда *нын* һәм *ын* формаларын бөтенләй очратмыйбыз. Мисаллар китерик. Беренче зат берлек өчен иялек килеше һәм тартым кушымчасы формасы:

„Кешеләр, *мәнем сөзем* äшетыңлäр“ („Кодекс...“, 79 бит); „*мәнем тыным*“ (83 бит); „*мәнем буйрукым*“ (85 бит). Күзәтүебезчә, тик бер урында гына „*мäнең яман эшләрем*“ формасы бар (81 бит).

Соңгы мисалдагы „*минең*“ (минем) формасы турында кайбер фикерләр әйтеп китү урынлы булыр. Без, югарыда бер схема теркәп, зат алмашлыкларының иялек килеше алулары тик беренче зат берлек санында гына үзенчәлекле (эм) булып, калганнарында *ның—нең* килүне күргән идек. „Кодекс-куманикус“ текстында әнә шул „*минем*“ урынына „*минең*“ формасы да сакланган. Моны язу хатасы китереп чыгарган очраклы күренеш кенә итеп карый алмыйбыз, киресенчә, бу форманың төбендә шактый әһәмиятле тарихи факт ятканын ачарга тиешле булабыз. Система булу бөтенлеге күзлегеннән караганда, *минең* формасы, гомумән, сүзләрнең килеш белән төрләнүләрендәге бердәмлекне тәшкил итә. Мәсәлән, *минең, синең, китапның, кешенең* һ. б. *Минем* формасы исә, тик ялгызы гына, аерым бер алым булып тора, һәм мондагы *эм* үзе килеш кушымчасы да түгел, бәлки зат һәм тартым кушымчасы; үзем бардым дигән җөмләдә *эм* турыдан-туры „мин“не аңлата, *үземнең* китабым дигәндә исә *үзе*, ягъни шул ук иялек килеше ала. Моның хикмәтен тагын да ача төшик дисәк, „*атам-анамнан* хат алдым“ дигән җөмләне, „атам-анамның хатлары килеп тора“ дигән әйләнмәгә күчерик. Беренче җөмләдә *атам-анам* сүзләренең *м* кушымчасы тартым (мин) иде, икенче җөмләдә исә шул ук *м* (мин) үзенә тагын иялек килеше дә алды. Мәсьәлә ачык: болар икесе дә зат алмашлыгыннан ясалган зат тартымнары. Монысы, димәк, бер яктан, „*минем*“-дәге *эм* нең килеш булмавын күрсәтә. Икенче яктан, „Кодекс-куманикус“тагы *минең* формасы, система рәвешендә булмаса да, татарның борынгы әдәбияты

телендә һәм бүгенге көнне аның кайбер сөйләшләрендә яшәешен дәвам иттерә. Мәсьәлә болай тора: гомумтатар теле һәм аның язма әдәбиятында, система буларак, *бәнем — мәнем* формасы күптәннән үк килә. Шул ук вакытта, сирәк күренеш рәвешендә генә булса да, *минең* варианты да була. Әдәбият телендә бу вариант XVI—XVII йөзләргә чаклы килә, сөйләшләрдә исә, әйткәнебезчә, әле бүген дә бар. Конкрет фактларга мөрәҗәгать итик. „Йосыф-Зөләйха"да төп урынны *бәнем* формасы ала. Мисаллар:

„Зөләйха әйдер: „Сезләр гаян күрдегезмү, *бәнем биңзем* сулдыгын белдегезмү? (55 бит.) Шулай ук без анда „Бәян белгел, сән *бәнең*, бән сәнең*мен*, бәндән үзгә һичкемсәнә һич булуман; *бәнем гыйшкым* хәтерендән сән салуман" (38 бит) формасын да очратабыз.

Ниһаять, шагыйрь Мөхәммәдъяр әсәрләрендә, *минем* эшем формасы төп урынны алган килеш, *минең* варианты да очрый; мәсәлән, „Ризаң булмаса бер шәйдин *синең*, ул шәйдин сакла күңелемне *минең*", — дип яза бер урында Мөхәммәдъяр.

*Минем* дәге тартымны *эң* формасында йөртү хәзерге көнне Горький өлкәсе мишәрләре сөйләшендә сакланган. Алар, мәсәлән, „Бу бит — *минең* эш, синеке төгел", „*минең* китабым" дип сөйлиләр.

Бу уңайда тагын шуны да өстәргә кирәк. *Безнең*, ягъни күплек санындагы беренче зат алмашлыгының килеш белән төрләнеше татар теле тарихында борыннан ук *безнең* формасына беркетелгән була.

Безнең дәге *нең* урынына тартым — „*эм*" аффиксы йөртү „Кодекс-куманикус һәм „Йосыф-Зөләйха" текстларына хас алым булып тора. Берничә мисал:

„*Безем* цикäу" („Кодекс...", 81 бит); „*безем* цикауга" (82 бит); „*безем* туганмас айгелек" (84 бит).

„*Безем* илә Йосыфың биләуарсун" („Й. З.", 6 бит). Шул ук чорларда һәм аннан соң язылган китапларда исә *безнең* формасы система булып килә.

Кыскасы, *минем — бәнем* һәм *безнең* формалары „Кодекс..." һәм „Йосыф-Зөләйха"лар чорыннан ук китап теленә, әдәби кулланылышка кергән булалар. Болар, әлбәттә, гомумхалык телендә формалашкан вариантлар булып торалар.

Тартым кушымчасы *быз — без* урынына *мыз — мез* вариантын йөртүгә килгәндә, мәсьәлә бөтенләй икенче

төс ала. Бу форма, электән ук алып, Каюм Насыйриларга чаклы шактый актив кулланыла. Мисаллар: „Безнең *балаларымыз*“, „безнең *егетлегемез*“ („Н. С.“). Шул ук китапта „безнең *мәканларыбыз*“ формасы да аз-маз очрый.

М. Колыйда да „безнең *телемез*“ кебек мисаллар бар. Ниһаять, К. Насыйрида „Безнең *телемездә* кадимдән бу фәннәр языла килмәгәнлек сәбәпле, урынына муафыйкъ вә килешә торган сүзләрне табуы читен“, — дип язылган җөмләне укыйбыз. („Ысуле җәграфия...“, 3 бит).

Күзәтелгәннәрдән түбәндәге нәтиҗәне чыгарырга мөмкин.

Хәзерге көнне *быз — без* формасында йөри торган кушымчаның элек *мыз — мез* дип әйтелүе һәм язылуы — бу тик фонетик күренеш кенә. Гомумән татар телендә *м — б* авазлары арасында күчеш булганлыкны югарыда әйткән идек: *мыз* дан *быз* га күчү, беренче чиратта, җирле диалектларның гомумтатар теле эчендә эрүләре процессында борынгы болгар-төрки әйтелешеннән төрки-кыпчак формасы өстенлек алу дип аңлату дөрес булыр.

„*безнең*“ урынына „безем“ формасын куллануда исә шактый әһәмиятле генә синтаксик факт бар. Иң элек, бу алым *нең* (иялек килеше) белән *эм* (тартым аффиксы) функциядәш булуны күрсәтә; ягъни боларның икесе дә тартым төшенчәсен, ике предмет яки предмет белән күренеш арасындагы үзара мөнәсәбәтне күрсәткеч чаралардан торганлыкны дәлилли. Шуның белән бергә, *эм* урынына китерелгән *нең* аффиксының борынгы телдә „*ныкы — неке*“ кушымчасы функциясенә йөргән булуы да ачыла. Без моны „сән *бәнем*, мән *сәнең*... („Й. З.“) дигән әйләнмәдә күрәбез: „сән бәнең“ — син минеке, „бән сәнең“ — мин синеке дигән сүз.

Нәрсә соң ул *ныкы* (неке)? Аның фонетик төзелеше һәм синтаксик-морфологик функциясендә нindirәк үзенчәлек бар?

*Ныкы* (неке)—бу, иялек килеш кушымчасы *ның* һәм тартым кушымчасы *кы* (—гы) ларның кушылмасыннан торган бер аффикс: *ның*+*кы*=*ны* (н) кы ⟶ ныкы (неке). Моның синтаксик функциясе ике момент белән характерлы:

а) гадәттә, бу аффикс тартымлы сүз тезмәсендә

төшеп калган аерылмышны күрсәтә. Мәсәлән, *синең эшең* тәмамланды, *минеке* әле бетмәгән. Бу фразада *минеке* формасы *минем эшем* дигән мәгънәне бирә. Икенче төрле әйткәндә, мондагы *неке* аффиксы — *эшем* сүзенең урынбасары, алмашлыгы була һәм, шул нигездә, *эш* || *эшем* сүзе төшеп кала.

Синтаксик яктан караганда, бу фразадагы *неке* төшеп калган иянең күрсәткече булып тора. Морфологик яктан исә, *неке* — алмашлык (ул, ягъни минем эшем) функциясен үти.

б) *Ныкы* (неке) нең икенче функциясе — җөмләдә хәбәрлек категориясен тәгъбир итү. Мәсәлән, бу каләм *минеке*, монысы — *синеке*. Ягъни бу — минем каләмем, бу — синең каләмең, яки бу каләм — минем каләмем, бу каләм — синең каләмең, дип әйтелә торган җөмләләрнең характерлы гына стилистик, синонимик варианты була.

Шул рәвешле, *ныкы — неке*, гади кушымча булудан ашып, җөмләдә иялек һәм хәбәрлек функцияләрен үти алу сәләтенә күтәрелә һәм, шуңа күрә, Н. К. Дмитриевның *ныкы, неке* не „тартым алмашлыгы“ (притяжательное *местоимение*) дип аңлатуы да раслана[1].

„Йосыф-Зөләйха“дан китерелгән „син *минең*, мин *синең*“ фразасына тагын бер кат күз салсак, боларның хәбәрләре *минең* һәм *синең*, хәзерге грамматика калыбынча, „син *минеке*, мин *синеке*“ дигән сүз була. Бу исә, үз чиратында, *ныкы — неке* формасы әдәби кулланышка *ның* нан шактый соңгарып кергән булуын һәм аның функциясен элек иялек килеше кушымчасы *ның — нең* үтәгән икәнен ачып бирә.

*Ныкы — неке* аффиксы алмашлык сыйфатына ия булганлыктан, абстракт мәгънәләр тәгъбирләү өчен аның зур гына иплелеге бар. Шуңа күрә дә фразеологик, идиоматик әйләнмәләр формалаштыруда *ныкы — неке* ләрнең кулланылышлары чагыштырмача киң. Мәсәлән, „*Алтыныкы җитәр, алтмышныкы бетәр*“; „*Ырыкныкы шырыкка*“; „*Биргәнneke җитәр, алганныкы бетәр*“. (Халык мәкальләре, К. Насыйри буенча.)

К. Насыйри язып алган мәкальләр арасында „Этнең

---

[1] Проф. Н. К. Дмитриев, „Грамматика кумыкского языка“, 1940 ел, 80 бит.

әткә, кошның кошка“ формасында борынгы калыпка салынган, ягъни *ныкы* урынына *ның* ны кулланып төзелгәннәре дә һәм „Ата*ның*-ана*ның* балада, бала*ныкы* балада“ формасына салынган катнаш стильдәге фразалар да бар. Бу мисаллар, беренчедән, *ның* белән *ныкы* арасындагы функциональ якынлыкны, икенчедән, *ныкы* формасының күбрәк халык фразеологиясендә, халык иҗаты телендә урын алган булуын тагын бер кат дәлилләр.

Тел тарихын өйрәнү һәм андагы фактларны фәнни дөрес ачу өчен, җирле диалект һәм сөйләшләрдә сакланган сөйләм чаралары иң таянычлы чыганаклар булып торалар. Шунлыктан борынгы язма әдәбият телендә күренгән барлык үзенчәлек, төрлелекләрне хәзерге телдәге фактлар белән чагыштырып, тикшереп карарга кирәк.

*Ныкы* белән *ның* ны бер үк функциядә йөртү ягыннан татар теленең җирле диалектларындагы аерым сөйләшләр арасында бик әһәмиятле үзенчәлекләр бар. Молотов, Свердлов һәм Чиләбе өлкәләрендә яшәүче татарлар сөйләшендә *ның* урынына *ныкы* (неке) һәм, киресенчә, *ныкы* урынына иялек килеше кушымчасы куллану бар. Мәсәлән, „Синеңдә *минеке* эшем юк“ (Шадрин), „Бу дәфтәр *кемнең?*“ (Молотов). Бу фразаларның беренчесендә *минем* урынына *минеке*, икенчесендә *кемнеке* урынына *кемнең* килгән. Аннары боларда гомумән иялек килешен бер дә урынсызга кушып йөртү дә бар — „*синеңдәге*“ (синдәге), „*синеңдә*“ (синдә), „*минеңдә*“ (миндә) „*синеңдәге* якты нур“ (Шадрин). Соңгы фразадагы „*синеңдәге*“не берничә төрле аңларга була: а) *синең нурың*, б) *синдәге нур*. „*Безнеке* фатир“, „*безнеке* авыл“ дип сөйләү көнбатыш диалектның Рузаевка, Тамбов урынчылыкларында бар. Нократ-Кистем сөйләшендә *ныкы* — *неке* бөтенләй юк. Алар, „Бу урман *безнең*, болын *безнең*“; „печәй минем түгел, *Мәдинәнең*“; „Мин үзем *Нократның*, ирем *Кистемнең*“ дип сөйлиләр.

Күренә ки, татар теленең җирле сөйләшләрендә *ныкы* белән *ның* әле, шактый характерлы рәвештә, бер-берсен алмаштыралар.

Бу фактлар, барысы бергә, иялек килеш кушымчалары һәм тартым алмашлыклары арасындагы тарихи тәңгәллекне ачарга бик зур булышлык итәләр.

*Ң* кушыгының хәзерге гомумтатар телендә үзләштерелеш дәрәҗәсе турында да бер-ике сүз әйтергә тиешбез, чөнки бу тармакта шактый характерлы төрлелекләр бар, һәм алар кирәк әдәби телнең орфографик (язылыш), кирәк аның орфоэпик (әйтелеш) нормаларын төгәл үзләштерүдә булсын, мәктәпләребез практикасына кыенлык кертәләр.

Эш моннан гыйбарәт: гомумтатар теле фонетик системасында *ң* авазы инде тулы канлы фонема санала. Шуның белән бергә, кайбер сөйләш, урынчылыкларда бу авазның үзләштерелеше төрле төс ала. Казан арты сөйләшенең Дөбъяз-Этнә урынчылыгында *ң* авазы өч төрле үзгәрешкә керә: а) йотыла, ягъни мәгълүм төр сүзләрдән аны төшереп калдыралар. Мәсәлән, *миа, сиа* (әдәб. миңа, сиңа); б) аны *ң + г* яки *н + г*-кушмасы итеп йөртәләр: *җиңгел* (әдәб. җиңел), *күңгел* (әдәб. күңел), *миңга* ‖ *мингарга, аңгар — аңгарга* (әдәб. миңа, аңа ‖ аңар), в) *ң* урынына *н* әйтелә; мәсәлән, *мен* сум (мең), *безнен* (безнең), *сезнен* (сезнең), *анын, синен* (аның, синең). Соңгысы көнбатыш диалектта картлар телендә дә очрый. Молотов, Свердлов өлкәсе татарларының минеке сүзен *миңке* дип *к* алдыннан килгән *н* авазын *ң* га күчерүе дә шул ук планда каралырга тиеш. Мәсәлән, „*миңке* эшем бик шәп" дигән фразадагы „*миңке*" әнә шул хәлне күрсәтә.

Гомумән алып әйткәндә, *ң* авазы, *н + г* кушылмасыннан торган фонема буларак, татарның борынгы теленнән үк килүенә карамастан, әле бүген дә тулысынча урнашып житмәгән.

## 6. Авазлар төшеп калу күренеше

Кеше сөйләменең „табигый материясе", материаль тел тышчасы булган бүленмәле авазлар, ясалышлары һәм әйтелешләре ягыннан төрле үзгәреш, алмашынуларга очраганнары кебек, теге яки бу сүзләрдән, грамматик категорияләрдән төшеп тә калганнар. Шуның аркасында күп кенә сүзләрнең һәм грамматик чараларның борынгы формалары белән хәзерге формалары арасында сиземле аерма да барлыкка килгән. Мәсәлән, борынгы татар телендә *оглак* ‖ *углак* дип әйтелгән сүздән *олау* ‖ *ылау* (йөк), *беләк+йөзек* тән *беләзек; эчке итек* тән *читек, бозагу* ‖ *бузагу* сүзен-

нән *бозау; углан ⟶ ылан; сарыйг ⟶ сары; угыл ⟶ ул* (минем улым), *тугры ⟶ туры* һ. б. шундый күп кенә сүзләрнең кайсы да булса берәр авазы яки иҗеге кыскарган һәм әйтелешләре дә үзгәргән.

Сүзләрнең авазлары төшеп калу, йотылу булганлык лингвистикада (тел фәнендә) күптән ачылган һәм танылган мәсьәлә санала, алай гына да түгел, бу күренешкә карата кайберәүләр үзләренчә, уртак „кагыйдә", уртак „закон" да төзегәннәр. Мәсәлән, рус теле тарихы өстендә кайбер күзәтүләр ясаган Казан университеты проф. Е. Ф. Будде „Сүзләр азагы законы" дигән бер „закон" да уйлап чыгарган. Аның бу „законы" буенча, гомумән, сүзләрнең азаклары кыскарган булып кала, һәм ул үзенең бу фикерен русча *волк* сүзенең борынгы Һинд-Европа һәм борынгы гомумславян телендәге *волкус — вылкус* сүзеннән кыскаруы белән дәлилләргә тырышкан[1].

Гомумән, буржуаз лингвистика вәкилләре, авазлар төшеп калу күренешенә бәйләп, „сүз азагы" дигән мәсьәлә тирәсендә бик күп мавыкканнар һәм, „сүзләрнең азакгы авазлары, бүтән сәбәпләрдән бәйсез рәвештә, тик азаккы булганлыкларыннан гына үзгәрәләр"; „сүзләрнең азаклары тотанаклы түгел"; „аерата еш кулланыла торган сүзләрнең соңгы авазлары төшүчән булалар" һ. б. шундый „аңлатма-тезислар" чыгарганнар.

Үзеннән-үзе аңлашылганча, бу төр „законнарның" барысы да телгә механистик караш, аны эчтәлегеннән аеру, аның иҗтимагый күренеш булуын инкарь итү һәм аңа хас эчке законнарны ачарга теләмәүгә корылганнар.

Теге яки бу сүзләрдән һәм кушымчалардан кайбер авазларның төшеп калуларын ниндидер „кыршылу", „тузу" теориясе белән аңлату совет тел белеменә берничек тә ябышмый, әлбәттә. Без бу күренешне, И. В. Сталин өйрәтмәләре нигезендә, телнең эчке законы, аның лексик, грамматик төзелешендәге камилләшү, шомару процессы белән органик бәйләнештә алып карыйбыз. Авазлар төшеп калу, барыннан да элек, грамматик категорияләрнең формалашулары

---

[1] Е. Ф. Будде, Лекции по истории русского языка, Казан, 1913 ел, 158—164 бит.

белән бик нык бәйләнгән. Татар телендәге кушымчалар, бәйлек, теркәгечләр формалашу тарихы моның шулай икәнлеген бик ачык күрсәтә.

Телдә озак заманнар кулланылып та, теге яки бу авазлары төшеп, үзләренең фонетик составларын үзгәрткән сүзләргә дә берьяклы гына карарга ярамый, чөнки аларның билгеле бер өлеше шул ук вакытта, ягъни авазлары төшеп калу уңаенда, яңа, өстәмә мәгънәләр алганнар. Мәсәлән, *бер* (один) сүзе, язма документлардан күренгәнчә, үзенең борынгы төсен, аваз төзелешен бертөрле дә үзгәртмәгән. Ләкин шул ук сүз, *лән* кушымчасы алып, ярдәмлек функциясенә күчү уңаенда, *берлән* ⟶ *белән* гә калган, һәм монда инде аның мәгънәсе дә бик нык алмашынган, абстракциягә күчкән: *белән* — нәрсәләрнеңдер һәм кемнәрнеңдер бергә булуларын күрсәтә. Хәзерге татар телендә *белән* нең, бәйлек, теркәгеч буларак, унга якын функция үзенчәлеге бар.

Шулай, авазлар төшеп калуны без, беренче чиратта, әчтәлек, мәгънә белән бәйләнештә алып карыйбыз. Дөрес, авазлары төшеп калуга карамастан, мәгънәләре үзгәреш алмаган сүзләр дә бар, без аны инкарь итмибез. Мәсәлән, борынгы *ыруг* сүзеннән *г* авазы төшеп, *ыру, олуг* дан *олы, оглы* дан *улы* калган һ. б. Ләкин без бу төр кыскаруларны да, механистик кыршылу итеп түгел, бәлки телнең үзенә хас эчке законы белән шомаруы, ипләшүе итеп саныйбыз.

Шуның белән бергә, авазлар төшеп калу сүзләрнең азаккы өлешләренә генә хас күренеш тә түгел, бәлки сүзләрнең уртасындагы авазлары да төшкәннәр һәм, төрле комбинацияләрдә килү аркасында, хәзерге телдә дә төшәләр.

Ниһаять, бер телгә караган сүзләрнең авазлары төшеп калу аның диалектларында төрлечә булырга мөмкин. Мәсәлән, урта диалектта *тегермән* ‖ *текермән*, көнбатыш диалектта исә *тирмән*, ягъни *к* — *г* төшкән.

Аңлашыла ки, теге яки бу мөстәкыйль сүз, ярдәмлек сүз һәм кушымчалардан авазлар төшеп калуның төбендә лексик-грамматик процесс ята. Бу процесста, бер яктан, мөстәкыйль сүзләр үзләре формалашканнар, икенче яктан исә, шундый ук сүзләрнең билгеле бер төркеме ярдәмлек сүзләргә (мәсәлән, бәйлек, теркә-

гечләр, модаль сүзләр...) һәм, ниһаять, кушымчаларга әверелгәннәр. Шуның белән бергә, бу төр әверелү, үзгәрү коры стилистик яки, киресенчә, коры фонетик күренеш кенә дә түгел, бәлки, И. В. Сталин билгеләгәнчә, грамматиканың абстракцияләү чарасы буларак, кешеләр фикерләве тәҗрибәсенең озак заманнар буе тупланган, беллюрләшкән нәтиҗәсеннән гыйбарәт.

Төрки телләр төзелешендәге үзенчәлекләрдән чыгып, морфологик процессны, башлыча, дүрт фазадан тора дип аңлату бар[1]. Бу билгеләмә, нигездә, дөрес һәм татар телендәге фактлар белән дә ачыклана. Бу күренешнең фоно-грамматик процесс булуы ягыннан зур әһәмияте бар. Моның ярдәмендә, хәзерге тел грамматик төзелешенә хас кушымчаларның этимологик чыганаклары теге яки бу төгәллектә ачыла, аныклана алалар. Ләкин без андый киң максатны куймыйбыз. Мөстәкыйль сүзләрдән кайберләренең, фоно-грамматик үзгәреш юлы белән, кушымчага күчүләрен җиңелчә күзәтү белән чикләнәчәкбез.

Татар телендә, мәсәлән, *бер* (сан исеме) дигән сүз бар. Бу үзе мөстәкыйль мәгънәле. Шуның белән бергә, хәзерге татар теле сүзлек составында *бер* тамыры катнашып ясалган сүзләрнең саны йөзгә якын булуы да мәгълүм. Бөек Октябрь социалистик революциядән соң гына да *бер* тамырыннан дистәгә якын сүз ясалды. Алар: *беркетмә* (протокол), *берек* (союз, хәзер кулланылмый), *берләшмә* (объединение), *берәмлек* (азык берәмлеге, кормовая единица), *берлек* (един. число), *беренчелек* өчен (көрәш), *беренчел* (первичный), *бертавыштан* (сайлау)... Менә шушы *бер* сүзе, борынгы төрки ыруглар, кабиләләр телендә үк *лә* (лән) кушымчасы алып, бәйлек, теркәгеч, ягъни ярдәмлек сүз функциясендә йөртелүгә күчкән була. Орхун язмаларында (VIII йөз) „Эчем каган *берлә* илгәрү Яшыл үгүз Шантуң языга тәге сүзәдемез“ (зур язма (17), (мәгънәсе: абыем каган *белән* Яшел үгүз Шантуң җиренә тикле сугыш алып бардык). Бу фразадагы *берлә* теркәгеч функциясен үти. Шул ук текстта без „йите йегерме *әрин*“ формалы сүз тезмәсен дә укыйбыз.

---

[1] Проф. Н. К. Дмитриев, „Грамматика кумыкского языка“, 1940 ел, 50—54 бит. Һәм аныкы ук „Башкорт теленең грамматикаһы“, 1950 ел, 51—55 бит.

С. Е. Малов бу тезмәне „С *семьнадцатью* мужами“ — дип тәрҗемәләгән (37 бит, (11) „Памятники древнетюркской письменности“ (1951 ел). Димәк, бу тезмәдәге *әрин* формасы *ир* белән дигән мәгънәне бирә. Әгәр дә шулай икән, ул чагында *әрин* сүзен *ир-ин* кисәкләренә аерып *ин* (ән), түбәндә, *берлән* (ир берлән) бәйлегеннән кыскарган, кушымчалашкан элемент дип уйларга мөмкинлек туа һәм, шул нигездә, хәзерге татар телендәге *җәйән, язын, көзен, кышын, иртән, кичен* кебек сүзләрдәге вакыт рәвеше ясагыч *н* кушымчасының да шул ук *белән* (← берлән) бәйлегеннән килеп чыккан булуы тагын да ачыклана, ышандыргыч булып әверелә, монысы бер яктан. *Иртән — иртә белән, кичен — кич белән, кышын — кыш белән* формаларының әле бүгенге көндә дә гомумхалык сөйләшендә синоним булып йөрүләре шуны дәлилли, монысы икенче яктан[1].

Хәзерге телдә *белән* || *белә* формасына калган бу бәйлекнең борынгы телдә, *гу* ⟶ *у* га беткән исем фигыльгә ялганып, *рәвеш-хәл* (хәзерге заман хәл фигыль) ясауга йөргәнлеге һәм соңыннан *ып — эп* формалы кушымчага әверелгән булуы билгеле. Мәсәлән, *сатып, йөгереп, барып* формасында әйтелә һәм языла торган хәзерге заман хәл фигыльне борынгы татар әдәбияты язмаларында *сатубән, йөгрүбән, барубән* дип язганнар, һәм бу форма XIX йөзнең беренче яртысына чаклы дәвам иткән.

— „Ки чын кәсәгә *салубән*.

Көмеш кашык илән алың!“ („Чәй бәете“, Насыйри текстыннан.)

— „Качуб китәрде урманга,

*Йөгрүбән* турук кына“ (Г. Кандалый).

Г. Тукай бер урында, „Иске Кисекбашка“ пародия рәвешендә, „Камчылы ишан *тотубән* өшкерде“, — дип яза. („Яңа Кисекбаш“).

Менә шушы фразалардагы *салубән, йөгрүбән, тотубән* формалары *салып, йөгереп, тотып*, ягъни хәзерге заман хәл фигыльнең борынгы вариантлары булып торалар. Шул рәвешчә, борынгы *берлән* бәйлеге хәзерге телдә *белән* (*р* төшеп) формасында кал-

---

[1] Ләкин *берлән* ⟶ *белән* дәге *эн* || ← *ин* үзе әлегә ачылмый кала. Монысы тагын да ныграк өйрәнүне сорый. *Автор.*

ган һәм, хәзерге заман хәл фигыльгә кушылып, *берлән* ⟶ *белән* ⟶ *бән* ⟶ *б* (⟶ *ып* — *эп*) вариантларында йөри башлаган.

Без монда бер тамыр сүзнең бәйлек һәм кушымчага әверелү процессын күзәттек һәм бу процесста сүз үзенең лексик-грамматик, фонетик төзелеше ягыннан зур гына үзгәреш алган булуын күрдек.

„Хәзерге заман теленең элементлары бик борынгы заманнарда ук, коллык эпохасына кадәр үк салынган дип уйларга кирәк. Бу тел катлаулы булмаган, аның сүзлек фонды да бик ярлы булган, ләкин аның үзенең грамматик төзелеше булган, дөрес, примитив төзелеш, ләкин, шулай да, грамматик төзелеше булган“[1], — дип өйрәтә И. В. Сталин.

Грамматик төзелешнең башлангычындагы примитивлык, барыннан да ачыграк булып, кушымчалар тармагында чагыла. Борынгы телдә *даг* — *дак* формасында йөреп, берничә функцияне үтәгән сыйфат, рәвеш кушымчасының хәзерге көнне *дый*, *дай*, *ай* (лай) формаларына аерылуы да шуны күрсәтә. Мәсәлән, *мондаг* ⟶ *мондый*, *ушандак* ⟶ *шундый* һәм *шулай*, *сәндәк* ⟶ *синдәй* формалары килеп чыккан.

Сүзләрнең кушымчалану уңаенда фоно-морфологик үзгәрешкә очрауларын иң ачык һәм һәркемгә аңлаешлы итеп күрсәтә торган факт — бу, *зат* алмашлыкларының *зат* һәм *тартым* кушымчаларына күчүләре. Мәсәлән, *кулым*, *кулың*, *кулы* һәм *бардым*, *бардың*, *барды* формаларындагы *ым*, *ың*, *ы* кушымчалары, *мин* (⟶ м), *син* (⟶ н), *ул* (⟶ ы) сүзләреннән кыскарып, *тартым* һәм *зат* төшенчәләрен тәгъбир итүгә беркетелгәннәр. Һәм, әйткәнебезчә, боларның мәгънәләре, функцияләре үзгәрү белән бергә, фонетик төзелешләре, материаль тышчалары да шактый алмашынган.

Безнең тәҗрибәбезчә, грамматик категорияләр формалашудагы эчке законлылыкны, аларның абстракцияләү чарасы буларак, фонетик яктан да һәм грамматик, шулай ук семантик яктан да үзгәрешләрен тикшергәндә, беренче мисал итеп менә шушы соңгыларын

---

[1] И. В. Сталин, Марксизм һәм тел гыйлеме мәсьәләләре, Татгосиздат, 1951 ел, 23 бит.

алу нәтиҗәлерәк булачак, чөнки укучылар боларны җиңел аңлый һәм үзләштерә алалар.

Гомумән сүз, ярдәмлек сүз һәм кушымчаларның авазлары төшеп калу, түбәндә, грамматик процесс, ягъни эчтәлек белән бәйләнешле күренеш булып тора.

Авазлар төшүнең мәгънәгә бәйләнешле булуы, югарыда күреп үткәнебезчә, бигрәк тә кушымчалар, бәйлекләр, теркәгечләр, гомумән, ярдәмлекләргә карый, дисәк тә хата булмас. Ачыклык өчен тагын бер мисал китерик. Хәзерге татар телендә күпләгән ярдәмче фигыльләрнең берсе булган *тор* (борынгы *тормак*) фигыле бар. Мәсәлән, *язгалый тор;* хаты килеп *тора;* бу безнең иң зур бурычыбыз булып *тора*... кебек тезмәләрдә бу фигыль дәвамлылыкны аңлата.

Менә нәкъ шушы *тор* (мак) борынгы телдә чагыштырмача күп кулланылыш алган була, һәм моны күбрәк очракта фигыльдән башка сүз төркемнәреннән булган хәбәрләргә өстәп йөрткәннәр. Мәсәлән, „Дөньяда хуп-хуп эшләр күп *торыр*" („Иске Кисекбаш"). Соңыннан, Кандалыйлар чорына җиткәч, бу фигыльне хәбәргә өстәп куллану стиле, нигездә, ташлана. Мәсәлән, Г. Кандалый, борынгыча *торыр* фигыле әйтелергә тиешле урыннарда *дыр—дер* кушымчасын гына куллануга күчә. Мәсәлән: „Насыйхәть*дер* сүзем, тыңла!"; „Башын*дадыр* ки, ак калпак"; „Үгет*дер* сәңа бу сүзем".

Күренә ки, Кандалыйның бу *дыр—дер*ләре әнә шушы борынгы *торыр* ярдәмче фигыленнән кыскарып кушымчалашкан вариант булып торалар, һәм үзләре, хәбәр бәйләгече хезмәтен үтәп, түбәндә, шул ук *торыр* мәгънәсен бирәләр.

Хәзерге телдә исә бу кушымча бөтенләй икенче функцияне үти—*ихтимал, бәлки* мәгънәсен бирә: ул инде кайткан*дыр*, дип, без әнә шул ихтималны аңлатабыз.

Шулай итеп, *тор* фигыле, һәм фонетик төзелешен, һәм эчтәлеген үзгәртеп, татар теленә *дыр* кушымчасын биргән була.

Берәр авазлары төшерелү аркасында, икешәр мәгънәгә аерылган сүзләргә мисал итеп, *тугры* (справедливый) ⟶ *туры* (прямой); *охшаш* (похожий) ⟶ *ошашу* (нравиться); *ыруг* (племя) ⟶ *ыру* (кардәш), *хәзер* (сейчас) ⟶ әзер (готовый)... кебек сүзләрне алырга мөмкин.

Билгеле, безнең бу мисалларыбыз — зур өлкәгә кечкенә бер экскурс кына. Шунлыктан болар башлангыч күзаллау бирүдән ерак китә алмаячаклар. Һәрхәлдә, бу мисаллар аваҙлар төшеп, йотылып калуның тарихын аңларга ярдәм итсәләр кирәк.

## 7. Сүзләрнең мәгънәләрен үзгәртмичә генә төшеп калган авазлар һәм иҗекләр

### а. К — г ның исем фигыльләрдә төшеп калуы

*К — г* авазлары турында сөйләгән бүлектә без моңа кагылган идек. Монда исә бер фактны гына өстәп узачакбыз.

а) *Мак — мәк* кушымчасы белән ясала торган исем фигыльгә юнәлеш килеш кушымчасы *ка — кә* ялгану уңае белән, бер *к* ның төшеп, йотылып калуы.

Борынгы татар телендә *мак — мәк* кушымчасы белән ясала торган бертөрле исем фигыль (дөресрәге, фигыль исеме) була. Мәсәлән, *бармак* (бару), *ашамак* (ашау), *укымак* (уку) һ. б.

Бу форма, исем фигыль буларак, килешләр белән дә төрләнгән: *укымак, укымакның, укымакка* һ. б.

Без биредә менә шушы *укымакка* формасының, бер *к* төшеп, *укымага*, ягъни кыскарган формага калуын күзәтәчәкбез.

Борынгы текстларга теркәлгән фактлар безгә түбәндәге мисалларны бирәләр.

„Йосыф-Зөләйха“ текстында *макка*, ягъни *мак* һәм *ка* кушымчаларындагы ике *к* ның да янәшә саклануы (язылуы) төп урынны ала.

Мисаллар:

„Йосыфы *күрмәккә* арзулады“ („Й. З.“, 12 бит).

„Пычак илә *үлдермәккә* хәмлә кылды“ („Й. З.“, 10 бит).

„Лаек дәгүл анлара сән *уҙрмакка*“ (шунда ук).

Күренә ки, китерелгән мисаллардагы *күрмәккә, үлдермәккә, уармакка* фигыльләре икешәр *к* белән язылганнар, ягъни *мак* кушымчасының да һәм юнәлеш кушымчасы *ка* ның да үз авазлары калганнар.

Ләкин „Йосыф-Зөләйха“ текстында ук, әйтергә мөмкин, бу система җимерелгән, һәм без анда ук инде салмага (←салмакка) формасын очратабыз. Мәсәлән:

— *Кою* эчрә *салмага* касд кылдылар („Й. З.“, 13 бит).

Мондагы *салмага* — әнә шул төп, „беренчел“ форма *салмак+ка* ның кыскармасы.

*Мак+ка* кушымчасының *мага* формасына күчүе, янәшә килгән к+к лардан берсе төшеп, *мака* га калу һәм ике сузык арасындагы *к* ның *г* белән алмашыну нәтиҗәсе булып тора: *мак+ка→мака→мага* булып әверелә.

XVI йөз шагыйре Мөхәммәдъяр текстларында инде менә шушы *мага—мәгә,* әйтергә мөмкин, бердәнбер төп форма булып тора.

„Мәңа тикмәс көстә халык *кылмага...*“ (М. Яр).

XVII йөз әдәби текстларында *макка—мәккә* формалары очрамый, анда инде *мага* формасы системага керә.

Мисаллар:

„Дуадакның өне юк, *сүзләмәгә* теле юк“ (М. Колый, 36 бит).

„Башында *утырмага* атасы юк“ (М. Колый).

„*Күрмәгә* барыр булсам, бакмас мәңа“ (шунда ук, 45 бит).

— „Калган халыкны бер җөмганың эчендә читкә *китмәгә* әмер бирде“ („Тәварихы Болгария“, 36 бит).

Монда тагын шуны да әйтеп китәргә кирәк. „Тәварихы Болгария“ авторы Шәрәфетдин-эл-Мөслими *мага* кушымчасына беткән инфинитив урынына, аның *ырга* белән ясала торган формасын куллана башлый:

„Ул дивана, падишаһга илтифат итмәенчә, тәхтенең аякыны балта илә *чабарга* кереште“ (шунда ук, 11 бит).

— „Шәһәр капугларыны баглык күрделәр, һичбер хәйлә илә *керергә* белмәделәр“ (шунда ук, 33 бит).

XIX йөз шагыйре Г. Кандалыйда бу фигыльнең „*сәүмәккә*“ һәм „*сәүмәгә*“, ягъни *мак* ның *к* сын саклап та һәм төшереп тә язылган вариантлары очрый. Мәсәлән:

„Ирең *сәүмәккә* теләсәң...“; „аны *сөйләмәгә* магу“ формаларында язган Кандалый.

Каюм Насыйрида бу фигыль тик „*мага, мәгә*“ аффиксы белән генә йөртелә. Мисаллар:

„Изгүлек *кылмага...*“ („Фәвакиһ-эл-җөласә“, 7 бит).

„Баручыны әда *кылмага* кадир икән“ (шунда ук, 7 бит).

„Ат *тикрәсендә* сакланып *йөрмәгә...* кирәк“ (шунда ук, 484 бит). „Аз *ашамага* тәнбиһдер“ (584 бит); „Исраф *кылмага* тәнбиһдер“ (584 бит).

Ниһаять, Габдулла Тукай телендә дә бу форма фигыль теге яки бу күләмдә урын ала. Мәсәлән, „Туктаганнар *күрмәгә* иртүк табигать күркене“; „*Булмага* мөмкин иде бит бай кеше“; „Бардым, бардым *бакмага,* ян тәрәзә *какмага...*“ (Хал. ижаты) һ. б.

Бөек Октябрь социалистик революциядән соң бу төр фигыль (инфинитив) әдәби кулланыштан төшеп калды.

Татар теленең төрле диалект һәм сөйләшләрендә исә бу форма фигыль әле дә саклана. Без моның Казан арты сөйләшенең Дөбъяз-Әтнә урынчылыгында, Урта диалектның Нократ, Бәрәңге сөйләшләрендә һәм Урта Урал татарлары сөйләшләрендә шактый актив яшәвен беләбез.

Югарыда китерелгәннәрдән мондый нәтиҗә, йомгак килеп чыга. Беренчедән, борынгы телдә исем фигыль ясагыч *мак-мәк* кушымчасына юнәлеш килеш аффиксы *ка—га* өстәлеп, инфинитив (максат фигыль) ясалган. Монысы, грамматик күренеш буларак, кушымчалар тарихын күзәтүгә зур гына ачыклык кертә. Икенчедән, „*мак*“ кушымчасы үзе дә һәм аның „*мак+ка*“ (*ма* (г) *га*) формасы да инде әдәби тотылыштан төшеп калган булулары фактлар белән ачыла. Өченчедән, *мак+ка* кушымчасыннан, саф фонетик законлылык нигезендә, бер *к* ның төшүе, йотылып калуы, гомумән, *мак* кушымчасы үзе берничә вариантка аерылган булу турында ныклы карарга килү мөмкинлеген бирә. Фонограмматик процессның иң характерлы ягы да шунда. Борынгы телдә, берничә кушымча укмашып, кушма, катлаулы аффикслар барлыкка килгән кебек, киресенчә, билгеле бер кушымчадан берничә кушымча ясалу да булган: мәсәлән, *мак* кушымчасы, төбендә, бер үк функцияне саклап (исем, исем фигыль төшенчәсен бирүче сыйфатында), *м, ма* һәм *ак, ык—эк* вариантларына аерылган. Түбәндәге мисаллар шуны күрсәтәләр: *сукмак, тукмак, башмак* — болар, төбендә, исем фигыльләр. *Басма* (к), *тартма* (к), *кабартма* (к); *чәчүрмә* (к)... — болар исемләшкән сүзләр; *белмәк→белек белем; телмәк→телем...* — шулай ук исемләшкән сүзләр; *сызмак→сызык; язмак→язык, бушатмак→*

*бошак* (ирек, азатлык, борынгы сүз), *кушмак→кушак* (билбау), *бизәмәк→бизәк, кулмәк→кием* кебек сүзләрдәге *мәк* белән *м* бер-берсенә тагын да якынрак торалар.

Аңлашыла ки, сүз яки кушымчаларның авазлары төшү, йотылу, „кушылулары“, кеше фикерләвенең абстракцияләү көче белән диалектик бәйләнеш нәтиҗәсендә, телнең грамматик төзелешенә гади күзгә күренмәслек нечкәлекләр кертқәннәр.

### б. Кайбер фигыль ясагыч кушымчалардан г авазының төшеп калуы

Борынгы татар әдәбияты телендә без *гучы* һәм *гусы* формалы ике кушымчаның язылып йөргәнен беләбез. Бу кушымчалар һәр икесе дә үзләре икешәр өлештән торалар: гучы—*гу*+*чы*, гусы—*гу*+*сы*. Бу кушымчалардагы *гу* аффиксы исем фигыль ясаган. Мәсәлән, баргу (бару), укыгу (уку); *чы* аффиксы исә, әнә шул исем фигыльгә өстәлеп, хәзерге заман сыйфат фигыль ясауга йөргән. Мәсәлән, *баргучы*, *язгучы*, *кәлгүче* һ. б. *Сы* аффиксы шулай ук, *гу* белән ясалган исем фигыльгә тоташып, киләчәк заман сыйфат фигыль төшенчәсен бирә торган фигыль ясауга йөргән. Мәсәлән, *йыгылгусы* (мәгънәсе — егылачак). „Дөньядагы тәхетләр *йыгылгусы*“ (XVII йөз, М. К.).

Татар теленең фонетик төзелеше шомару, камилләшү уңаенда, исем фигыль ясагыч *гу*ның *г* авазы төшеп, *у* гына калган, һәм борынгы *язгучы*, *баргучы* формасыннан *язучы*, *баручы* формасына, ә *баргусы*, *язгусы...* формасы *барасы*, *язасы...* булып калган.

Димәк, хәзерге заман сыйфат фигыль һәм киләчәк заман сыйфат фигыльләрнең икесенең дә борынгы язылышларындагы *г* авазы төшкән була.

*Гусы* кушымчасы белән ясалган фигыль борынгы чорда да аз очрый, *гучы* белән ясалган фигыль формасын язу Каюм Насыйрига чаклы дәвам итә. Мәсәлән, Каюм Насыйри „телебездә *булгучы* сүзләр...“ дип яза.

### в. К—г авазлары төшеп калган кайбер сүзләр

Монда, өстәмә итеп, шуны әйтергә кирәк. Татар теленең борынгы торышын деталь тикшергәндә, *к*—*г* авазлары төшеп калган байтак сүзләр табылырга мөм-

кин. Менә берничә мисал: „Йөзе аның кичә *туган* ай дик“ (Мөхәммәдъяр, „Төхфәи мәрдән“, 20 бит). Мондагы *туг+ган* сүзенең төп тамыры *туг* булганмы, әллә *ту* гынамы? Хәзерге телдә *тудыны* борында *тугды* дип, *тумышны тугмыш* формаларында язу шуны күрсәтмиме? Күрсәтә, әлбәттә. („Сәңа бинзәш һичкемсәнә *дугмыш* дәгел“, „Й. З.“, 36 бит).

*Дуг+мыш, туг+ды* формаларында тамырның *туг* булуы дәгъвасыз.

Димәк, Мөхәммәдъярның „*туган*“ дип язуы әнә шул тамырдагы *г* саклануга кайтып кала.

Мондагы *г*, күренеп тора, *ган* кушымчасы белән килү, ягъни ике *г* янәшә килү аркасында төшеп, *туган* калган дип уйларга мөмкин. Тик бу турыда фикер йөртүчеләр *ган*ның үзе, В. А. Богородицкий әйткәнчә, тамырдагы авазның кушымчага күчүе, гадиләшү (упрощение) нигезендә *г+ан* элементларыннан укмашкан булуы ихтималын да истә тотарга тиешләр.

*Туг* тамырын күзәткәндә, К. Насыйриның „Бер *тугма* кардәш“ дип язуын да исәпкә алу кирәк.

„Йосыф-Зөләйха“ да „Гад коюсы *тикрәсендә* йөрдең ирсә“ (15 бит) дигән фраза бар. Монда, тирә сүзе *тикрә*, ягъни *к* белән язылган. Тагын шул ук китапның 68 битендә „Бер айга *тикрү* тагам йимәс имде“ дигән фразаны укыйбыз. Мондагы *тикрү* хәзерге *тиклегә* туры килә.

Шунсы характерлы: *тирә* сүзен *тикрә* формасында язу К. Насыйрида да бар: „Ат *тикрәсендә* сакланып йөрмәгә вә, хатун булса, ире *тикрәсендә* сакланып йөрмәгә тәнбиһдер“) („Фәвакиһ-эл-җөләса“, 584 бит).

Димәк, *тирә* сүзе борында *тикрә* булган, һәм *к* төшеп *тирәгә* калган.

Бу момент хәзерге *тиеш* нең *тикеш, тиерү* нең *тикерү*, мәсәлән, „Сәламымны *тикергәйсен* Сәхибҗәмал абыстайга“ (Г. Кандалый) формасында булганлыкларын күзаллауга һәм аңларга юл ача.

*Текермән* сүзенең *тирмән* формасына калуын да шул ук төркемгә кертергә кирәк.

Шул рәвешчә, *тикер, тикерә, текермән* кебек сүзләрне бер төркемгә җыеп карагач, *кр* комбинациясендәге *к* авазы төшкән дип билгеле бер нәтиҗәгә килергә, кагыйдә чыгарырга була.

### г. Аерым комбинацияләрдә *р* ның төшеп калуы

*Рл* тезмәсендәге *р* төшкән. Мәсәлән, *берлән—белән*.

*Рд* тезмәсендәге *р* төшеп, *ирде—иде, ирмеш—имеш, иркән—икән,* калган.

### д. *Лт* тезмәсеннән *л* ның төшеп калуы

Мисаллар: *Ултыр—утыр; тултыр—тутыр; килтер—китер; үлтер—үтер...*

### е. *Рт* тезмәсеннән *т* ның төшеп калуы

Моның мисалы *йомыртка—йомырка* (сүзендә күренә); „*йомырткадин* чыкар, күккә очар кошлар“ (М. Колый).

Югарыда китерелгән материаллар һәм аларга ясалган анализ, аңлатмалар татар теле фонетик төзелеше тарихына башлангыч бер кереш булып торалар. Татар теле формалашу процессында булган фонетик үзгәрешләр болар белән генә чикләнми, әлбәттә. Шулай булуга карамастан, уебызча, татар теленең тарихи грамматикасын төзүчеләргә, аның фонетик системасы үсешен чагыштырма тарихи метод белән өйрәнүчеләргә моның азмы-күпме ярдәме тиячәк. Икенчедән, югары мәктәпләрдә, педагогия училищеларында татар теле тарихын өйрәнүче һәм өйрәтүче иптәшләр бу материаллардан файдалана алачаклар.